Татарстан Республикасы

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы

# Лаеш урманчылыгының урман хуҗалыгы регламенты

Казан, 2013 ел

Боерык

22.10.2013 №571/20-осн

Казан ш.

**Лаеш урманчылыгының урман хуҗалыгы регламентын раслау хакында**

Россия Федерациясе Урман кодексының 87 статьясының 2 өлеше, 2008 елның 22 маенда кабул ителгән “Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында” 22-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясының 3 өлешендәге 1 пункты нигезендә,

**боерык бирәм:**

1. Лаеш урманчылыгының урман хуҗалыгы регламентын расларга.
2. Мәгълүмати технологияләрне үстерү секторы җитәкчесенә (М.В. Киселев) әлеге боерыкны теркәү һәм бастырып чыгаруны техник яктан тәэмин итәргә.
3. Юридик бүлек башлыгына (М.В. Зайцева) әлеге боерыкны дәүләт теркәвенә алу һәм Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының Рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) рәсми төстә бастырып чыгару өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.
4. Финанс, бухгалтерлык исәбе һәм контрольлеге бүлеге башлыгына (А.К. Ганиева) әлеге боерыкны татар теленә тәрҗемә итүгә бәйле булган чыгымнарны финанслауны тәэмин итәргә.
5. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Министр в.б. Х.Г. Мусин

**Эчтәлек**

**КЕРЕШ......................................................................................................5**
Россия Федерациясенең закон чыгару актлары..............................................6
Урман хуҗалыгы регламентын төзү буенча мәгълүмати база........................13

**1 БҮЛЕК. ГОМУМИ МӘГЪЛҮМАТЛАР.............................................................. 15**
1.1. Урманчылыкка кыскача сыйфатлама..........................................................15
1.2 Урманнардан файдалануның рөхсәт ителгән төрләре..................................31

**2 БҮЛЕК. УРМАННАРДАН РӨХСӘТЛЕ ФАЙДАЛАНУ НОРМАТИВЛАРЫ, ПАРАМЕТРЛАРЫ ҺӘМ ВАКЫТЛАРЫ, УРМАННАРНЫ САКЛАУ, ЯКЛАУ ҺӘМ ЯҢАДАН ҮСТЕРҮ БУЕНЧА НОРМАТИВЛАР...................................................................................................36**
2.1 Үзагач әзерләгәндә урманнардан рөхсәтле файдалану нормативлары (диләнке хисабы), параметрлары һәм вакытлары..................................................................................................36
2.2. Урманнардан чәер әзерләү өчен файдалану нормативлары, параметрлары һәм вакытлары..........................................................................78
2.3 Урманнардан агач булмаган урман ресурсларын әзерләү һәм җыю өчен файдалану нормативлары, параметрлары һәм вакытлары.......................................83
2.4 Урманнардан азык-төлек урман ресурслары әзерләү һәм дару үләннәре җыю өчен файдалану нормативлары, параметрлары һәм вакытлары..............................97
2.5 Урманнардан аучылык хуҗалыгы өлкәсендә эшчәнлек төрләре башкару өчен файдалану нормативлары, параметрлары һәм вакытлары....................................105
2.6. Урманнардан авыл хуҗалыгы алып бару өчен файдалану нормативлары, параметрлары һәм вакытлары.........................................................................107
2.7. Урманнардан фәнни-тикшеренү һәм мәгариф эшчәнлеге башкару өчен файдалану нормативлары, параметрлары һәм вакытлары....................................114
2.8 Урманнардан рекреация эшчәнлеге башкару өчен файдалану нормативлары, параметрлары һәм вакытлары.........................................................................115
2.9 Урманнардан урман плантацияләре булдыру һәм аларны эксплуатацияләү өчен рөхсәтле файдалану нормативлары, параметрлары һәм вакытлары............128
2.10 Урманнардан җимешле, җиләкле, декоратив урман үсемлекләре һәм дару үләннәре үстерү өчен файдалану нормативлары, параметрлары һәм вакытлары...............................................................................................129
2.11 Урманнардан урман үсентеләренең утырту материалларын (чәчкеннәр, үсентеләр) үстерү өчен файдалану нормативлары, параметрлары һәм вакытлары...............................................................................................130
2.12 Урманнардан җир асты байлыкларын геологик өйрәнү, файдалы казылма байлыкларын чыгару урыннарын эшләү өчен файдалану нормативлары, параметрлары һәм вакытлары.........................................................................132
2.13 Урманнардан сусаклагычлар һәм башка төрле ясалма су объектлары, шулай ук гидротехника корылмалары һәм махсуслаштырылган портлар төзү һәм

эксплуатацияләү өчен файдалану нормативлары, параметрлары һәм вакытлары.....135
2.14 Урманнардан линияле объектлар төзү, үзгәртеп кору, эксплуатацияләү өчен файдалану нормативлары, параметрлары һәм вакытлары.....137
2.15 Урманнардан үзагач һәм башка төрле урман ресурсларын эшкәртү өчен файдалану нормативлары, параметрлары һәм вакытлары.....145
2.16 Урманнардан дини эшчәнлек өчен файдалану нормативлары, параметрлары һәм вактлыра.....145
2.17 Урманнарны саклау, яклау һәм яңадан үстерүгә карата таләпләр.....146
2.18 Урманнардан урман үсә торган зоналар һәм урманлы районнар буенча файдалануга карата таләпләрнең үзенчәлекләре.....219

**3 БҮЛЕК. УРМАННАРДАН ФАЙДАЛАНУДА ЧИКЛӘҮЛӘР.....220**
3.1 Урманнардан максатчан файдалану төрләре буенча чикләүләр.....220
3.2 Урман кишәрлекләренең махсус саклана торган төрләре буенча чикләүләр.....222
3.3 Урманнардан файдалану төрләре буенча чикләүләр.....226

# КЕРЕШ

Әлеге урман хуҗалыгы регламенты – Лаеш урманчылыгы урманнарын файдалануны, саклауны, яклауны һәм яңадан җитештерүне гамәлгә ашыру өчен нигез булып тора.

Урман хуҗалыгы регламенты Россия Федерациясе Урман кодексының 04.12.2006 ел, №200-ФЗ (алга таба – РФ УК) 87 статьясының 7 өлеше нигезендә, "Урман хуҗалыгы регламентлары составын, аларны эшләү тәртибен, аларның гамәлдәге вакытын һәм аларга үзгәрешләр кертү тәртибен раслау турында" 04.04.2012 ел, №126 Рослесхоз боерыгы белән расланган программа буенча эшләнде.

Урман хуҗалыгы регламенты урманчылыкның территориясенә, урман үстерү шартларына карата кулланылучы урманнарны комплексны үзләштерүнең нормативлары һәм параметрлары җыелмасын үз эченә ала һәм урман кишәрлекләренең хокукый тәртибен билгели.

Урман хуҗалыгы регламенты урманчылык чикләрендә урманнарны файдалану, саклау, яклау, яңадан торгызуны гамәлгә ашыручы гражданнар һәм юридик затлар тарафыннан мәҗбүри үтәлергә тиешле (РФ УК 87 ст. 6 ө.).

Урман хуҗалыгы регламентында урманчылык чикләрендә урнашкан урманнарга карата, РФ УК 87 статьясының 5 өлеше нигезендә, түбәндәгеләр аныклана:

– РФ УК 25 статьясы нигезендә билгеләнүче урманнардан файдалануның рөхсәт ителгән төрләре;

– агач кисентеләренең яшьләре, диләнке хисабы, урманнардан файдалану вакытлары һәм алардан рөхсәтле файдалануның башка параметрлары;

– РФ УК 27 статьясы нигезендә урманнардан файдалануны чикләү;

– урманнарны саклау, яклау, яңадан торгызуга карата таләпләр;

Урманнардан файдалануның төрләре буенча ел саен мөмкин булган файдалану күләмнәре урман хуҗалыгы регламентының гамәлдәге вакыты өчен билгеләнгән һәм түбәндәгеләрне тәэмин итәргә тиешле:

– урманның кеше сәламәтлеге өчен әйләнә-тирәлекне булдыручы, су саклаучы, яклаучы, санитар-гигиена һәм башка файдалы үзлекләрен саклау һәм көчәйтү;

– җәмгыятьнең урманнарга һәм урман ресурсларына булган ихтыяҗларын канәгатьләндерү буенча урманнарны күпмаксатлы, рациональ, өзлексез, бетермичә куллану;

– урманнарның токым составын һәм сыйфатын яңадан үстерү, яхшырту, аларның продуктлылыгын, саклануын һәм яклануын арттыру;

– урман фонды җирләреннән рациональ файдалану;

– бердәм техник сәясәт нигезендә урман хуҗалыгын алып баруның нәтиҗәлелеген арттыру, фән, техника һәм алдынгы тәҗрибә казанышларын куллану;

– биологик төрлелеген, тарихи-мәдәни һәм табигый мирас объектларын саклау.

Түбәндәрәк аларга нигезләнеп урман хуҗалыгы регламенты булдырылган норматив-хокукый, норматив-техник, методик закон документларының исемлеге китерелә:

**Россия Федерациясенең Закон чыгару актлары**

2006 елның 4 декабрендәге 200-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Урман кодексы (алга таба – РФ УК).

2006 елның 3 июнендәге 74-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Су кодексы (алга таба – РФ СК).

2001 елның 25 октябрендәге 136-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Җир кодексы (алга таба – РФ ҖК).

1994 елның 30 ноябрендәге 51-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Гражданнар кодексы (алга таба – РФ ГК).

1992 елның 21 февралендәге "Җир асты байлыклары турында" 2395-1 номерлы Россия Федерациясе Законы (алга таба – "Җир асты байлыклары турында" РФ Законы).

1994 елның 21 декабрендәге "Янгын куркынычсызлыгы турында" 69-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – "Янгын куркынычсызлыгы турында" ФЗ).

1995 елның 14 мартындагы "Махсус саклanучы табигый территорияләр турында" 33-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 33-ФЗ номерлы Федераль закон).

1995 елның 24 апрелендәге "Хайваннар дөньясы турында" 52-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 52-ФЗ номерлы Федераль закон).

1995 елның 26 декабрендәге "Геодезия һәм картография турында" 209-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 209-ФЗ номерлы Федераль закон).

1997 елның 19 июлендәге "Пестицидлар һәм агрохимикатлар белән сак эш итү турында" 109-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 109-ФЗ номерлы Федераль закон).

1997 елның 26 сентябрендәге "Намус иреге һәм дини берләшмәләр турында" 125-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 125-ФЗ номерлы Федераль закон).

2007 елның 24 июлендәге "Күчемсез милекнең дәүләт кадастры турында" 221-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 221-ФЗ номерлы Федераль закон).

1999 елның 31 мартындагы "Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турында" 69-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 69-ФЗ номерлы Федераль закон).

2001 елның 18 июнендәге "Җир төзелмәсе турында" 78-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 78-ФЗ номерлы Федераль закон).

2002 елның 10 гыйнварындагы "Әйләнә-тирә мохитне саклау турында" 7-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 7-ФЗ номерлы Федераль закон).

2003 елның 26 мартындагы "Электр энергиясе турында" 35-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 35-ФЗ номерлы Федераль закон).

2003 елның 07 июлендәге "Элемтә турында" 126-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 126-ФЗ номерлы Федераль закон).

2006 елның 04 декабрендәге "Россия Федерациясе Урман кодексын гамәлгә кертү турында" 201-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 201-ФЗ номерлы Федераль закон).

1997 елның 17 декабрендәге "Орлыкчылык турында" 149-ФЗ номерлы Федераль закон (149-ФЗ номерлы Федераль закон).

2009 елның 24 июлендәге "Ау һәм аучылык ресурсларын саклау һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" 209-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 209-ФЗ номерлы Федераль закон).

## Аларны җайга салу Россия Федерациясе Урман кодексы һәм аларны җайга салучы норматив-хокукый актлар белән каралган хокукый мөнәсәбәтләр (01.01.2013 елга карата).

| РФ Урман кодексы статьясы | РФ Урман кодексы белән каралган | Норматив актлар |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| **Россия Федерациясе Хөкүмәте актлары** | | |
| 59 ст. | Сирәк һәм юкка чыгу куркынычы янаган урман үсемлекләрен саклау | "Россия Федерациясенең Кызыл китабы турында" 19.02.1996 ел, № 158 РФ Хөкүмәте карары |
| 91 ст. 7 ө. | Дәүләт урман реестрыннан өземтәләр бирүгә түләү күләме һәм аны тотып калу тәртибе | "Дәүләт урман реестрыннан өземтәләр бирүгә түләү күләме һәм аны тотып калу тәртибе турында" 03.03.2007 ел, № 138 РФ Хөкүмәте карары |
| 100 ст. 2 ө.,<br>81 ст. 38 п. | Урман законнарын бозу нәтиҗәсендә урманнарга китерелгән зыянның күләмен исәпләп чыгару таксалары һәм методикалары | "Урман законнарын бозу нәтиҗәсендә урманнарга китерелгән зыян күләмен исәпләп чыгару турында" 08.05.2007 ел, № 273 РФ Хөкүмәте карары |
| 96 ст. 6 ө.<br>81 ст. 36 п. | Дәүләт урман контролен һәм күзәтчелеген башкару тәртибе | "Федераль дәүләт урман күзәтчелеген (урман сагын) гамәлгә ашыру турында нигезләмә раслау турында" 22.06.2007 ел, № 394 РФ Хөкүмәте карары |
| 50 ст. 3 ө. | Зат, затлар төркеме тарафыннан әзерләнергә тиешле максималь үзагач күләме | "Зат, затлар төркеме тарафыннан әзерләнергә тиешле максималь үзагач күләмен билгеләү турында" 22.06.2007 ел, № 395 РФ Хөкүмәте карары |
| 73 ст. 4 ө.<br>81 ст. 27 п. | Федераль милектә булган урман кишәрлеге арендасы буенча урман ресурслары күләме бирәмлеге өчен түләү ставкалары һәм урман кишәрлеге мәйданы берәмлеге өчен түләү ставкалары | "Федераль милектә булган урман кишәрлеге арендасы буенча урман ресурслары күләме берәмлеге өчен түләү ставкалары һәм урман кишәрлеге мәйданы берәмлеге өчен түләү ставкалары турында" 22.05.2007 ел, № 310 РФ Хөкүмәте Карары |
| 44 ст. | Су объектын файдалануга тапшыру турында карар әзерләү һәм кабул итү тәртибе | "Су объектын файдалануга тапшыру турында карарны әзерләү һәм кабул итү тәртибе турында" 30.12.2006 ел, № 844 РФ Хөкүмәте карары. |

| РФ Урман кодексы статьясы | РФ Урман кодексы белән каралган | Норматив актлар |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 45 ст. | Урманнарны линияле объектлар төзүдә файдалану | "Россия Федерациясенең элемтә линияләрен һәм корылмаларын саклау кагыйдәләрен раслау турында"  09.06.1995 ел, № 578 РФ Хөкүмәте карары |
| 76 ст. 3 ө.<br>81 ст. 30 п. | Федераль милектәге җирләрдә әзерләнүче диләнкеләр күләменең бирәмлеге өчен түләү ставкалары (урман утыртмаларын сату-алу килешүе өчен) | "Федераль милектә булган урман кишәрлеге арендасы буенча урман ресурслары күләме берәмлеге өчен түләү ставкалары һәм урман кишәрлеге мәйданы берәмлеге өчен түләү ставкалары турында" 22.05.2007 ел,<br>№ 310 РФ Хөкүмәте Карары |
| 55 ст. 3 ө.; 81 ст. 17 п. | Урманнарда санитар иминлек кагыйдәләре (шул исәптән урман утыртмаларын кисү тәртибе, 16 ст. 3 ө.) | "Урманнарда санитар иминлек кагыйдәләрен раслау турында" 29.06.2007 ел, № 414 РФ Хөкүмәте Карары |
| 53 ст. 4 ө.; 81 ст. 16 п. | Урманнарда янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләре (шул исәптән урман утыртмаларын кисү тәртибе, 16 ст. 3 ө.) | "Урманнарда янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен раслау турында" 30.06.2007 ел, № 417 РФ Хөкүмәте Карары;<br>"Урманнарны янгынга каршы кору турында" 16.04.2011 ел, № 281 РФ Хөкүмәте Карары;<br>"Урманнарда урман янгыннары нәтиҗәсендә барлыкка килгән гадәттән тыш хәлләрне бетерү буенча көчләрне һәм янгын сагы бүлекчәләре чараларын җәлеп итү кагыйдәләрен раслау турында" 05.05.2011 ел, № 344<br>РФ Хөкүмәте Карары<br>"Урман янгыннары нәтиҗәсендә барлыкка килгән гадәттән тыш хәлләр турында" 17.05.2011 ел, № 376 РФ Хөкүмәте Карары;<br>"Урман янгыннарын сүндерү планын һәм аның формасын эшләү һәм раслау кагыйдәләрен раслау турында" 17.05.2011 ел, № 377 РФ Хөкүмәте Карары;<br>"Урманнарда һәм урман янгыннарында янгын куркынычы турындагы мәгълүматларның дөреслеген контрольдә тоту кагыйдәләрен раслау турында" 18.08.2011 ел, № 687<br>РФ Хөкүмәте Карары |
| 22 ст. 3 ө. | Урманнарны үзләштерү өлкәсендә өстенлекле инвестиция проектлары исемлеген әзерләү һәм раслау тәртибе | "Урманнарны үзләштерү өлкәсендәге өстенлекле инвестиция проектлары турында" 30.06.2007 ел, № 419<br>РФ Хөкүмәте Карары |
| 6 ст. | Урманнар урнашкан җирләрнең категорияләре | "Урман фонды җирләрен башка төр (бүтән) категория җирләренә күчерү турында документлар составы һәм аларны әзерләү |

| РФ Урман кодексы статьясы | РФ Урман кодексы белән каралган | Норматив актлар |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | | тәртибе турында" 28.01.2006 ел, № 48 РФ Хөкүмәте Карары |
| 105 ст. 7 ө. | Урман-парк зоналарының, яшел зоналарның функция зоналарын билгеләү | "Урман-парк зоналарының функция зоналарын, урман-парк зоналарының, яшел зоналарның мәйданын һәм чикләрен билгеләү турында нигезләмә раслау турында" 14.12.2009 ел, №1007 РФ Хөкүмәте Карары |
| 13 ст. | Урман инфраструктурасы | "Саклык урманнары, эксплуатация урманнары һәм резерв урманнары өчен урман инфраструктурасы объектлары исемлеген раслау турында" 2012 елның 17 июнендәге №1283-р РФ Хөкүмәте Әмернамәсе |
| **Россия Федерациясе Табигый ресурслар министрлыгы актлары (РФ ТРМ)** | | |
| 62 ст. 3 ө. 81 ст. 21 п. | Урман торгызу кагыйдәләре | "Урман торгызу кагыйдәләрен раслау турында" 16.07.2007 ел, №183 боерык |
| 64 ст. 3 ө. 81 ст. 23 п. | Урманнарда янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләре (шул исәптән урман утыртмаларын кисү тәртибе, 16 ст. 3 ө.) | "Урманнарны карап тору кагыйдәләрен раслау турында" 16.07.2007 ел, №185 боерык |
| 103 ст. 6 ө. 81 ст. 40 п. | Махсус саклануы табигый территорияләрдә урнашкан урманнарны файдалану, саклау, яклау, яңадан торгызу үзенчәлекләре | "Махсус саклануы табигый территорияләрдә урнашкан урманнардан файдалану, аларны саклау, яклау, яңадан үстерү үзенчәлекләрен раслау турында" 16.07.2007 ел, №181 боерык |
| **Федераль урман хуҗалыгы агентлыгы (Рослесхоз) боерыклары** | | |
| 88 ст. 2 ө. | Урманнарны үзләштерү проектының составы һәм аны эшләү тәртибе | "Урманнарны үзләштерү проектының составын һәм аны эшләү тәртибен раслау турында" 29.02.2012 ел, №69 боерык |
| 104 ст. 2 ө. 107 ст. 4 ө. | Су саклау зоналарында урнашкан урманнарны, табигый һәм башка объектларны яклау функциясен үтәүче урманнарны, кыйммәтле урманнарны, һәм шулай ук махсус яклана торган урман кишәрлекләрендә урнашкан урманнардан файдалану, аларны саклау, яклау, яңадан үстерү үзенчәлекләре | "Су саклау зоналарында урнашкан урманнарны, табигый һәм башка объектларны яклау функциясен үтәүче урманнарны, кыйммәтле урманнарны, һәм шулай ук махсус яклана торган урман кишәрлекләрендә урнашкан урманнардан файдалану, аларны саклау, яклау, яңадан үстерү үзенчәлекләрен раслау турында" 14.12.2010 ел, №485 боерык |
| 15 ст. 3 ө. | Урман үсү зоналары һәм урманлы районнар | "Россия Федерациясенең урман үсү зоналары исемлеген һәм Россия Федерациясенең урманлы районнары исемлеген раслау |

| РФ Урман кодексы статьясы | РФ Урман кодексы белән каралган | Норматив актлар |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | | турында" 09.03.2011 ел, №61 боерык |
| 86 ст. 5 ө. | РФ субъектының урман планы составы һәм планны әзерләү тәртибе | "Россия Федерациясе урман планының типлаштырылган формасын һәм составын, аны әзерләү тәртибен раслау турында" 5.10.2011 ел, №423 боерык |
| 87 ст. 7 ө.<br>81 ст. 34 п. | Урман хуҗалыгы регламентларының составы, аларны эшләү тәртибе, аларның гамәлдәге вакыты һәм аларга үзгәрешләр кертү тәртибе | "Урман хуҗалыгы регламентларының составын, аларны эшләү тәртибен, аларның гамәлдәге вакытын һәм аларга үзгәрешләр кертү тәртибен раслау турында" 04.04.2012 ел, №126 боерык |
| 81 ст. | Урманнарны саклык категорияләре буенча аеру | "Урманнарны кыйммәтле урманнарга, эксплуатацияләнүче урманнарга, резервтагы урманнарга кертү буенча вакытлы күрсәтмәләрне раслау турында" 26.08.2008 ел, №237 боерык |
| 15 ст. 4 ө. | Кисентеләрнең яше | "Кисентеләрнең яшен билгеләү турында" 19.02.2008 ел, №37 боерык |
| 29 ст. 5 ө.<br>81 ст. 1 п. | Диләнке хисабын исәпләп чыгару тәртибе | "Диләнке хисабын исәпләп чыгару тәртибе турында" 27.05.2011 ел, №191 боерык |
| 29 ст. 9 ө.<br>81 ст. 4 п. | Үзагач әзерләү кагыйдәләре (шул исәптән урман утыртмаларын кисү тәртибе, 16 ст. 3 ө.) | "Үзагач әзерләү кагыйдәләрен раслау турында" 01.08.2011 ел, №337 боерык |
| 39.1 ст. | Урман үсемлекләренең утырту материалларын үстерү | "Урманнардан урман үсемлекләренең утырту материалларын (үсентеләрне, чәчкеннәрне) үстерү өчен файдалану кагыйдәләрен раслау турында" 19.07.2011 ел, №308 боерык |
| 45 ст. | Урманнардан линияле объектлар төзү, үзгәртеп кору, эксплуатацияләү өчен файдалану | "Урманнардан линияле объектлар төзү, үзгәртеп кору, эксплуатацияләү өчен файдалану кагыйдәләрен раслау турында" 10.06.2011 ел, №223 боерык |
| 43 ст. | Урманнардан җир асты байлыкларын геологик өйрәнүне башкару һәм файдалы казылма ятмаларын эшләп чыгару өчен файдалану | "Урманнардан җир асты байлыкларын геологик өйрәнүне башкару һәм файдалы казылма ятмаларын эшләү өчен файдалану кагыйдәләрен раслау турында" 27.12.2010 ел, №515 боерык |
| 31 ст. | Чәер әзерләү | "Чәер әзерләү кагыйдәләрен раслау турында" 24.01.2012 ел, №23 боерык |
| 91 ст. 9 ө.; 81 ст. 35 п. | Дәүләти урман реестрын алып бару тәртибе | "Дәүләти урман реестрын алып бару турында" 30.05.2011 ел, № 194 боерык;<br>"Дәүләти урман реестрын алып бару рәвешләрен раслау турында" 15.02.2012 ел, №194 боерык |
| 32 ст. | Агач булмаган урман ресурсларын әзерләү һәм җыеп алу | "Агач булмаган урман ресурсларын әзерләү һәм җыеп алу турында" 05.12.2011 ел, №512 боерык |

| РФ Урман кодексы статьясы | РФ Урман кодексы белән каралган | Норматив актлар |
| --- | --- | --- |
| 1 | 2 | 3 |
| 39 ст. | Җимешле, җиләкле декоратив урман үсемлекләрен үстерү | "Урманнардан җимешле, җиләкле, декоратив урман үсемлекләрен, дару үләннәрен үстерү өчен файдалану кагыйдәләрен раслау турында" 05.12.2011 ел, № 510 боерык |
| 34 ст. | Азык-төлек урман ресурсларын һәм дару үсемлекләрен әзерләү | "Азык-төлек урман ресурсларын һәм дару үләннәрен әзерләү кагыйдәләрен раслау турында" 05.12.2011 ел, №511 боерык |
| 40 ст. | Фәнни-тикшеренү эшчәнлеген, мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашыру буенча урманнардан файдалану | "Урманнардан фәнни-тикшеренү эшчәнлеген, мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашыру буенча файдалану кагыйдәләрен раслау турында" 23.12.2011 ел, №548 боерык |
| 41 ст. | Рекреация эшчәнлеген башкару өчен урманнардан файдалану | "Урманнардан рекреация эшчәнлеген башкару өчен файдалану кагыйдәләрен раслау турында" 21.02.2012 ел, №62 боерык |
| 104 ст.<br>105 ст. | Су саклау зоналарында урнашкан урманнардан, табигый һәм башка объектларны яклау функциясен үтәүче урманнардан, кыйммәтле урманнардан, һәм шулай ук махсус яклана торган урман кишәрлекләрендә урнашкан урманнардан файдалану | "Су саклау зоналарында урнашкан урманнардан, табигый һәм башка объектларны яклау функциясен үтәүче урманнардан, кыйммәтле урманнардан, һәм шулай ук махсус яклана торган урман кишәрлекләрендә урнашкан урманнардан файдалану, аларны саклау, яклау, яңадан үстерү үзенчәлекләрен раслау турында" 14.12.2010 ел, №485 боерык |
| 49 ст. 3 ө.<br>81 ст. 14 п. | Урманнардан файдалану буенча хисап рәвеше һәм аны тапшыру тәртибе | "Урманнардан файдалану, аларны саклау, яклау, яңадан үстерү, урман үрчетү турында хисапларның рәвешләрен һәм аларны тапшыру тәртибен билгеләү турында" 14.02.2012 ел, №47 боерык |
| 60 ст. 2 ө.<br>81 ст. 20 п. | Урманнарны саклау һәм алардан файдалану буенча хисап рәвеше һәм аны тапшыру тәртибе | "Урманнардан файдалану, аларны саклау, яклау, яңадан үстерү, урман үрчетү турында хисапларның рәвешләрен һәм аларны тапшыру тәртибен билгеләү турында" 14.02.2012 ел, №47 боерык |
| 63 ст. 2 ө.<br>81 ст. 22 п. | Урман үрчетү кагыйдәләре | "Урман үрчетү кагыйдәләрен раслау турында" 10.01.2012 ел, №1 боерык |
| 66 ст. 2 ө.<br>81 ст. 25 п. | Урманнарны яңадан үстерү һәм урман үрчетү турында хисап рәвеше, аны тапшыру тәртибе | "Урманнардан файдалану, аларны саклау, яклау, яңадан үстерү, урман үрчетү турында хисапларның рәвешләрен һәм аларны тапшыру тәртибен билгеләү турында" 14.02.2012 ел, №47 боерык |
| 89 ст. 1 ө. | Урманнарны үзләштерү проектының дәүләт һәм муниципаль экспертизасы тәртибе | "Урманнарны үзләштерү проектының дәүләт һәм муниципаль экспертизасы тәртибен раслау турында" 22.12.2011 ел, №545 боерык |
| 26 ст. 3 ө. | Урман декларациясенең | "Урман декларациясе турында" 17.01.2012 ел, |

| РФ Урман кодексы статьясы | РФ Урман кодексы белән каралган | Норматив актлар |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 81 ст. 3 п. | рәвеше, аны тутыру һәм тапшыру тәртибе | №18 боерык |
| 77 ст. 5 ө.<br>81 ст. 31 п. | Дәүләт яки муниципаль милектәге урман утыртмаларын сату-алу килешүләрен әзерләү һәм төзү тәртибе, һәм урман утыртмаларын сату-алу килешүенең үрнәк рәвеше | "Дәүләти һәм муниципаль милектәге җирләрдә урнашкан урман утыртмаларын сату-алу килешүләрен әзерләү һәм төзү тәртибен, һәм Урман утыртмаларын сату-алу килешүенең үрнәк рәвешен раслау турында" 26.07.2011 ел, № 318 боерык |
| 74 ст. 5 ө.<br>29 һәм 28 п.<br>81 ст. | Дәүләти яки муниципаль милектәге урман кишәрлеге арендасы килешүен әзерләү һәм төзү тәртибе, һәм урман кишәрлеге арендасы килешүенең үрнәк рәвеше | "Дәүләти яки муниципаль милектәге урман кишәрлеге арендасы килешүен әзерләү һәм төзү тәртибен, һәм урман кишәрлеге арендасы килешүенең үрнәк рәвешен раслау турында" 26.07.2011 ел, № 319 боерык |
| 38 ст. | Урманнардан авыл хуҗалыгын алып бару өчен файдалану | "Урманнардан авыл хуҗалыгын алып бару өчен файдалану кагыйдәләрен раслау турында" 05.12.2011 ел, №509 боерык |
| 26 ст. 6 ө.<br>81 ст. 2 п. | Үзагачын әзерләү рөхсәт ителмәгән агачларның һәм куакларның төрләре (токымнары) исемлеге | "Үзагачын әзерләү рөхсәт ителмәгән агачларның һәм куакларның төрләре (токымнары) исемлеген раслау турында" 05.12.2011 ел, №513 боерык |
| 46 ст. 3 ө.<br>81 ст. 13 п. | Урманнардан үзагач һәм башка урман ресурсларын эшкәртү өчен файдалану кагыйдәләре | "Урманнардан үзагач һәм башка урман ресурсларын эшкәртү өчен файдалану кагыйдәләрен раслау турында" 12.12.2011 ел, № 517 боерык |
| 53 ст. 4 ө.; 81 ст. 16 п. | Урманнарда янгын һәм санитар иминлек кагыйдәләре | "Урманнарда янгын куркынычсызлыгын яисә санитар иминлекне тәэмин итү максатларында гражданнарның урманнарда булуын һәм аларга транспорт чараларының үтеп керүен, урманнарда билгеле бер эш төрләрен үткәрүне чикләү тәртибен раслау турында" 03.11.2011 ел, №471 боерык<br>"Урманнарны янгынга каршы кору турында турында" 27.04.2012 ел,<br>№174 боерык<br>"Урманнарның табигый янгын куркынычы классификациясен һәм, урманнардагы һава торышына карап, табигый янгын куркынычы классификациясен раслау турында" 05.07.2011 ел, № 287 боерык |
| 67 ст.<br>68 ст. | Урман коруны үткәрү кагыйдәләре | "Урман кору күрсәтмәсен раслау турында" 12.12.2011 ел, №516 боерык. |
| | Санитар-тернәкләндерү чараларын үткәрү буенча күрсәтмә, Зарарлы организмнар чыккан | "Методик документларны раслау турында" 29.12.2007 ел, №523 боерык. |

| РФ Урман кодексы статьясы | РФ Урман кодексы белән каралган | Норматив актлар |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | урыннарны юк итү һәм бетерү буенча күрсәтмә, Урманнарны патологик яктан мониторинглауны проектлау, оештыру һәм алып бару буенча күрсәтмә һәм Урманнарны патологик тикшеренүләрне планлаштыру, оештыру һәм алып бару буенча күрсәтмә | |
| **Татарстан Республикасының норматив-хокукый актлары** | | |
| 82, 83 ст. | | 2008 елның 22 маендагы "Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында" 22-ТРЗ номерлы ТР Законы;<br>2009 елның 16 мартындагы "Татарстан Республикасының Урман планын раслау турында" ПУ-146 номерлы ТР Президенты Указы<br>"2011-2014 елларда Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгын үстерү" озак вакытлы максатчан программасын раслау турында" 29.04.2011 ел, № 355 ТР МК Карары |

## Урман хуҗалыгы регламентын төзү буенча мәгълүмати база

Урман хуҗалыгы регламентын эшләгәндә түбәндәгеләрдән файдаланылды:

– законнар, методик һәм норматив документлар нигезендә яшь класслары ысулы белән башкарылган 2012 елның урманкору материаллары;

– җир корылышы материаллары;

– Татарстан Республикасы урман хуҗалыгы идарәсе органнарының исемлек һәм статистика хисаплылыгы;

– РФ Юстиция министрлыгында теркәлгән норматив-хокукый актлар.

Россия ТРМ урман хуҗалыгы регламентларына үзгәрешләр кертү тәртибе ачыкланды. Үзгәрешләрне кертү түбәндәге очракларда рөхсәт ителә:

– урман торышы һәм структурасы буенча урман корылышын яисә махсус тикшеренүләрне уздырганда ачыкланган үзгәрешләр;

– урман мөнәсәбәтләре өлкәсендәге гамәлдә булган норматив-хокукый актлардагы үзгәрешләр;

– Россия Федерациясе законнарында каралган бүтән очракларда.

Аларны Урман кодексына ярашлы торышка китерү өчен түбәндәге гамәлләр башкарылды:

– 01.01.2013 елга карата дәүләти урман реестры күрсәткечләре нигезендә урманчылыкның мәйданы билгеләнде.

– урманчылык кишәрлекләре буенча урманнардан рөхсәтле файдалану төрләре билгеләнде;

– әзерләнгәннең күләме (диләнке хисабы), өлгергән һәм картайган утыртмаларны сайланма һәм тоташ кисүләрдә урманнарны рөхсәтле файдалануның параметрлары һәм вакытлары хисапланды;

– урманнарны карап тотканда, санитар-сәламәтләндерү чараларын үткәргәндә урта яшьле, өлгереп килүче утыртмаларны кискәндә әзерләнүче үзагач күләмнәре хисапланды;

– урманнардан чәер әзерләү буенча рөхсәтле файдалануның нормативлары, параметрлары һәм вакытлары билгеләнде,

– агач булмаган урман ресурсларын әзерләү буенча урманнардан рөхсәтле файдалануның нормативлары, параметрлары һәм вакытлары билгеләнде;

– азык-төлек урман ресурсларын әзерләү һәм дару үләннәрен җыеп алу буенча урманнардан рөхсәтле файдалануның нормативлары, параметрлары һәм вакытлары билгеләнде;

– аучылык хуҗалыгын алып бару һәм аучылык белән шөгыльләнү, авыл хуҗалыгын алып бару буенча урманнардан рөхсәтле файдалануның нормативлары, параметрлары һәм вакытлары билгеләнде;

– урманнардан рөхсәтле файдалануның нормативлары, параметрлары һәм вакытлары, урманнарны саклау, яклау һәм яңадан торгызу нормативлары билгеләнде;

– урманнардан максатчан билгеләнеш төрләре, махсус якланучы кишәрлек төрләре буенча файдаланудагы чикләүләрнең нормативлары, куллану төрләре буенча чикләүләр билгеләнде;

– урманнарның максатчан билгеләнеше буенча бүлгәләнешенә карап, картографик материалларга үзгәрешләр кертелде.

Әлеге урман хуҗалыгы регламенты 19.03.2009 ел, №151 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Карары белән расланды.

Урман хуҗалыгы регламенты 10 елга (2019 елның мартына кадәр) кадәрге вакытка эшләнде.

Регламентны эшләүче булып түбәндәгеләр санала:

ФГУП "Рослесинфорг" "Поволжский леспроект" Казан экспедиция филиалы, 420087, Казан ш., Г. Кутуй ур. – 155 а (2008 елның 18 февралендәге 64 номерлы дәүләт контракты).

Үзгәрешләр кертүче оешмалар турында белешмәләр:

2010 елда – ФГУП "Рослесинфорг" Казан филиалы, 420087, Казан ш., Г. Кутуй ур. – 155 а (2010 елның 29 октябрендәге 441 номерлы дәүләт контракты).

2013 елда – "Ульяновсклеспроект" җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять, Ульян ш., Орлов ур., 21 а, тел. (8422) 72-79-29 (2012 елның 25 декабрендәге 815 номерлы дәүләт контракты).

# 1 БҮЛЕК. ГОМУМИ МӘГЪЛҮМАТЛАР

## 1.1. Урманчылыкка кыскача сыйфатлама

### 1.1.1. Урманчылыкның исеме һәм урнашкан урыны

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының Лаеш урманчылыгы (алга таба – Урманчылык) Татарстан Республикасының көнбатыш өлешендә Лаеш, Питрәч һәм Балык бистәсе муниципаль районнары территорияләрендә урнашкан.

Урманчылыкның конторасы республика үзәге булган Казан шәһәреннән 67 чакрымдагы Лаеш поселогы район үзәгендә урнашкан.

Урманчылыкның почта адресы: 422605, Татарстан Республикасы, Лаеш ш., Яшел ур., 1.

Урманчылык территориясенең төньяктан көньякка кадәр озынлыгы – 65 чм, көнчыгыштан көнбатышка кадәр – 53 чм.

### 1.1.2. Урманчылыкның һәм кишәрлек урманчылыкларының гомуми мәйданы

01.01.2013 елга карата Лаеш урманчылыгының урман фонды җирләренең гомуми мәйданы – 34031 га, шул исәптән кишәрлек урманчылыклары буенча:

Питрәч – 13274 га;
Янтык – 8240 га;
Лаеш – 12517 га.

### 1.1.3. Урманчылык территориясен муниципаль берәмлекләр буенча бүлгәләү

Урманчылык территориясен муниципаль берәмлекләр буенча бүлгәләү 1.1.3 таблицада китерелә.

1.1.3 таблица

**Урманчылыкның структурасы**

| № п/п | Урман кишәрлекләренең исеме | Административ район (муниципаль берәмлек) | Гомуми мәйданы, га |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Питрәч | Питрәч | 12891 |
| | | Балык Бистәсе | 383 |
| | Кишәрлек урманчылыгы буенча җәмгысе: | | 13274 |
| 2. | Янтык | Питрәч | 661 |
| | | Балык Бистәсе | 364 |
| | | Лаеш | 7215 |
| | Кишәрлек урманчылыгы буенча җәмгысе: | | 8240 |
| 3. | Лаеш | Лаеш | 12517 |

| № п/п | Урман кишәрлекләренең исеме | Административ район (муниципаль берәмлек) | Гомуми мәйданы, га |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 8. | Урманчылык буенча җәмгысе: | | 34031 |
| | шул исәптән районнар буенча: | Питрәч | 13522 |
| | | Лаеш | 19732 |
| | | Балык Бистәсе | 747 |

Тулаем алганда, Урманчылыкның урман фонды массивлар буларак та, төрле зурлыктагы аерымланган утраучыклар буларак та гыйбарәт. Төньяк һәм көнбатыштан Шәһәр яны урманчылыгы, төньяктан Саба урманчылыгы, көнчыгыштан Кызыл Йолдыз урманчылыгы белән чикләшә, көньяктан Куйбышев сусаклагычына тоташа һәм көньяктан һәм көнбатыштан чиге өлешчә Дәүләт Идел-Чулман дәүләт тыюлыкларына барып тоташа.

Урманлылыгы 13,5% алып (Питрәч районы) 84% кадәр (Балык Бистәсе районы) – уртача 14,4%.

### 1.1.4. Татарстан Республикасының Урманчылык территориясе аерып күрсәтелгән схематик картасы

Татарстан Республикасының Урманчылык территориясе аерып күрсәтелгән схематик картасы № 1 карта-схемада күрсәтелгән.

### 1.1.5. Урманчылык урманнарын урман үсү зоналарына һәм урманлы районнарга бүлү

Федераль урман хуҗалыгы агентлыгының "Россия Федерациясенең урман үсү зоналары исемлеген һәм Россия Федерациясенең урманлы районнары исемлеген раслау турында" 09.03.2011 ел, № 61 боерыгы белән расланган урман үсү районнарына бүлү нигезендә, урманчылык территориясе ылыслы-киң яфраклы (катнаш) урманнар зонасының Россия Федерациясенең Европа өлешендәге ылыслы-киң яфраклы (катнаш) урманнар районына кертелгән (1.1.5 таблица).

1.1.5 таблица


**Урманчылык урманнарын урман үсү зоналарына һәм урманлы районнарга бүлү**

| № п/п | Урман кишәрлекләренең исеме | Урман үсү зонасы | Урманлы район | Урман кварталлары исемлеге | Мәйданы, га |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| 1. | Питрәч | Ылыслы-киң яфраклы урманнар зонасы | Россия Федерациясе Европа өлеше ылыслы-киң яфраклы (катнаш) урманнар районы | 11-182 | 13274 |
| 2. | Янтык | Ылыслы-киң | Россия Федерациясе | 1-99 | 8240 |

| № п/п | Урман кишәрлекләренең исеме | Урман үсү зонасы | Урманлы район | Урман кварталлары исемлеге | Мәйданы, га |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| | | яфраклы урманнар зонасы | Европа өлеше ылыслы-киң яфраклы (катнаш) урманнар районы | | |
| 3. | Лаеш | Ылыслы-киң яфраклы урманнар зонасы | Россия Федерациясе Европа өлеше ылыслы-киң яфраклы (катнаш) урманнар районы | 1-112, 114-123 | 12517 |
| | ҖӘМГЫСЕ: | | | | 34031 |


Урманчылык территориясенең Урманчылык территориясен һәм урман үсү зоналары һәм урманлы районнар буенча кишәрлек урманчылыкларын аерып күрсәткән схематик картасы № 2 карта-схемада күрсәтелгән.

Карта-схема N1. Схематическая карта Республики Татарстан
с выделением территории лесничества.




- Лаишевское лесничество

Карта-схема N2. Распределение территории лесничества по лесорастительным зонам и лесным районам.



## 1.1.6. Урманнарны максатчан билгеләнеше һәм саклык урманнары категорияләре буенча бүлү

Урманнарны максатчан билгеләнеше һәм кварталлар яки аларның өлешләре буенча саклык урманнарына бүлү, һәм шулай ук саклык һәм эксплуатация урманнарын бүлеп чыгаруга нигезләр 1.1.6.1 таблицада китерелгән.

1.1.6.1 таблица.

**Урманнарны максатчан билгеләнеше һәм саклык урманнары категорияләре буенча бүлү**

| Урманнарның максатчан билгеләнеше | Кишәрлек урманчылыгы | Кварталларның яисә аларның өлешләренең номерлары | Мәйданы, га | Урманнарны максатчан билгеләнеше буенча бүлүнең нигезләре |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| Барлыгы урманнар | | | 33657 | РФ Урман кодексы, РФ Су кодексы, 04.12.2006 ел, №201-ФЗ Федераль закон, "Урманнарны кыйммәтле урманнарга, эксплуатация урманнарына, резерв урманнарына кертү буенча вакытлыча күрсәтмәләрне раслау турында" 26.08.2008 ел, №237 Рослесхоз боерыгы, 12.12.2011 ел, №516 Рослесхоз боерыгы белән расланган Урман корылышы инструкциясе, 04.05.2011 ел, №669-р ТР МК әмернамәсе. |
| Саклык урманнары, барлыгы | | | 28911 | |
| Су саклау зоналарында урнашкан урманнар | Янтык | 4 - 5, 9, 19, 32, 51, 54, 55, 71, 74-79, 85, 91 квартал өлешләре, 73 кв. | 278 | |
| | Лаеш | 39 кв., 90, 99, 112 квартал өлешләре | 156 | |
| | Барлыгы | | 434 | |
| Табигый һәм башка объектларны саклау функциясен үтәүче урманнар, барлыгы | | | 23085 | 04.12.2006 ел, №201-ФЗ Федераль закон, 14.07.1944 ел, № 14537 СССР ХКС әмернамәсе һәм 31.12.2003 ел, №702 ТР МК Карары белән расланган Гомуми файдаланудагы автомобиль юллары исемлеге, 04.05.2011 ел, №669-р ТР МК әмернамәсе нигезендә |
| Россия Федерациясе субъектлары милкендә булган, гомуми кулланылыштагы тимер юл, гомуми кулланылыштагы федераль автомобиль юллары, гомуми кулланылыштагы автомобиль юллары буйларындагы саклык урманнары полосалары | Питрәч | 16, 41, 42, 43, 44, 93, 94, 99, 100, 102, 105-110, 114 квартал өлешләре | 331 | |
| | Янтык | 39, 40, 43 квартал өлешләре | 50 | |
| | Лаеш | 31, 43, 44, 48-49 квартал өлешләре | 93 | |
| | Барлыгы | | 474 | |
| яшел зоналар | Питрәч | 11, 12, 13, 15, 17-40, 45-49, 51-65, 68-77, 79-92, 95- 98, 101, 103, 104, 111-113, | 11214 | 04.12.2006 ел, №201-ФЗ Федераль закон, 04.05.1949 ел, №6136-р СССР МС әмернамәсе, 22.06.93 ел, |

| Урманнарның максатчан билгеләнеше | Кишәрлек урманчылыгы | Кварталларның яисә аларның өлешләренең номерлары | Мәйданы, га | Урманнарны максатчан билгеләнеше буенча бүлүнең нигезләре |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| | | 115-117, 119-135, 145-161 кварталлар, 16, 41-44, 93, 94, 99, 100, 102, 105-110, 114 квартал өлешләре | | №168 Рослесхоз боерыгы |
| | Лаеш | 1- 20, 23-30, 32 - 38, 40-42, 45-47, 50-73, 75, 76, 79-89, 93-94, 96, 98, 100, 102-111 кварталлар, 31, 43, 44, 48 ,49 квартал өлешләре | 10244 | |
| | Барлыгы | | 21458 | |
| урман-парк зоналары | Янтык | 1, 2, 3 кв. | 169 | 04.12.2006 ел, №201-ФЗ Федераль закон, 18.04.2011 ел, №543-р ТР МК әмернамәсе, 04.05.2011 ел № 669-р ТР МК әмернамәсе |
| | Лаеш | 22 кв., 21, 74, 77, 78, 91, 92, 95, 97, 101 квартал өлешләре | 984 | |
| | Барлыгы | | 1153 | |
| Кыйммәтле урманнар, барлыгы: | | | 5392 | |
| эрозиягә каршы көрәш урманнары | Янтык | 35, 37 кв., 38, 45, 61, 71 квартал өлешләре | 353 | 04.12.2006 ел, №201-ФЗ Федераль закон, 28.11.1980 ел, №1981-р РСФСР МС әмернамәсе, "Татарстан Республикасы территориясендә урманнарны кыйммәтле, эксплуатация урманнарына кертү һәм аларның чикләрен билгеләү турында" 16.06.2010 ел, №232 Рослесхоз боерыгы |
| | Барлыгы | | 353 | |
| кеше аз йөри торган ярымдала, урман-дала, урман-тундра зоналарында, далаларда, тауларда урнашкан урманнар | Питрәч | 162-182 кв. | 1103 | 04.12.2006 ел, №201-ФЗ Федераль закон, 11.08.1950 ел, №12221-р СССР МС әмернамәсе "Татарстан Республикасы территориясендә урманнарны кыйммәтле, эксплуатация урманнарына кертү һәм аларның чикләрен билгеләү турында" 16.06.2010 ел, №232 Рослесхоз боерыгы, 18.04.2011 ел, №543-р ТР МК әмернамәсе. |
| | Янтык | 31, 36, 39, 41, 42, 44, 46, 47, 59 , 60, 62-70, 72, 80, 92-99 кв,, 40, 43 квартал өлешләре | 2281 | |
| | Лаеш | 114-123 кв. | 933 | |
| | Барлыгы | | 4317 | |
| фәнни яисә тарихи әһәмияткә ия урманнар | Питрәч | 14, 50, 66, 67 | 287 | 04.12.2006 ел, №201-ФЗ Федераль закон, 23.07.1991 ел, №313 СССР |
| | Барлыгы | | 287 | |

| Урманнарның максатчан билгеләнеше | Кишәрлек урманчылыгы | Кварталларның яисә аларның өлешләренең номерлары | Мәйданы, га | Урманнарны максатчан билгеләнеше буенча бүлүнең нигезләре |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| | | | | Министрлар Кабинеты карары, "Татарстан Республикасы территориясендә урманнарны кыйммәтле, эксплуатация урманнарына кертү һәм аларның чикләрен билгеләү турында" 16.06.2010 ел, №232 Рослесхоз боерыгы |
| уылдык саклаучы урман полосалары | Янтык | 74-79 кв. өлешләре | 330 | 04.12.2006 ел, №201-ФЗ Федераль закон, 26.10.1975 ел, №554-р РСФСР МС әмернамәсе, 07.08.1978 ел, №388 РСФСР МС карары, "Татарстан Республикасы территориясендә урманнарны кыйммәтле, эксплуатация урманнарына кертү һәм аларның чикләрен билгеләү турында" 16.06.2010 ел, №232 Рослесхоз боерыгы 04.12.2011 ел, №669-р ТР МК әмернамәсе, 18.04.2011 ел, №543-р ТР МК әмернамәсе |
| | Лаеш | 90, 99, 112 кв. | 105 | |
| | Барлыгы | | 435 | |
| Эксплуатация урманнары | Янтык | 6, 7, 8, 10-18, 20-30, 33, 34, 48-50, 52, 53, 56-58, 81-84, 86-90 кварталлар, 4, 5, 9, 19, 32, 51, 54, 55, 85, 91 квартал өлешләре | 4746 | 04.12.2006 ел, №201-ФЗ Федераль закон, 23.04.1943 ел, №430 СССР ХКС әмернамәсе, "Татарстан Республикасы территориясендә урманнарны кыйммәтле, эксплуатация урманнарына кертү һәм аларның чикләрен билгеләү турында" 16.06.2010 ел, № 232 Рослесхоз боерыгы |
| | Барлыгы | | 4746 | |

Урманнарны максатчан билгеләнеше һәм саклык урманнары категорияләре буенча бүлү 1.1.6.2 таблицада күрсәтелгән.

1.1.6.2 таблица

## Урманнарны максатчан билгеләнеше һәм саклык урманнары категорияләре буенча бүлү

мәйданы, га

| Кишәрлек урманчылыгы | Барлыгы урманнар | Саклык урманнары, барлыгы | Шул исәптән саклык урманнары категорияләре | | | | | | | | | | Эксплуатация урманнары |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Су саклау зоналарында урнашкан урманнар | Табигый һәм башка төр объектларны саклау функциясен үтәүче урманнар, барлыгы | шул исәптән: | | | Кыйммәтле урманнар, барлыгы | шул исәптән: | | | | |
| | | | | | Гомуми файдаланудагы т/юл, гомуми файдаланудагы федераль а/ю, гомуми файдаланудагы РФ субъектлары милкендә булган а/ю буйларында урнашкан саклык урман полосалары. | Яшел зоналар | Урман-парк зоналары | | Уылдык саклаучы урман полосалары | эрозиягә каршы көрәш урманнары | Кеше аз йөри торган ярымдала, урман-дала, урман-тундра зоналарында, далаларда, тауларда урнашкан урманнар | Фәнни яисә тарихи әһәмияткә ия урманнар | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 |
| Питрәч | 13274 | 13274 | - | 11545 | 331 | 11214 | - | 1729 | - | - | 1442 | 287 | - |
| Янтык | 8240 | 3494 | 278 | 219 | 50 | - | 169 | 2997 | 313 | 403 | 2281 | - | 4746 |
| Лаеш | 12517 | 12517 | 156 | 11321 | 93 | 10244 | 984 | 1040 | 107 | - | 933 | - | - |
| Барлыгы* | 33657 | 28911 | 434 | 23085 | 474 | 21458 | 1153 | 5392 | 435 | 353 | 4317 | 287 | 4746 |
| Барлыгы** | 34031 | 29207 | - | 23085 | 474 | 21458 | 1153 | 6122 | 776 | 403 | 4656 | 287 | 4824 |

* "Татарстан Республикасы территориясендә урманнарны кыйммәтле урманнарга, эксплуатация урманнарына кертү һәм аларның чикләрен билгеләү турында" 16.06.2010 ел, № 232 Рослесхоз Боерыгы нигезендә

** 01.01.2013 карата урман фонды исәбе күрсәткечләре нигезендә (чираттагы тапкыр урманкоруны үткәргәндә күрсәткечләр аныклауны таләп итә)

### 1.1.7. Урманчылык территориясенең урман фонды җирләре составындагы урман һәм урман булмаган җирләргә сыйфатлама

1.1.7 таблица

**Урманчылык территориясенең урман фонды җирләре составындагы урман һәм урман булмаган җирләргә сыйфатлама**

| Җирләрнең категорияләре | Урманчылык буенча барлыгы | |
|---|---|---|
| | Мәйданы, га | % |
| 1 | 2 | 3 |
| Җирләрнең гомуми мәйданы | 34031 | 100 |
| Урманлы җирләр - барлыгы | 32886 | 96,6 |
| Урман үсемлекләре белән капланган җирләр барлыгы | 32238 | 94,7 |
| шул исәптән урман культуралары | 10343 | 30,4 |
| урман үсемлекләре белән капланмаган җирләр | 457 | 1,3 |
| шул исәптән: | | |
| тоташмаган урман культуралары | 449 | 1,3 |
| урман питомниклары; плантацияләр | 8 | 0,0 |
| табигый аралыклар | | |
| урман торгызу фонды, барлыгы | 191 | 0,6 |
| шул исәптән | | |
| көекләр | | |
| һәлак булган урман утыртмалары | 7 | 0,0 |
| кисү | 125 | 0,4 |
| аланлыклар, ташландык урыннар | 59 | 0,2 |
| Урмансыз җирләр - барлыгы | 1145 | 3,4 |
| шул исәптән | | 0,0 |
| сөрүлекләр | 17 | 0,0 |
| печән чабу урыннары | 281 | 0,8 |
| утлавыклар | 119 | 0,4 |
| сулар | 42 | 0,1 |
| бакчалар һ.б. | 2 | 0,0 |
| юллар, урман юллары | 242 | 0,7 |
| утарлар | 35 | 0,1 |
| сазлар | 168 | 0,5 |
| комлыклар | | |
| башка җирләр | 239 | 0,7 |

### 1.1.8. Булган махсус сакланучы табигый территорияләрнең һәм объектларның, аларны оештыру, экологик челтәрләрен үстерү, биотөрлелеген саклау буенча планнарының сыйфатламасы

Алга таба санап үтелгән территорияләрнең (кишәрлекләрнең) хокукый режимы РФ УК 103 ст. белән билгеләнә. Әлеге җирләр әйләнештән чыгарылган яки әйләнештә чикләнгән (РФ ҖК 27 ст.).

Махсус сакланучы табигый территорияләрдә, шул исәптән урманнарны файдалану, саклау, яклау һәм яңадан үстерү өлкәсендә тыелган яисә рөхсәт ителгән эшчәнлекнең конкрет төрләре РФ ҖК, РФ УК, "Махсус сакланучы табигый территорияләр турында" 14.03.1995 ел, №33-ФЗ Федераль закон, һәм шулай ук аларны үтәү өчен чыгарылган Татарстан Республикасы норматив-хокукый актлары белән билгеләнә.

Аларда хуҗалыкны алып бару режимы түбәндәгеләрне тыя:

– табигый процессларга кешенең теләсә нинди йогынтысы тыелган кишәрлекләрдәге урман утыртмаларын кисү;

– әгәр бу махсус сакланучы табигый территорияләрнең чикләрендә каралган функция зоналарының хокукый режимы белән башкасы каралмаган булса, урман утыртмаларын тоташ кисү;

– җирләрне теләсә нинди файдалануга бүлү;

– теләсә нинди коммуникацияләрне салу;

– территорияне төзеп тутыру, чүпләү яисә иске-москы белән тутыру;

– терлек куу, йөртү, печән чабу;

– файдалы казылмалар табу;

– биосфера полигоннарыннан гайре, урманнарны саклау һәм яклау өчен, шул исәптән фәнни максатларда агулы химия препаратларын куллану;

– автотранспортны кертү һәм туктатып тору;

– туристлык тукталышларын кору, учаклар ягу;

– агач булмаган урман ресурсларының түбәндәге үсемлек төрләрен әзерләү һәм җыеп алу: РФ Кызыл китабына һәм Татарстан Республикасы Кызыл китабына кертелгәннәрне;

– җимешле, җиләкле, декоратив урман үсемлекләрен, дару үсемлекләрен үстерү;

– кирәкмәгән агачларны кисү һәм башка төр кисүләр әлеге территорияләр өчен билгеләнгән режимда башкарыла.

Дини, урман торгызу эшчәнлеген башкару рөхсәт ителә.

Ау, авыл хуҗалыгын алып бару, фәнни-тикшеренү, мәгариф, рекреация эшчәнлеге башкару, урман плантацияләре булдыру, җир асты байлыкларын геологик өйрәнү буенча эшләр башкару, ятмаларны эшләп чыгару, сусаклагыч һәм башка төр су объектларын төзү һәм эксплуатацияләү әлеге территорияләр өчен билгеләнгән режим нигезендә чикләнә.

Урманчылык территориясендә махсус саклануучы, кабатланмас урман үстерү һәм биологик үзенчәлекләргә ия булган табигый территорияләр бар (1.1.8 таблица).

1.1.8 таблица

**Махсус саклануучы табигый территорияләр исемлеге**

| № п/п | МСТТ исеме | мәйданы, га | Киш. урманчылыгы урнашу урыны, квартал, бүлендек | МСТТ профиле, бүлеп чыгаруга нигез | Кыскача сыйфатлама | Урман хуҗалыгын алып бару режимы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| Республика әһәмиятендәге дәүләт табигать һәйкәлләре | | | | | | |
| 1. | "Иске тегермән" ландшафт профильле региональ әһәмияттәге дәүләт табигый тыюлыгы | 111,8 | Питрәч Кишәрлеге урманчылыгы, 66, 67 кварталлар | Ботаник, 23.07.1991 ел, №313 ТАССР МС Карары, 29.12.2005 ел, №644 ТР МК Карары. | Кечкенә болынлы җирләре булган урман массивы, Елан тавы. | РФ һәм ТР законнары белән билгеләнгән саклау режимын үтәү. Тоташ кисүләр тыела. Һәлак булган һәм зарарланган агачларны кисү максатларында сайланма кисүләр рөхсәт ителә. |
| 2. | Комплекслы профильле региональ әһәмияттәге Ленино-Кокушкино дәүләт табигый заказнигы | 165 | Питрәч Кишәрлеге урманчылыгы, 14, 50 кварталлар | Тарихи, 23.07.1991 ел, №313 ТАССР МС Карары, 2004 елның 19 августындагы №379 ТР МК Карары. | Ульянов Ленин гаиләсе булган җирләргә бәйле истәлекле урыннар. | РФ һәм ТР законнары белән билгеләнгән саклау режимын үтәү. Тоташ кисүләр тыела. Һәлак булган һәм зарарланган агачларны кисү максатларында сайланма кисүләр рөхсәт ителә. |

1. "Иске тегермән" ландшафт профильле региональ әһәмияттәге дәүләт табигый заказнигы

Заказник территориясенә Питрәч урманчылыгының 66 һәм 67 кв., алар Мишә елгасының уң ярында урнашкан, һәм кечкенә болыннары булган Елан тавы керә. Территориянең гомуми мәйданы – 122 га. Төп урман булдыручы токым – нарат. Урманның үзәк өлешендә өлгергән наратлыклар, ә көнчыгыш өлешендә яшь агачлыклар үсә. Сөзәклекнең югары өлеше гөлҗимеш, эт шомырты куаклары үскән. Мәйданның калган өлеше үзәнлекләр һәм култыклы болыннар белән капланган. Үлән капламы төрле-төрле. Татарстан Республикасының Кызыл

китабына кертелгән үсемлекләрдән түбәндәгеләр билгеле: биек испәрәк, тояксыман какамия, Урал цицербиты һ.б.

| 22. | Юкәле Чыршылык (Е лп.)<br>ТУМ: С2<br>Бонитет: 1 – 2<br>Яңа чыршылык | 6Е1П<br>1Б1Лп<br>1Ос<br>юкә керергә мөмкин нарат чыбылдыгына | Тигез, җиңелчә югарылыклы, яссы сөзәклекләр | Уртача<br>аз күләмдә көлсу, балчыксыл | Төркемле, чыршы, ак чыршы, кайчак усак һәм каен катнашында, тәрәзәләрдә, юкәнең куе чатыры булмаганда, 2 ярус тәшкил итә | Уртача куелыкта яки куе - юкә, миләш, зелпе, эт шомырты, кабар, балан, карлыган | Киң яфраклы үләннәр, сәрдә, кайчак кызыл бөрлегән, кымызлык, майник, абага, талакдар | Юк яки аз күләмдә үсеш алган яшел мүкләр | Канәгатьләндерерлек нигездә наратка алмашынып, сирәк юкәгә | Усак, каен, юкә<br>Бонитет: 1 - 1б | Кыяклы (сәрдәле) | ПР<br>СР<br>Е.з<br>Л/к |
| 23. | Юкәлекле Чыршылык (Е лпк.)<br>ТУМ: С2<br>Бонитет: 2 (1)<br>Яңа чыршылык | 8Е1С<br>1Б+ Ос | Тигез җиңелчә югарылыклы | Кәслесулыкөлсу балчыксыл яңа | Төркемле, чыршы, кайчак каен һәм усак катнашмалы ак чыршы | Уртача куелыкта яки куе - юкә, миләш, зелпе, эт шомырты, кабар агачы, балан | Киң үләнле үләннәр, кымызлык, күкебаш, сәрдә, абага, түбәнлекләрдә кара җиләк | Яшел мүкләр аз үсеш алган | Канәгатьләндерерлек, йомшак яфраклыларга алмашынып | Каенлы усаклы<br>Бонитет: 2 – 1 | Кыяклы | ПР<br>СР<br>Е.з<br>Л/к |
| 24. | Кымызыклы чыршылык (Е к.)<br>ТУМ: С3<br>Бонитет 1.(2).<br>Дымлы чыршылык | 7Е2Ос<br>1Б + П<br>берәм. С, Лп | Бүлемтекләрдәге биеклекләр һәм яссы калкулыклар. М/рельеф җиңелчә дулкынлы | Уртача алтынсу балчыксыл, балчык белән түшәлә торган | Сирәк чыршылы ак чыршы катнашында, юкәле кырыйларда усак катнашмалы | Сирәк - миләш, эт шомырты, бүре курысы, зелпе, юкә | Кымызлык, майник, абага, талакдар, себерке кыяк, сәрдә, таштояк, каеш яфрак; сирәгрәк чәчбай, төркем-төркем | Яшел мүкләр | Канәгатьләндерерлек, йомшак яфраклыларга алмашынып, кайчакта - чыршы | Каенлы усаклы<br>Бонитет: 1 – 2 | Эреүләнле, кырлыганлы, куралыклы (сәрдәле) | ПР<br>СР<br>Е.з<br><br>Л/к |

| № п/п | Урман тибы, үсеп китү урынындагы шартларның типлары бонитет классы | Утыртмаларның уртача составы | Рельефтагы торышы | Туфрагы | Яшь агачлыклары | Куаклыклары | Капламы | | Торгызылуы | Җитештерү утыртмалары | Кисү тибы | Кисүләрнең ысулы урман торгызу ысулы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | Үләнле | Мүкле, лишайник | | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 |
| | | | | | | | кара җиләк | | үсентеләре хисабына | | | |
| 25. | Чыршылы елга буендагы (Е пр.) ТУМ: С4 Бонитет: 3 (2) Дымлы чыршылык | 7Е2Б 1Ол+Ос, Лп катнашмалы Л. 5 берәмл. кадәр. Чыршы | Елга, елгачык буйлары агымсулы дымланып торулы | Үләнле-алтынсу, торфлы-глейлы, балчыксыл яки комсыл | Сирәк, кайчак урт. куелыктагы, төркемле Сирәк юкә, зирек катнашмалы | Урт. куелыктагы яки сирәк шомырт, карлыган, миләш, юкә | Мул, тубылгы күпчелек тәшкил итә, кычыткан, абага, сирәгрәк сәрдә, урман наратбашы, зеленчук, бохар кынасы, себерке кыяк, кашыклык үлән | Юк яки аз үскән, кәккүк җитене, сирәк сфагнум, калкулыкларда яшел мүкләр | Чыршы үрентеләре хисабына яки йомшак яфраклыларга алмашынып | Усаклы зирекле каенлы Бонитет: 1 – 3 | Тубылгылы | ПР СР Е.з |
| 26. | Чыршылык имәнле (Е имән) ТУМ: Д2, 3; С2, 3 Бонитет 1.(2). Яңа чыршылык | 7Е1Д 2Ос+Б, Лп | Биекләндерелгән яссылык һәм җиңелчә таулыклар | Уртача һәм бик аз күләмдә көлсу, балчыксыл | Чыршы, имән, юкә, сирәк | Куе, чикләвек куагы, зелпе, кабар, юкә | Киң яфраклы үләннәр | Юк | Канәгат. йомшак яфраклыларга алмашынып яки үсенте хисабына | Каенлы усаклы Бонитет 1 - 2. | (Сәрдәле) | ПР СР Е.з Л/к |
| **Имән утыртмалары** | | | | | | | | | | | | |
| 27. | Имәнлек өрәңгеле-юкәле-сәрдәле яңа (Д сн) ТУМ: Д2 Бонитет: 3 Яңа имәнлек | 6Д2Ос 1Б1Лп | Биеклекләрдәге субүләр һәм яссы калкулыклар | Соры урман һәм кәсле-көлсу балчыксыл яки комсыл балчык белән түшәлә торган | Сирәк яисә урт. куелыктагы, юкә, каен, имән, урыны белән өрәңге, корычагач | Урт. куелыкта, миләш, чикләвек куагы, кагар агачы, юкә | Сәрдә, йолдызак, таштояк, сырмавык, кыңгырау чәчәк, ландыш, миләүшә, кашыклы абага күкебаш | Юк | Йомшак яфраклыларга алмашынып | Лп, Кл, Ос, Б Бонитет: 2 (1) | (Сәрдәле) | СР Л/к |
| 28. | Имәнлек чыршылы-юкәле (д е. лп) | 7Д 2Е 1Б+ Ос | Тигез | Соры урман җиңелчә-алтынсу, балчыксыл | Сирәк, имән, усак | Сирәк, чикләвек куагы, кабар агачы | Сизелерлек мул, нигездә киң яфраклы үләннәр | Юк | Йомшак яфраклыларга алмашыны | Лп, Б Ос, Е Бонитет 1 - 2. | Кырлыганлы | урт. Л/к |

| № п/п | Урман тибы, үсеп китү урынындагы шартларның типлары бонитет классы | Утыртмаларның уртача составы | Рельефтагы торышы | Туфрагы | Яшь агачлыклары | Куаклыклары | Капламы | | Торгызылуы | Житештерү утыртмалары | Кисү тибы | Кисүләрнең ысулы урман торгызу ысулы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | Үләнле | Мүкле, лишайник | | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 |
| | ТУМ: Д3<br>Бонитет 3<br>Дымлы имәнлек | | | | | | | | п | | | |
| 29. | Өрәңгеле-юкәле, абагалы имәнлек<br>(д кл. п.)<br>ТУМ: Д3<br>Бонитет: 2 – 3<br>Дымлы имәнлек | 8Д1Ос<br>1Б<br>берәм. Лп, Кл, Вяз, Ил | Сөзәклекләрнең түбән өлеше | Соры урман уртача алтынсу, балчыксыл | Имәннән, каеннан, усактан, корычагачтан төркемле | Урт. куелыкта, чикләвек куагы, кабар агачы, балан, эт шомырты, шомырт, карлыган | Куе. Абага, сәрдә, таштояк, сырлавык, кырлы борчак, кымызлык, күкебаш, йолдызак, миләүшә, урман кысыр тигәнәге, ике өйле, яран | Юк | Усакка, каенга һәм юкәгә алмашка | Лп, Кл, Б, Ос<br>Бонитет 1 - 2. | Тубылгылы | СР<br><br>Л/к |
| 30. | Тугайлы тубылгылы имәнлек<br>(Д пмт.)<br>ТУМ: Д4<br>Бонитет: 3 (2)<br>Дымлы имәнлек | 6Д 2Б<br>2Ос<br>+Е, Лп | Елга үзәннәре | Кәсле-болынлы балчыксыл | Сирәк яки урт. куелыктагы, имән, каен, усак | Сирәк, яки урт. куелыктагы - эт шомырты, шомырт, тал, зелпе, гөлҗимеш карлыган | Киң яфраклы үләннәр: себерке кыяк, абага, тубылгы, кычыткан, сәрдә, яран, казаяк, кысыр тигәнәк | Юк | Канәгатьләндерерлек, имән һәм йомшак яфраклы токымнарның яшь агачлары белән | К. зирек, каенлы-усаклы<br>Бонитет 1 - 3. | Кыяклы | СР<br><br>Е.з |
| **Чыршылы урман типлары** | | | | | | | | | | | | |
| 31. | Кыяклы каенлык<br>(Б ос.)<br>ТУМ: С4<br>Бонитет: 4, 5<br>Дымлы чыршылык | Каен нарат һәи чыршы катнашында | Тигез түбәнләндерелгән иңкүлекләр һәм калкулыклы өслекле сазланган елга үзәннәре | Торфлы-глейлы балчыксыл, ләмле - торфлы | Сирәк, зирек, каен | Сирәк талдан, эт шомыртыннан | Кыяклылар, бишьяфрак, тавык үләне, тубылгы | Сфагнум, кәккүк җитене, югарылыкларда яшел мүкләр | Каен һәм зирек яшь агачлары белән | Зирекле<br>Бонитет<br>4 – 5 | Кыяклы | СР<br><br>Е.з |

| № п/п | Урман тибы, үсеп китү урынындагы шартларның типлары бонитет классы | Утыртмаларның уртача составы | Рельефтагы торышы | Туфрагы | Яшь агачлыклары | Куаклыклары | Капламы | | Торгызылуы | Җитештерү утыртмалары | Кисү тибы | Кисүләрнең ысулы урман торгызу ысулы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | Үләнле | Мүкле, лишайник | | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 |
| | | | | **Кара зирекле урман типлары** | | | | | | | | |
| 32. | Зиреклек (Зир.) ТУМ: С5, Д5 Бонитет 2 (3,1). Юеш зиреклек (торф катламы һәм сазлыклар булмаганда, бонитет 1) | 7Олч 3Б +Ос катнашма Б һәм Ос төрле, кайчак юк | Сазланган тугайлар һәм акрын агучы су агынтысы белән саз тирәләре | Ләмле-торфлы кәсле-көлсу, глейлы, балчыксыл, 10 см кадәр торф катламы яки бөтенләй юк | Сирәк - зирек, кайчак каент һәм усак катнашмалы | Сирәк - тал, кайчак шомырт, карлыган, юкә | Бишьяфрак, тавык үләне, тубылгы, күрән, югарылыкларда сәрдә, кашыклык үлән, абага, кычыткан очрый | Юк | Зирек, каен һәм усак шытымнары белән | Сирәк каенлы Бонитет 2.(3). | Кыяклы | СР<br>Е.з |
| | | | | **Тал утыртмалары урманнарының типлары** | | | | | | | | |
| 33. | Тугайлыктагы таллык (Т пм.) ТУМ В3 Бонитет 3 - 4(2). Тугайлык | 10 Ив | Елгалы һәм елгачыклы тугайлыклар | Төрле механик составлы | Юк | Юк | Сирәк болын үләнле | Юк | Канәгатьләндерерлек, яшь тал куаклары булган | Барлыкка килми | Тубылгылы | СР<br>Е.з |
| | | | | **Антропоген урман типлары** | | | | | | | | |
| 34. | Киптерелгән наратлык (Ст. ос.) ТУМ: А2 - А4 В1 - В3 Бонитет 3 - 4. Торфлык киптерелгән | 9С1Б + Ос | Киптерелгән торфлыклар | Торфлы-глейлы | Наратлы сирәк | Сирәк - тал эт шомырты | Кассандра, түбәнлекләрдә сазанак, калкулыкларда кара җиләк, мүк җиләге | Кәккүк җитене, микроюгарылыкларда яшел мүкләр | Канәгатьләндерерлек, нарат һәм чыршы белән | Билгеле түгел | Тубылгылы | СР<br>Е.з |
| 35. | Киптерелгән каенлык (Б т.ос.) ТУМ: С2 - С4 | 7б2Ос 1С + Ол | Киптерелгән торфлыклар | Торфлы-глейлы | Нарат сирәк | Тал, эт шомырты, балан | Кара җиләктән, мамыкбаштан, кыяктан, куян йонынннан, | Кәккүк җитене | Каен белән канәгатьләндерерлек | Билгеле түгел | Тубылгылы | СР<br>Л/к |

| № п/п | Урман тибы, үсеп китү урынындагы шартларның типлары бонитет классы | Утыртмаларның уртача составы | Рельефтагы торышы | Туфрагы | Яшь агачлыклары | Куаклыклары | Капламы | | Торгызылуы | Җитештерү утыртмалары | Кисү тибы | Кисүләрнең ысулы урман торгызу ысулы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | Үләнле | Мүкле, лишайник | | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 |
| | Бонитет: 2-3 (4) Киптерелгән торфлык | | | | | | ярышниктан сирәкләнгән | | | | | |

## 2.1.7. Үзагач әзерләү буенча урманнардан файдалану вакытлары һәм башка мәгълүматлар

Урман утырмаларын һәр диләнкедә кисү, тарттыру, өлешчә эшкәртү, саклау һәм әзер үзагачны алып чыгу урман кишәрлеген үзагач әзерләү максатларында файдаланучы зат тарафыннан, урман декларациясе нигезендә декларацияләнүче чор башланган көннән 12 ай эчендә, яисә үзагачны урман утыртмаларын сату-алу килешүе нигезендә әзерләгән очракта, – урман утыртмаларын сату-алу килешүендә билгеләнгән вакыт эчендә башкарыла.

Урман утыртмаларын кисүнең, үзагач саклауның һәм алып чыгуның әлеге пунктта күрсәтелгән вакытларын озынайту күрсәтелгән таләпләрне үз вакытында үтәүгә юл калдырмаган начар һава шартлары барлыкка килгән очракта рөхсәт ителә.

Урман утыртмаларын кисүнең, үзагач саклауның һәм алып чыгуның вакытлары урманнан файдаланучы затның язмача гаризасы буенча, вәкаләтле орган тарафыннан 12 айдан да артмаган күләмдә арттырылырга мөмкин.

Үзагач әзерләгәндә:

а) елга һәм чишмә үзәннәрен сөйрәмә җир трассалары һәм урман юллары сыйфатында куллану рөхсәт ителми;

б) диләнке чикләрендә урман утыртмаларын, үсемчелек катлавын һәм туфракларны зарарлау, урманнарны сәнәгать һәм башка калдыклар белән чүпләү рөхсәт ителми;

в) юлларны, күперләрне һәм агач кисеп салынган юлларны, һәм шулай ук киптерүче челтәрне, юл, гидромелиоратив һәм башка корылмаларны, су агымнарын, чишмәләрне, елгаларны саклау мөһим;

г) өемнәрне (кисеп ташланган һәм диләнкедә калдырылган агачларны исәпкә алып) һәм кисеп ташланган асылынып төшкән агачларны калдыру, саклап калынырга тиешле яшь агачны зарарлау яисә бетерү тыела;

д) чик, квартал, диләнке һәм башка баганаларны һәм агачлардагы һәм агач төпләрендәге билгеләрне, ярлыкларны һәм номерларны бетерү яисә зарарлау тыела;

е) кисүгә тиешле булмаган һәм Россия Федерациясенең Үзагач әзерләү кагыйдәләре һәм урман законнары нигезендә сакланырга тиешле агачларны, шул исәптән орлык бирү чыганакларын һәм полюс агачларын кисү һәм зарарлау тыела;

ж) рөхсәт ителгән вакыты (рөхсәт ителгән кичектереп торуларны исәпкә алып) тәмамланганнан соң үзагач әзерләү, һәм шулай ук файдалану хокукы туктатылганнан соң яисә тәмамланганнан соң үзагач әзерләү рөхсәт ителми;

з) билгеләнгән вакытка (рөхсәт ителгән кичектереп торуларны исәпкә алып) үзагачны алып чыкмыйча диләнкедә калдыру рөхсәт ителми;

и) диләнке эшләп чыгаруның технологик картасында каралмаган урыннарга үзагач чыгару, тарттыру рөхсәт ителми;

к) диләнке чистарту буенча эшләрне үтәмәү яисә үз вакытында үтәмәү рөхсәт ителми;

л) сөйрәмә җирләрдән һәм төяү мәйданнарыннан кала туфракның өске уңдырышлы катламын юк итү рөхсәт ителми;

Үзагач әзерләгәндә Россия Федерациясе Кызыл китабына, Татарстан Республикасы Кызыл китабына кертелгән зат төрләре сакланырга тиешле.

Исемлеге "Үзагачын әзерләү тыелган агачларның һәм куаклыкларның төрләре (токымнары) исемлеген раслау турында" 05.12.2011 ел, №513 Рослесхоз боерыгы белән расланган агач һәм куаклыклар төрләреннән (токымнарыннан) үзагач әзерләү рөхсәт ителми.

Урманнарның биотөрлелеген арттыру максатларында үзагач әзерләгәндә диләнкеләрдә теләсә кайсы яруста аерым кыйммәтле һәм алар төркемендәге агачлар (карт агачлар, куышлы, кош оялары булган, һәм шулай ук оя кору һәм вак җанварларга качу урыны һ.б. өчен яраклы агачлар) сакланырга мөмкин.

Үзагач әзерләү максатларында урман кишәрлеге мәйданының кисү өчен билгеләнгән өлеше (алга таба – диләнке) аерып алына, һәм шулай ук урман утыртмаларының сан һәм сыйфат сыйфатламалары һәм әзерләүгә тиешле үзагачның күләмен билгеләүче таксация ясала. Диләнкеләрне аерып алганда җирлектә диләнкеләрнең чикләре билгеләнә һәм тамгалана, сайланма кисүләрдә киселергә тиешле агачлар билгеләнә.

Диләнкене аерып алу һәм таксацияләү түбәндәгеләр тарафыннан башкарыла:

– урман кишәрлекләре арендасы килешүләре нигезендә үзагач әзерләүче гражданнар һәм юридик затлар;

– аларга даими (озак вакытлы) файдалануга тапшырылган урман кишәрлекләрендә үзагач әзерләүче федераль дәүләт учреждениеләре;

– Россия Федерациясе Урман кодексының 82-84 статьялары нигезендә билгеләнгән вәкаләтләре кысаларында дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, урман утыртмаларын сату-алу килешүләре нигезендә үзагач әзерләү өчен гражданнар һәм юридик затлар.

Кисүләрнең төрле формаларында диләнкеләрне аерып алу урман кварталы кысаларында, кагыйдә буларак, карсыз чорда башкарыла. Урмантаксация бүлендекләре тулысынча кисүгә юнәлдерелә, әгәр дә аларның мәйданы Үзагач әзерләү кагыйдәләрендә билгеләнгән диләнкеләрнең чик күләмнәрен артып китмәсә.

Эксплуатация урманнарындагы өлгергән, картайган урман утырмаларын кискәндә диләнкегә урман таксациясе бүлемтекләре кысаларында гомуми мәйданы 3 гектардан артып китмәүче өлгергән һәм картайган урман бүлендекләре дә кертелергә мөмкин.

Урман кварталында кисүгә өлгергән урман утыртмаларын бер үк вакытта берничә катнаш урман таксацияләү бүлемтеге бирелергә мөмкин, әмма аларның суммар мәйданы, урман утыртмаларының иң күп токымы өчен билгеләнгән диләнке зурлыгыннан артмаска тиеш.

Урман үсентеләрен кисүләр сайланма кисүләр яки тоташ кисүләр рәвешендә башкарыла.

Сайланма кисүләр тиешле җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә агачларның һәм куакларның бер өлешен кисүдән гыйбарәт (Россия Федерациясе Урман кодексының 17 статьясындагы 2 өлеше).

Аерым агачлар һәм куаклар яисә агачларның һәм куакларның төркемнәре урманнарны торгызу өчен саклап калдырылып, тиешле җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә урман утыртмаларын кисү тоташ кисүләр дип атала (Россия Федерациясе Урман кодексының 17 статьясындагы 3 өлеше)

Үзагач әзерләү өчен билгеләнгән урман кишәрлекләрендә тоташ кисүләр әлеге урман кишәрлекләрендә урманнарны торгызу шарты белән генә рөхсәт ителә (Россия Федерациясе Урман кодексының 17 статьясындагы 5 өлеше).

Киселүче агачларның холкына һәм кисүләрнең технологиясенә карап, Урманчылыкта өлгергән, картайган урман утыртмаларын кисүнең түбәндәге төрләре башкарылырга мөмкин: ирекле-сайланма, төркемле-сайланма, төркемле-эзлекле (чокыр-чокыр), полоса аша эзлекле, озаклап-эзлекле кисүләр.

Ирекле-сайланма кисүләрдә мәйдан буйлап тигез рәвештә беренче чиратта зарарланган, картайган, акрын үсүче өлгергән агачлар киселә, әмма бу чакта агач токымнарын торгызу тәэмин ителергә, урманның яклау һәм мохит барлыкка китерү сыйфатлары сакланырга тиеш. Әлеге кисүләрдән соң аяк өсли агачларның тулылыгы 0,5 түбәнрәк булмаска тиеш.

Төркемле-сайланма кисүләр төркемле-төрле яшьтә булган урман утыртмаларына карата башкарыла, аларда картайган һәм өлгергән агачлар, урман диләнкесендә урнашуларына карап, төркем-төркем киселә. Киселүче төркемнәрнең мәйданы 0,01дән 0,5 гектарга кадәр тәшкил итә.

Тигез-эзлекле кисүләрдә бер үк яшь классындагы аяк өсли агачлар диләнкедә икенче ярустагы урман утыртмаларын һәм шытып чыккан утыртмаларны кисү барышында башлангыч яисә юлдаш урманнарны торгызуны тәэмин итеп, тигез генә сирәкләү юлы белән берничә мәртәбә башкарыла. Тигез-эзлекле кисүләр шулай ук яшәү көче басымчакланган шытып чыккан үсентеләре биек һәм уртача тулылыктагы, өлгерү дәрәҗәсе төрле булган, агач токымнары белән барлыкка китерелгән аяк өсли агачларда, катнаш урман утыртмаларында (ылыслы-яфраклы, усаклы-каенлы һ.б.) башкарыла.

Кисүләрне беренче тапкыр башкарганда аяк өсли агачларның тулылыгы 0,5 кадәр кими. Үсентеләр булмаганда яисә аларны барлыкка китерү өчен яшь үсентеләр җитәрлек булмаганда, тиешле үсеш шартларында тигез-эзлекле кисүләр вакытында урманны торгызуга ярдәм чаралары башкарыла.

Оя-оя үсентеләр булган урыннарда ике яшь классы дәвамында шытып чыгучы агачлар төркем-төркем (чокыр-чокыр) берничә мәртәбә киселә (шулай ук аларның тагын шытып чыгулары тәэмин ителә) торган төркемле-эзлекле (чокыр-чокыр) кисүләрдә бер үк яшьтәге урман утыртмаларында яшь үсентеләр төркемләп урнаштырыла. Өлгергән агачларны кисү эзлекле итеп, 30-40 ел дәвамында оя-оя үсентеләр булган урыннарда 0,01 алып 1,0 гектарга кадәрге мәйданнарда (чокырларда) 3-5 тапкыр башкарыла.

Озаклап-эзлекле итеп кисүләр, әлеге шартларда тотрыклы булып кала торган, өлгереп җитмәгән, эксплуатация күләмнәренә җиткән агачлар өлешен икенче алымга калдырып, ике тапкырда төрле яшьтәге урман утыртмаларында башкарыла. Беренче тапкырдан соң аерым тулылык куе төстәге ылыслы урманнарда 0,5 һәм ачык төстәге ылыслы урман утыртмаларында 0,4 ким булмаска тиеш. Кисү алымнарын кабатлау чоры – 30-40 елдан соң.

Полоса аша акрынлап кисүләрне уздырганда агач биеклегеннән артмаган киңлектәге билгеле бер тәртиптә чиратлаша торган полосаларда бер яшь классындагы агачлар дүрт тапкырда киселә, ә имәнлекләрдә - киләчәктә имәннең урман культураларын агачның икеләтелгән биеклегендә булдыру шарты белән киселә. Кисүнең мондый төре бер үк яшьтәге җилгә чыдам, яхшы дренажланган туфракта үсүче (беренче чиратта йомшак яфраклыларда, кыйммәтле

токымнарның икенче ярусы һәм яшь үсентеләр булган) урман үсентеләренә карата башкарыла.

Полоса аша кисүләр кискән вакытта тотрыклылыгын югалтучы агачларга карата кулланылмый.

Тигез-эзлекле, төркемле-эзлекле (чокыр-чокыр), кара полосалы эзлекле, озак итеп-эзлекле кисүләрнең соңгысы бары тик диләнкедә яшәргә яраклы, урман утыртмаларын формалаштыруны тәэмин итә алырдай йомык яшь урманны формалаштырганнан соң гына башкарыла.

Кисү башкарылган урыннарны кисенте калдыкларыннан чистарту үзагач әзерләү белән берлектә башкарыла.

## 2.2. Урманнардан чәер әзерләү өчен файдалану нормативлары, параметрлары һәм вакытлары

Урманнарны чәер әзерләү өчен файдалану РФ УК 31 статьясы, 24.01.2012 ел, №23 Рослесхоз боерыгы белән расланган Чәер әзерләү кагыйдәләре белән регламентлана.

Чәер әзерләү ылысслы үсентеләрнең кайрыларына кирт салу, чәерне саклау һәм аны урманнан читкә чыгару рәвешендәге эшкуарлык эшчәнлегеннән гыйбарәт.

Гражданнар, юридик затлар чәер әзерләүне урман кишәрлеге арендасы килешүе нигезендә гамәлгә ашыра.

Урман кишәрлеге арендасы килешүе 10 елдан 49 елга кадәр вакытка төзелә.

Чәер әзерләү үзагач әзерләүгә билгеләнгән урманнарда башкарыла.

Кирт салуга өлгергән һәм картайган урман утыртмалары тапшырыла:

– I - IV бонитет класслы нарат утыртмалары;

– I - III бонитет класслы чыршы утыртмалары;

– I - III бонитет класслы карагай утыртмалары;

– I - III бонитет класслы урта яшьле, өлгереп килүче һәм өлгергән ак чыршы утыртмалары.

Кирт салуга яраклы дип сәламәт, сизелерлек җитешсезлекләре булмаган түбәндәге диаметрлы кәүсәле агачлар санала: 20 см һәм аннан артмаган наратлар һәм карагайлар, 24 см һәм аннан артмаган чыршылар.

Сәламәт, кәүсәсенең диаметры 16 сантиметрдан алып 20 сантиметрга кадәр булган нарат һәм карагай агачлары кирт салу өчен кисәренә кимендә 2 ел кала тәкъдим ителергә мөмкин.

Түбәндәгеләргә кирт салу тыела:

– аларны бетергәнчегә хәтле зарарлы организмнар чыганакларындагы урман утыртмаларына;

– урман янгыннары, зарарлы организмнар һәм башка тискәре факторлар нәтиҗәсендә зарарланган һәм зәгыйфьләнгән урман утыртмаларына;

– Россия Федерациясе законнары нигезендә үзагач әзерләү максатында өлгергән һәм картайган урман утыртмаларын тоташ яки сайланма кисүләр рөхсәт ителмәгән урманнардагы урман утыртмаларына;

– даими диләнке кишәрлекләрендә, урман-орлыклык плантацияләрендә, генетик резервацияләрдә урнашкан урман утыртмаларына, һәм шулай ук полюс агачларына, орлыклыкларга, орлык чәчәклекләренә һәм полосаларына.

Кирт салуга түбәндәгеләр җәлеп ителергә мөмкин:

– агачлар составында урман утыртмаларындагы гомуми үзагач запасының 40 процентыннан азрак нарат катнашмалы урман утыртмалары;

– сазлыклы туфраклардагы IV бонитет класслы һәм V бонитет класслы нарат утыртмалары;

– наратлы аралыклар;

– үз билгеләнешен үтәгән нарат орлыклыклары, орлыклык полосалары һәм чәчәклекләре;

– сайланма кисүгә билгеләнгән нарат агачлары;

– 2-3 гектарга кадәр мәйдан биләүче урман утыртмалары.

Кирт салуның 10-15 еллык вакытын тәшкил итәрлек өлгергән һәм картайган нарат утыртмалары җитеп бетмәгәндә, өлгереп килүче, кирт салганнан соң кисү яшенә җитәчәк һәм кисүгә билгеләнәчәк агачларга кирт салу рөхсәт ителә.

### 2.2.1. Агачларга кирт салу фонды

Урманчылыкның агачларга кирт салу Урманчылыкта юк (2.2.1 таблица).

2.2.1 таблица

**Агачларга кирт салу фонды**

Мәйданы, га

| № п/п | Күрсәткечләр | Кирт салу урманнарның максатчан билгеләнеше | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Саклык урманнары | Эксплуатация урманнары | Җәмгысе |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 1. | Кирт салуга яраклы булган өлгергән һәм картайган утыртмалар барлыгы: | - | - | - |
| 1.1 | Алардан: | | | |
| | - кирт салуга җәлеп ителмәгән | - | - | - |
| | - кирт салу өчен отышлы түгел | - | - | - |
| 2. | Кирт салу өчен ел саен алына торган күләм | - | - | - |

### 2.2.2. Кирт салу төрләре

Кирт салу төрләре:

– гади кирт салу;

– А һәм Б төркемнәренә караган чәер чыгару стимуляторлары белән кирт салу;

– хлорлы известь белән кирт салу;

– күкерт кислотасы белән кирт салу

2.2.2 таблица

**Кирт салу төрләре**

| Кирт салу төрләре, стимулятор | Кирт салу категорияләре |
|---|---|
| 1 | 2 |
| Гади кирт салу | I, II, III |
| А һәм Б төркемнәренә караган чәер чыгару стимуляторлары белән кирт салу | I, II, III |
| Хлорлы известь белән кирт салу | I, II |
| Күкерт кислотасы белән кирт салу | |
| 50% лы куертылган әчкелтем белән | I |
| 75% лы куертылган әчкелтем белән | II |

## 2.2.3. Агачтагы каррлар күләме һәм, агачның диаметрына карап, каррлар арасындагы каешлар киңлеге

Төрле категориядәге кирт салу өчен агач кәүсәләрендәге каррлар арасында каешларның гомуми киңлеге һәм каррлар күләме 2.2.3.1 таблицада китерелгән

2.2.3.1 таблица

**Төрле категориядәге кирт салу өчен агач кәүсәләрендәге каррлар арасында каешларның гомуми киңлеге һәм каррлар күләме**

| Агач кәүсәсенең 1,3 метр биеклектәге диаметры, см | I категория | | II категория | | III категория | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | агач кәүсәсен-дәге каррлар саны, данә | каррлар арасында-гы каешлар-ның гомуми киңлеге, см | агач кәүсәсендәге каррлар саны, данә | каррлар арасында-гы каешлар-ның гомуми киңлеге, см | агач кәүсәсен-дәге каррлар саны, данә | каррлар арасында-гы каешлар-ның гомуми киңлеге, см |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| 20 | 1 | 20 | 1 | 30 | - | - |
| 24 | 1-2 | 20 | 1-2 | 30 | - | - |
| 28 | 1-2 | 20 | 1-2 | 30 | 1 | 28 |
| 32 | 1-2 | 20 | 1-2 | 32 | 1 | 32 |
| 36 | 1-2 | 20 | 1-2 | 36 | 1 | 36 |
| 40 | 1-2 | 24 | 1-2 | 40 | 1 | 40 |
| 44 | 2 | 24 | 2 | 44 | 1 | 44 |
| 48 | 2 | 24 | 2 | 48 | 1 | 48 |
| 52 | 2 | 30 | 2 | 52 | 1 | 52 |
| 56 | 2 | 30 | 2 | 56 | 1 | 56 |
| 60 | 2 | 30 | 2 | 60 | 1 | 60 |
| 60 артык | 2-3 | 40 | 2-3 | Агач кәүсәсенең | 2 | Агач кәүсәсенең |

| Агач кәүсәсенең 1,3 метр биеклектәге диаметры, см | I категория | | II категория | | III категория | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | агач кәүсәсен-дәге каррлар саны, данә | каррлар арасында-гы каешлар-ның гомуми киңлеге, см | агач кәүсәсендәге каррлар саны, данә | каррлар арасында-гы каешлар-ның гомуми киңлеге, см | агач кәүсәсен-дәге каррлар саны, данә | каррлар арасында-гы каешлар-ның гомуми киңлеге, см |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| | | | | диаметрына тигез | | 1/2 диаметрына тигез |

Күкерт кислотасы ярдәмендә кирт салганда чәер чыгару стимуляторы буларак каррлар арасындагы каеш киңлеге 4 см арта.

Урман утыртмаларын соңгы тапкыр кисү елында бер карр арасындагы каешны 10 см дан ким булмаган киңлектә калдырып, кирт салу рөхсәт ителә.

Каррлар агач кәүсәсе буйлап тигез урнаша. Әгәр дә каррларны тигез итеп урнаштыру мөмкин булмаса, каррлар арасындагы каешның минималь киңлеге 10 см дан ким булмаска тиеш. Каррлар арасындагы каешлар агачның бары тик сәламәт өлешендә генә урнаштырылырга тиеш.

15 таблицада күрсәтелгәннәргә карата каррлар арасындагы каешларның билгеләнгән гомуми киңлеген яки каррларның киңлеген киметү рөхсәт ителми.

Нарат урман утыртмаларына кирт салганда чәер чыгару стимуляторларын файдаланырга рөхсәт ителә. Бер кирт салу чоры дәвамында бер үк агачларда чәер чыгаруның төрле стимуляторларын файдалану рөхсәт ителми.

Чәер чыгару буенча барлык стимуляторлар актив матдәләрнең һәм аларның төрле концентраттагы катнашмаларының судагы эретмәсе рәвешендә кулланыла. Хлорлы известь паста рәвешендә кулланыла. Күкерт кислотасы сыек хәлдә, капрон яисә каолин белән куертылып кулланыла.

Чәер чыгару стимуляторлары аларны куллану буенча күрсәтмәләргә катгый нигезләнеп кулланылырга тиеш.

Сазланган туфракларда үсеп киткән нарат урман утыртмаларына һәм зәгыйфьләнгән нарат урман утыртмаларына кирт салганда күкерт кислотасын куллану рөхсәт ителми.

Күкерт кислотасы ярдәмендә кирт салынучы нарат урман утыртмалары кирт салу вакыты узу белән кисүгә тапшырылырга тиешле.

Күкерт кислотасы белән кирт салганда беренче һәм һәр кирт салу чорында 3-4 мм тирәнлектә күкерт кислотасын кулланмыйча гына саклык кисемнәре ясалырга тиеш.

Туктатып торуның, яңарту адымының, яңарту һәм буразна тирәнлекләренең мөмкин булган чик күрсәткечләре 2.2.3.2 таблицада күрсәтелгән.

2.2.3.2 таблица

**Туктатып торуның, яңарту адымының, яңарту һәм буразна тирәнлекләренең мөмкин булган чик күрсәткечләре**

| Кирт салу төре, стимулятор | Кирт салу категориясе | Туктатып тору кимендә, тәүлек | Яңарту адымы артмаган, мм | Яңарту тирәнлеге артмаган, мм | Буразна тирәнлеге артмаган, мм |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| Гади кирт салу | I | 2 | 15 | 6 | 8 |
| | II-III | 3 | 15 | 4 | 6 |
| А һәм Б төркемнәренә караган чәер чыгару стимуляторлары белән кирт салу | I | 3 | 20 | 4 | 6 |
| | II-III | 4 | | 4 | 6 |
| Хлорлы известь белән кирт салу | I | 7 | 30 | 4 | 6 |
| | II | 10 | 40 | 4 | 6 |
| Күкерт кислотасы белән кирт салу<br>50% каолин белән куертылган<br>75% каолин белән куертылган | I<br>II | 7<br>14 | 40<br>50 | 2<br>2 | 3<br>3 |

Сайланма кисүләргә билгеләнгән нарат урман утыртмаларына беренче кисүгә кабул ителгәнче 5 ел алдан кирт салына. Нарат урман утыртмаларына кирт салу озынлыгы кисүләр арасындагы чор озынлыга бәйле, әмма 15 елдан артып китә алмый.

Сайланма киселергә тиешле төрле яшьле нарат урман утыртмаларында беренче кисүгә кадәр 10 елдан алдан кирт салынырга тиеш. Шул ук вакытта беренче кабул итүдә киселергә тиешле агачларга гына кирт салынырга тиеш.

### 2.2.4. Урманнарны чәер әзерләү өчен файдалану вакытлары урман нарат утыртмаларына кирт салу вакыты 15 елдан артмаска тиеш.

Кирт салу озынлыгына һәм нарат урман утыртмаларының кисүгә тапшырылу вакыты җитүгә карап, кирт салу өч категория буенча башкарыла:

I категория буенча – 1-3 елдан соң киселергә тиешле нарат урман утыртмаларына;

II категория буенча – 4-10 елдан соң киселергә тиешле нарат урман утыртмаларына;

III категория буенча – 11-15 елдан соң киселергә тиешле нарат урман утыртмаларына.

Категорияләр буенча кирт салу озынлыгы 11.1 таблицада китерелгән.

2.2.4 таблица

**Кирт салу озынлыгы**

<table>
<tr><th>Кирт салу вакыты, ел</th><th>Кирт салу чоры, эксплуатация башыннан бирле үткән еллар</th><th>Кирт салу вакыты, ел</th><th>Кирт салу категориясе</th></tr>
<tr><td>1</td><td>2</td><td>3</td><td>4</td></tr>
<tr><td rowspan="3">15</td><td>1 алып 5 нче буйлап</td><td>5</td><td>III</td></tr>
<tr><td>6 алып 12 нче буйлап</td><td>7</td><td>II</td></tr>
<tr><td>13 алып 15 нче буйлап</td><td>3</td><td>I</td></tr>
<tr><td rowspan="2">10</td><td>1 алып 7 нче буйлап</td><td>7</td><td>II</td></tr>
<tr><td>8 алып 10 нчы буйлап</td><td>3</td><td>I</td></tr>
</table>

Нарат урман утыртмалары бер категориядән икенчесенә күчкәндә кирт салуның технологик параметрлары үзгәрә.

## 2.3. Урманнардан агач булмаган урман ресурслары әзерләү һәм җыеп алу өчен файдалану нормативлары, параметрлары һәм вакытлары

Урманнарны агач булмаган урман ресурсларын әзерләү һәм җыеп алу өчен файдалану РФ УК 32 ст. һәм "Агач булмаган урман ресурсларын әзерләү һәм җыеп алу кагыйдәләрен раслау турында" 05.12.2011 ел, №512 Рослесхоз боерыгы, "Татарстан Республикасында урманнарны файдалану турында" 22.05.2008 ел, №22-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы белән Регламентлана.

Агач булмаган урман ресурсларына түмәрләр, каен тузы, агач һәм куак кайрылары, чыбык-чабык, ботаказык, чыршы, ак чыршы, нарат ботаклары, чыршылар һәм (яки) яңа ел бәйрәме өчен башка ылыслы агач токымнары, мүк, урман түшәмәсе, камыш, кыяклылар һәм шуңа охшаш урман ресурслары керә.

Агач булмаган урман ресурсларын әзерләү һәм җыеп алу гражданнар, юридик затлар тарафыннан эшмәкәрлек максатларында, һәм шулай ук гражданнар тарафыннан - шәхси кирәк-яраклар өчен башкарыла.

Эшкуарлык эшчәнлеге максатларында агач булмаган урман ресурсларын әзерләү һәм җыеп алу урман кишәрлеге арендасы килешүе нигезендә башкарыла.

Урман кишәрлеге арендасы килешүе 10 елдан 49 елга кадәр вакытка төзелә.

Үз кирәк-яракларың өчен агач булмаган урман ресурсларын әзерләү һәм җыеп алу ирекле һәм бушлай башкарыла.

Аларның чикләрендә урманнардан агач булмаган урман ресурсларын әзерләү һәм җыеп алу рөхсәт ителгән кварталлар исемлеге 1.2 таблицада күрсәтелгән.

Урман кишәрлеге арендасы килешүе яки урман утыртмаларын сату-алу килешүе буенча үзагач әзерләгәндә кисүдән калган агач булмаган урман ресурсларын әзерләү һәм җыеп алу өстәмә килешү төзүне таләп итми һәм урманнан файдалануның аерым төре булып саналмый.

Россия Федерациясе Кызыл китабына, Татарстан Республикасы Кызыл китабына кертелгән, "Наркотик һәм психотроп матдәләр турында" 08.01.1998 ел,

№3-ФЗ Федераль закон нигезендә наркотик матдәләр булып саналучы, һәм шулай ук алардан үзагач әзерләү рөхсәт ителми торган агач һәм куак төрләре (токымнары) исемлегенә кертелгән үсемлек төрләрен агач булмаган урман ресурсларын әзерләү һәм җыеп алу буенча куллану тыела.

Урман кишәрлекләрен агач булмаган урман ресурсларын әзерләү һәм җыеп алу өчен арендалаучы гражданнар һәм юридик затлар түбәндәгеләргә хокуклы:

– урманнардан аренда килешүе шартлары нигезендә файдаланырга;

– урман инфраструктурасын булдырырга (урман юллары, урман саклыкханәләре һәм башкалар);

– бирелгән урман кишәрлекләрендә әвеслекләр һәм башка вакытлы төзелмәләр урнаштырырга;

– аларны гамәлгә ашыру Россия Федерациясенең урман законнары таләпләренә каршы килмәгән башка хокукларга ия булырга.

Урман кишәрлекләрен агач булмаган урман ресурсларын әзерләү һәм җыеп алу өчен арендалаучы гражданнар һәм юридик затлар түбәндәгеләрне бурычлы:

– урманнарны үзләштерү проектын төзергә;

– урманнардан урманнарны үзләштерү проекты һәм әлеге урман хуҗалыгы регламенты нигезендә файдаланырга;

– урман кишәрлеге арендасы килешүе шартларын үтәргә;

– гражданнарның сәламәтлегенә, әйләнә-тирә мохиткә зарар китерүгә юл куймаска;

– урманнардан туфрак эрозиясен булдырмый торган, урманнарның торышына һәм аларны торгызуга, һәм шулай ук су объектларына һәм башка табигый объектларга тискәре йогынтыны булдырмый торган яисә чикли торган ысуллар ярдәмендә файдаланырга;

– урманнарда янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен, урманнарда санитар иминлек кагыйдәләрен, һәм шулай ук урманнарны карап тоту кагыйдәләрен үтәргә;

– урманнарда санитар иминлек булдыру максатларында санитар-сәламәтләндерү чараларын башкарырга (һәлак булган һәм зарарланган урман утыртмаларын кисәргә, урманнарны чүп-чардан, пычраклардан һәм башка тискәре йогынтылардан чистартырга);

– ел саен урман декларациясен тапшырырга;

– квартал саен тапшырыла торган 1-ВЛ, 1-ОЗЛ һәм 1-ИЛ хисапларын тапшырырга;

– Россия Федерациясе законнары белән каралган башка йөкләмәләрне үтәргә.

### 2.3.1. Урманнардан агач булмаган урман ресурсларын аларның төрләре буенча әзерләү һәм җыеп алу өчен файдалануның нормативлары (ел саен мөмкин булган күләмнәре) һәм параметрлары

Агач булмаган урман ресурсларын әзерләү һәм җыеп алу буенча урманнардан рөхсәтле файдалануның ел саен мөмкин булган күләмнәре 2.3.1.1 таблицада китерелгән.

2.3.1.1 таблица

**Агач булмаган урман ресурсларын әзерләү буенча урманнардан рөхсәтле файдалану параметрлары**

| № п/п | Агач булмаган урман ресурсы төре | Үлчәү берәмлеге | Ел саен мөмкин булган әзерлек күләме |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Каен тузы | т | 15 |
| 2. | Агачларның кайрысы, мунчала | т | 0,5 |
| 3. | Озын корыган ботак | т | 50 |
| 4. | Ботак азык | т | 150 |
| 5. | Чыршы һәм нарат ботаклары | т | 245 |
| 6. | Чыршылар һәм (яки) яңа ел бәйрәмнәре өчен башка ылысслы токым агачлары | мең данә | 1,5 |
| 7. | Мунчала | т | 16,5 |

Агач булмаган урман ресурсларының классификациясе (Сударев һәм б. 1991 ел) нигезендә ресурслар 3 төркемгә бүлгәләнә, алар барлыкка килү (әзерләү) урыны, ресурсны исәпкә алу (бәяләү) ысулы, файдалану холкы белән аерылалар (2.3.1.2 таблица).

2.3.1.2 таблица

**Агач булмаган урман ресурсларының классификациясе**

| Агач булмаган урман ресурслары | Билгеләмә, ГОСТ, ОСТ, ТУ |
|---|---|
| 1 | 2 |
| Агач биомассасы компонентлары (диләнке калдыклары) | |
| Калын ботаклар | Агач нигезендә 3 см артык юанлыктагы кәүсәдән чыгучы агачланган ян үсентеләр, ГОСТ 17462-84 |
| Нечкә ботаклар | Агач нигезендә 3 см һәм аннан азрак юанлыктагы агач ботакларыннан чыгучы агачланмаган ян үсентеләр, ГОСТ 17462-84 |
| Агачларның яшел өлеше | Ылыслар, яфраклар, бөреләр һәм агач-куак үсемләренең агачланмаган үрентеләре, түбәндәгеләрдән гайре: эт шомырты, агулы сумаха, бүре җиләге, кара аю баланы, еламсар тал, чикләвек, бук, кабар агачы, имән, чикләвек куагы - нигезендә 1 см кимрәк юанлыкта, ГОСТ 21769-84 |
| Чыршы, каен, юкә, башка токым кайрылары | Үзагачны каплаучы кәүсәнең, калын ботакларның, нечкә ботакларның тышкы өлеше, ГОСТ 17462-84 |
| Нарат, башка | Сәнәгать эшкәртүе һәм ягулык рәвешендә куллану өчен билгеләнгән |

| Агач булмаган урман ресурслары | Билгеләмә, ГОСТ, ОСТ, ТУ |
|---|---|
| 1 | 2 |
| токымнарның түмәр үзагачы | агачның тамыр өлеше һәм тамырлары, ГОСТ 17462-84. |
| Озын корыган ботак | Агачларның 4 см кадәрге юанлыктагы нечкә кәүсәләре, ТУ 463-8-766-79. |
| Урманнардан исән чакта файдалану ресурслары | |
| Чәер | Сумалалы матдә, ылыслы агачларны җәрәхәтләгәндә бүленеп чыга, ОСТ 13-428-82 |
| Баррас | Куеланган (каткан) чәер - түбән бонитетлы нарат утыртмаларын киртләгәндә бүленеп чыгучы төп продукт, ОСТ 13-197-84 |
| Чыршы чәере | Ябышучан (уалучан) чыршы чәере, кәүсәләр зарарланганда бүленеп чыга, ТУ 13-284-80 |
| Башка урман ресурслары | |
| Тал һәм башка токым үсентеләре | Җиһаз үрү, әзерләү өчен (ТУ56-44-86), дуплау матдәләрен (ГОСТ 6663-74) әзерләү өчен кулланылучы агач-куак токымнары үсентеләре һ.б.ш. |
| Яңа ел чыршылары | ТУ 56 РСФСР 41-81 |

Чыгарылган үзагачның 1000 м3 карата агач булмаган урман ресурсларыннан беренчел алынган продукцияне хисаплау мисалы 2.3.1.3 таблицада китерелгән.

2.3.1.3 таблица

**Алып чыгылган үзагачның 1000 м3 алынган агач булмаган беренчел продукция (хисаплау мисалы)**

| Агач булмаган урман ресурслары | Табигый чагылыштагы нормативлар, м3 | | Беренчел продукция | Продукция берәмлегенә карата чимал тотылу нормасы | Ресурслардан табигый чагылыштагы продукциянең чагыштырмача күләме, % | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | калдыклар барлыкка килүдән (потенциаль ресурслар) | кулланырга яраклы (икътисади яктан мөмкин булган ресурслар) | | | потенциаль | икътисади яктан мөмкин булган |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| Калын ботаклар | 110 | 24 | Технологик чимал, м3 | 1,3 | 84,6 | 18,5 |
| Нечкә ботаклар | 90 | 20 | Агач яшеллеге, т | 2,7-3,3 | 30,0 | 6,7 |
| Кайры | 100 | 70 | Дуплау кайрысы, т | 2,1-3,6 | 39,2 | 24,8 |

| Агач булмаган урман ресурслары | Табигый чагылыштагы нормативлар, м3 | | Беренчел продукция | Продукция берәмлегенә карата чимал тотылу нормасы | Ресурслардан табигый чагылыштагы продукциянең чагыштырмача күләме, % | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | калдыклар барлыкка килүдән (потенциаль ресурслар) | кулланырга яраклы (икътисади яктан мөмкин булган ресурслар) | | | потенциаль | икътисади яктан мөмкин булган |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| Агач төпләре | 30 | 15 | Нарат агачы төбе, т | 5,4 | 5,6 | 2,8 |
| Озын корыган ботак | 110 | 77 | Төрле токымлы һәм озынлыктагы корыган ботаклар, м3 | 1,1 | 100,0 | 70,0 |

Агачның яшел өлеше – яңа көе азык (ботаказык) яки терлекчелек өчен витаминлы азык продуктлары әзерләү буенча чимал сыйфатында кулланылучы ылыслар, яфраклар (бөреләр) һәм төрле агач һәм куак токымнарының 0,8 см кадәр диаметрлы агачланмаган ботаклары (үсентеләре).

Техник яшеллек – агачның яшел өлешенең эшкәртү өчен кулланылучы масса өлеше. Агач яшеллегенең гомуми массасыннан наратта ул 35%, чыршыда – 50%, каенда – 20 % тәшкил итә.

Ылыслы яшеллек запасларын билгеләү. Агач яшеллеген әзерләү агачларны кисү нәтиҗәсендә аударылган барлык яшь төркемнәрендәге утыртмалар буенча башкарыла. Агач яшеллеген диаметры (d=1,3 м) кимендә 18 см булган үсеп утыручы өлгергән өлешеннән агач кәүсәсенең 30% озынлыгында нәзек ботакларын кисеп алу юлы белән әзерләү рөхсәт ителә.

Агач (техник) яшеллеге запасларын билгеләүне региональ норматив-белешмә таблицасын кулланып башкаралар.

1 гектардагы техник яшеллек запасын билгеләү өчен әлеге утыртманың 1 гектарга карата агачларының уртача санын һәм аларның юанлык баскычлары буенча урнашуын белергә кирәк. Әгәр дә андый белешмәләр булмаса, 0,5 гектар күләмендә кулланып карау мәйданнарын ясарга кирәк һәм, агачларны санап, 1 гектар буенча һәр юанлык баскычындагы агачларның уртача санын ачыкларга. Килеп чыккан санга бер агачтан чыккан техник яшеллекне тапкырлап, 1 гектар буенча запасны ачыклыйлар, ә аннан соң чимал базасының барлык мәйданы буенча ресурсларын да. Хисап эшләрен алып барганда шулай ук 1 м3 карата билгеле агач токымының кәүсә массасыннан чыгучы уртача техник яшеллекне дә исәпкә алырга мөмкин.

Кабык, ылыслар, үзагачлар, органик булмаган һәм органик агач яшеллеге кушылмалары ГОСТ 21769-84 таләпләренә туры килергә тиеш.

Азык максатларында агач яшеллеген әзерләгәндә эт шомыртын, бүре җиләген, аю баланын, еламсар таллыкны, кабар агачын, имәнне куллану тыела.

Нарат һәм чыршы ботаклары запасларын билгеләү. Ак чыршы, нарат һәм чыршы ботакларының запасларын билгеләү 2.3.1.4, 2.3.1.5 региональ норматив-белешмә таблицаларыннан файдаланып башкарыла.

2.3.1.4 таблица

**Нарат ботаклары массасы**

| D=1.3 м, см | Бер нарат агачыннан ылыслы ботаклар массасы, кг, биеклек разрядына карап | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | Ia | I | II | III | IV |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| 12 | 13 | 12 | 11 | 10 | 9 |
| 16 | 20 | 18 | 17 | 15 | 14 |
| 20 | 28 | 25 | 23 | 21 | 19 |
| 24 | 34 | 31 | 29 | 27 | 25 |
| 28 | 41 | 38 | 36 | 32 | 29 |
| 32 | 48 | 44 | 41 | 37 | 34 |
| 36 | 54 | 48 | 46 | 42 | 38 |
| 40 | 61 | 56 | 51 | 48 | 43 |
| 44 | 66 | 60 | 57 | 52 | 47 |
| 48 | 72 | 67 | 61 | 56 | 52 |
| 52 | 77 | 72 | 66 | 60 | 56 |
| 56 | 82 | 76 | 70 | 66 | 59 |

2.3.1.5 таблица

**Чыршы ботаклары массасы**

| D=1.3 м, см | Бер нарат агачыннан ылыслы ботаклар массасы, кг, биеклек разрядына карап | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | Ia | I | II | III | IV |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| 8 | 10 | 9 | 8 | 7 | 7 |
| 12 | 21 | 18 | 16 | 15 | 13 |
| 16 | 38 | 31 | 44 | 24 | 20 |
| 20 | 63 | 53 | 29 | 37 | 31 |
| 24 | 86 | 72 | 60 | 50 | 42 |
| 28 | 125 | 104 | 80 | 67 | 56 |
| 32 | 150 | 126 | 105 | 88 | 67 |
| 36 | 195 | 163 | 125 | 104 | 87 |
| 40 | 229 | 192 | 146 | 123 | 103 |
| 44 | 269 | 224 | 172 | 144 | 110 |
| 48 | 289 | 239 | 200 | 167 | 128 |
| 52 | 331 | 276 | 232 | 177 | 148 |

Нарат түмәре сагызы дип өлгергән нарат түмәренең һәм тамырларының чәерле матдәләрен алу буенча чимал буларак кулланыла торган сәламәт өлеше атала. Агачларны кискәннән соң түмәрләр тора-бара чери башлый. Черү процессы иң беренче чиратта сагызы аз булган түмәр өлешенә тия. Сагызлы матдәләр

агачка черүгә каршы тотрыклылык бирә. Башта түмәрнең тышкы ягы һәм вак тамырлары чери. Түмәрнең аз сагызлы өлеше черү процессы бер үк вакытта түмәр сагызы әзерләү өчен киләчәктә куллану җәһәтеннән түмәрнең өлгерү процессы да була.

Түмәрнең өлгергәнлеге торышына карап билгеләнә. Түмәрнең тышкы ягы черегәч һәм төп өлешеннән җиңел аерыла башлагач, түмәрне куллану өчен өлгергән дип санарга була. Өлгергән түмәрләр аралауга һәм чистартуга җиңел бирелә. Түмәр өлгергән вакытта ул сагызлы матдәләргә байый, сагызы азрак булган түмәрләр тизрәк череп бетә. Әйтик, 15 елдан соң түмәр сагыз әзерләү өчен өлгергән дип санала, бу вакытта диләнкедә барлык түмәрләрнең 70% тирәсе кала. Әгәр дә әзерлек эшләре 25 елдан соң алып барылса, ул вакытта элекке диләнкедә түмәрләрнең башлангыч санынннан нибары 40% тирәсе генә сакланып калачак. Иң эре һәм сагыз матдәләре иң югары булган түмәрләр кала.

Агачны кискәннән соң, түмәрнең җирдә булган вакытына карап, яңа (5 яшькә кадәрге) өлгереп килүче (5-10 яшь) һәм өлгергән (10 яшьтән олы) түмәрләрне аерып чыгаралар.

Нарат сагызының өлгерү процессы туфрак-климат һәм урманчылык факторларына бәйле һәм, кагыйдә буларак, 10-15 елга кадәр дәвам итә. Көньяк районнарда өлгерү тизрәк бара, төньякта – акрынрак. Коры туфракларда, җитәрлек дымы булган туфракларга караганда, өлгерү акрынрак бара.

Киселгән җирләрдә барыннан да бигрәк эре үзәкле түмәрләр озаграк саклана, андый түмәрләрнең саны кисеп ташланган агач сыйфатламасына бәйле.

Түмәр сагызы запасларын билгеләү. Түмәр сагызын әзерләү буенча чимал базасы буларак түбәндәгеләр хезмәт итә:

– яңа һәм коры туфраклары белән торгызылмаган нарат кисентеләре;

– нарат агачлары киселгән урыннардагы 13 яшькә кадәрге, I-IV бонитет класслы, тулылыгы 0,3-0,7 булган ылыслы утыртмалары белән һәм 0,3-0,8 булган яфраклы утыртмаларындагы ылыслы һәм яфраклы яшь агачлар, махсус саклanучы урыннардан кала;

– нарат кисүләрендә 4-5 яшьлек үсеп китү мөмкинлеге 40-50% булган урман культуралары (ябалдашлары кушылмаган культуралар) һәм 6-12 яшьлек 0,4-0,6 тулылыгы булган, рәт аралары киңлеге 2,5 метрдан артык;

– I-IV бонитет класслы ревизия чорындагы нарат диләнкеләре.

1 гектарга әзерләргә рөхсәт ителә торган түмәрләр саны (данә) урман культуралары булуга һәм аларның торышына карап билгеләнә.

Әзерләп куелучы түмәрләр саны:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1. | 0,5 метрга кадәр биеклекле: | 5 меңгә кадәр. данә/га | 175 |
| | | 5-8 меңгә кадәр. данә/га | 100 |
| 2. | 0,5-1,5 метрга кадәр биеклекле: | 3 меңгә кадәр. данә/га | 100 |
| | | 3-5 меңгә кадәр. данә/га | 75 |
| | | 5 меңнән артык. данә/га | - |
| 3. | 1,5 метрдан артык биеклекле: | 5 меңгә кадәр. данә/га | 50 |
| | | 5 меңнән артык. данә/га | - |

Табигый чыгышлы яшь агачлары белән берлектә яфраклы токымнарны кисеп ташлау:

1 метрга кадәр биеклекле: чикләүләрсез

3 метрдан биегрәк булган каенлыклар: 100

1,5-3 метрдан биек булган каенлыклар: 125

Урманнарның коры дала типларының алда китерелгән категорияләрендәге урманнарга таксация уздыру барышында 20 артык чыршысы булган наратлыкларны кисүнең күптән узган һәм 1 гектарга кимендә 50 түмәр булса, түмәр сагызын исәпкә алына. Шул ук вакытта 1 гектарга түмәрләр саны, түмәрләрнең уртача диаметры һәм сагызлылыкның өлгерү классы (киселгәннән соң узган вакыт) исәпкә алына. Түмәр сагызының өлгергәнлек класслары 2.3.1.6 таблицада китерелгән.

2.3.1.6 таблица

**Түмәр сагызының өлгергәнлек классы**

| Кисүдән соң үткән чор, ел. | Өлгергәнлек классы | Нарат агачы төбенең сыйфатламасы | Агач төпләренең өлгергәнлек классының тышкы билгеләре |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1-5 | I | Яшь | Төчлегән череми һәм үзәк белән бербөтенне тәшкил итә |
| 6-10 | II | Өлгереп килүче | Төчлегән күп яки аз дәрәҗәдә черегән, түмәрнең җир өстендәге өлешендә үзәгеннән көч белән аерыла, җир астында - аерылмый. |
| 11-15 | III | Өлгергән | Төчлегән сизелерлек черегән һәм үзәгеннән җиңел аерыла. |
| 16-20 | IV | Картайган | Төчлегән тулысынча черегән, үзәк чери башлаган |

1 гектарга түмәрләр саны сынау мәйданчыкларында тоташ санау, ленталы санау яисә исәпкә алу адымнары юлы белән билгеләнә (21 түмәр арасындагы аралар буенча билгеләнә торган уртача ераклык буенча).

Түмәр сагызы ресурслары, түмәрләрнең саныннан һәм диаметрыннан чыгып, региональ норматив-белешмә таблицаларны исәпкә алып билгеләнә.

Нормаль юкә агачларының 1 гектарыннан мунчала чыгышы 2.3.1.7 таблицада күрсәтелгән.

2.3.1.7 таблица.

**Нормаль юкә агачларының 1 гектарыннан мунчала чыгышы**

| Уртача диаметры, см | Агачларның тулылыгы | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | 0,3 | 0,4 | 0,5 | 0,6 | 0,7 | 0,8 | 0,9 | 1,0 |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
| 16 | 53 | 58 | 62 | 64,6 | 65,4 | 66,4 | 67 | 67,5 |
| 18 | 48,8 | 51,2 | 54,8 | 57 | 57,8 | 58,6 | 59,2 | 59,6 |
| 20 | 42 | 45,9 | 49,1 | 51,2 | 51,3 | 52,6 | 53,4 | 53,5 |
| 22 | 38 | 41,6 | 44,5 | 45,3 | 46,9 | 47,6 | 48 | 48,4 |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 24 | 34,9 | 38,2 | 40,9 | 42,6 | 43,1 | 43,8 | 44,2 | 44,5 |
| 26 | 31,8 | 34,8 | 37,2 | 38,9 | 39,3 | 39,9 | 40,3 | 40,6 |
| 28 | 29,4 | 32,2 | 34,4 | 35,9 | 36,3 | 36,9 | 37,2 | 37,5 |
| 30 | 27,1 | 29,7 | 31,7 | 33,1 | 33,5 | 34 | 34,3 | 34,6 |

Искәрмә. Мунчала запаслары кисүгә тапшырылучы утыртмалар өчен билгеләнә, түбәндәге формула буенча: V=0,1КxМxL , биредә V – мунчала чыгышы; К – утыртмадагы юкә составы коэффициенты; М – утыртма запасы; L – 1 м3 юкәдән мунчала чыгышы (таблица күрсәткече).

Агач үсентеләренең күп кенә төрләренең кабыгы дуплау сыйфатында күн сәнәгатендә кулланыла. Үсемлек рәвешендәге дуплау матдәләре арасында тал кайрысы беренче урыннарның берсен алып тора. Тал кайрысы белән эшкәртелгән күн эластик, йомшак һәм югары механик сыйфатларга ия була.

Талның кайбер төрләре (ак, кәҗә, уалучан, әйлән-бәйлән, кызгылт) кайрысыннан йонны, ефәкне, лайка күнен, җитен һәм мамык җепләрен буяу өчен буяулар әзерлиләр, салицил һәм гликозид алалар. Талның яшь кайрысы капчык материалы, баулар, шпагат әзерләү өчен кулланыла.

Тал кайрысының дуплау матдәләре – таннидлар – билгеле бер эрү ноктасы булмаган аморф (кристаллик булмаган) катышмалар. Таннидлар күләменең проценты зуррак булган саен, кайрының да дуплау матдәсе буларак сыйфаты югарырак була.

Кайрыдагы таннидлар саны асылда талның төренә бәйле. Таннидлыкка тәэсир итүче факторлар – үсемлекнең яше, талда кайрының урнашкан җире, әзерләү сезоны, үсү урыны шартлары.

Агач рәвешендәгеләрдән иң кыйммәте булган таллар арасында кәҗә, уалучан, биек, саз һәм биш яфрак таллар санала, алар кайрысында таннидлар 8% алып 12% кадәр. Агач-куак рәвешендәгеләрдән таннидлар иң күп булганы – өчьяфрак, коры кайрылы, соры һәм йонлач таллар. Кайрысында 7% да азрак таннидлар булганнарга кайрысыз төркем кертелә.

Иске һәм бөкеләнгән кайрыда, бер еллык яшь ботаклардагы кайрылар кебек үк таннидлар бик аз була. Төрләрнең күбесе өчен таннидлар 4-15 яшьтәге талларга хас. Кәүсәнең аскы өлешендәге кайрыда таннидлар өске өлешеннән күбрәк була.

Суты йөргәндә талда таннидлар кышкыга караганда шактый күп була, тал кайрысында дуплау матдәләренең иң күп күләме суты иң интенсив йөргән чакта – май башыннан алып июль уртасына кадәр була.

Таннидлар күләменә тал үсентеләренең кайда үсеп чыгулары да тәэсир итә. Уңдырышлырак туфраклар дуплау матдәләре тупланууга китерә.

Каен тузы әзерләүне исәпкә алу һәм аның үзенчәлекләре. Туз ике төрдә әзерләнә. Сутлы килеш – үсеп утыручы агачлардан һәм шомарткыч ярдәмендә (ышкып алу) – каенның аскы өлешеннән, утыннардан һәм аударылган агачлардан. Үсеп утыручы агачлардан туз әзерләү, кисү башланырга 1-2 ел кала, урман бүлемтегендәге агачлардан рөхсәт ителә, моңа диаметры 12 см ким булган һәм фанер әзерләү өчен билгеләнгән махсус сортлы агачлар керми.

Үсеп утыручы агачлардан каен тузы салдыру язгы чорда, агачның кайры астына һәм материалга китә торган өлешенә зыян китермичә генә, гомуми биклегенең яртысына кадәр башкарыла.

Аударылган агачлардан һәм корыган агачлардан шомарткыч ярдәмендә каен тузы әзерләү урман фондының бөтен территориясе буенча елы буена башкарылырга мөмкин.

Әзерләнгән каен тузы сыйфаты "Дегет җитештерү өчен каен тузы" ТУ 13-707-83 туры килергә тиеш. 1 м3 кәүсәле үзагачтан чыгучы каен тузы кг 2.3.1.8 таблицада китерелә.

2.3.1.8 таблица

**1 м3 кәүсәле агачтан туз чыгышы, килограммнарда**

| Сортиментларның исеме | Диаметры, см | Туз чыгышы | |
|---|---|---|---|
| | | Яңа алынган рәвештә | Җиңел-коры килеш |
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| Эре | 26 һәм аннан артык | 6,3 | 3,8 |
| Уртача | 14-24 | 7,2 | 4,3 |
| Вак | 13 | 2,2 | 1,3 |
| Утын | 13 һәм аннан артык | 2,2 | 1,3 |

Тал кайрысының чимал базасы елга үзәннәрендәге һәм дымлы урыннардагы куаклы үзәннәрнең, сазланган урманнардагы, ягъни дымы җиткән һәм уңдырышлы туфраклы урыннардагы табигый таллыклардан гыйбарәт.

Тал кайрысын әзерләү кайрысында дуплау матдәләре 7% ким булмаган талларда башкарыла (дымлылык 16%).

Агачсыман таллар: кәҗә талы – кайрының таннидлыгы 16%; уалучан, бишьяфрак – 10%.

Куаклыклар: соры, миндальсыман – кайрының таннидлыгы 17%; көлсыман, колаклы – 11; куе кызыл – 9.6; рус талы – 7-15; чыбыклы – 10; йонлач – 11; озын яфраклы, кара тал – 10.5; лапландия талы – 8-14; киң яфраклы – 11%. Түбән таннидлы таллар: ак тал һәм еламсар тал – кайрының таннидлыгы 6-7%.

Тал кайрысы әзерләү өчен 5 һәм аннан да олырак яшьле тал куаклары, 15 һәм аннан да зуррак яшьле тал агачлары яраклы. Үзагач запасы кимендә 5 м3/га булган алда күрсәтелгән тал төрләре исәпкә алынырга тиешле.

Яңа киселгән 1 м3 агачтан тал кайрысы уртача 65 кг чыга.

Тал кайрысы запасларын билгеләү, 1 гектарга тал үзагачы запасыннан чыгып, 2.3.1.9 таблица нигезендә башкарыла.

2.3.1.9 таблица

**1 гектарга тал үзагачы запасыннан чыгып, коры тал кайрысы массасы**

| Күләәме меңнәрчә йөз, дистә һәм бер. запас санында м3 | Кабык-кайры массасы, т сан бүлекләре буенча | | | | Күләәме меңнәрчә йөз, дистә һәм бер. запас санында м3 | Кабык-кайры массасы, т сан бүлекләре буенча | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | меңнәрчә | йөзләрчә | дистәләрчә | берәмеклә р | | меңнәрчә | йөзләрчә | дистәләрчә | берәмеклә р |
| | Тал куаклыклары | | | | | Агачсыман таллар | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
| 1 | 70 | 7 | 0,7 | 0,1 | 1 | 60 | 6 | 0,6 | 0,1 |
| 2 | 140 | 14 | 1,4 | 0,1 | 2 | 119 | 12 | 1,2 | 0,1 |
| 3 | 210 | 21 | 2,1 | 0,2 | 3 | 178 | 18 | 1,8 | 0,2 |
| 4 | 280 | 28 | 2,8 | 0,3 | 4 | 238 | 24 | 2,4 | 0,2 |
| 5 | 350 | 35 | 3,5 | 0,4 | 5 | 298 | 30 | 3,0 | 0,3 |
| 6 | 420 | 42 | 4,2 | 0,4 | 6 | 357 | 36 | 3,6 | 0,4 |
| 7 | 490 | 49 | 4,9 | 0,5 | 7 | 416 | 42 | 4,2 | 0,4 |
| 8 | 560 | 56 | 5,6 | 0,6 | 8 | 476 | 48 | 4,8 | 0,5 |
| 9 | 630 | 63 | 6,3 | 0,6 | 9 | 536 | 54 | 5,4 | 0,5 |

Мисал: 10 гектар мәйданлы бүлемтектә куаклы талдан үзагач запасы – 175 м3/га. Җиңел-корыган кайрының авырлыгы, таблица нормативларыннан чыгып, түбәндәгегә тигез: 7+4,9+0,4=12,3 т/га; 12,3 т/га*10 га=123 т.

Чыршы кайрысын исәпкә алу

Дуплау матдәләрен алу максатында чыршы кайрысын әзерләү диләнкеләрдә чыршыларны кисү чорында, сут бирү вакытында, 20 см кадәр диаметрлы өлгергән һәм картайган утыртмаларга карата башкарыла. Әзерләнгән 1 м3 чыршы үзагачыннан уртача 40 кг дуплау кайрысы чыга.

## 2.3.2. Агач булмаган урман ресурсларын җыеп алу буенча урманнардан файдалану вакытлары

Түмәр сагызын әзерләү теләсә нинди максатчан билгеләнештәге, ул утыртмаларга, яңа үсеп килүче һәм яшь агачларга зарар китерә алмый торган урманнарда рөхсәт ителә.

Түмәр сагызын әзерләү ысулы (кул белән, трактор белән, шартлатып һ.б.) аренда килешүендә күрсәтелә.

Эрозиягә каршы урманнарда; су объектлары ярларындагы, тау һәм чокыр сөзәклекләрендәге ярсаклагыч һәм туфраксаклагыч урман кишәрлекләрендә, һәм шулай ук 0,8-1,0 тулылыклы яшь агачлардан түмәр сагызы әзерләү рөхсәт ителми.

Туз әзерләү кисү өчен бүлеп бирелгән үсеп утыручы агачлардан кисәргә 1-2 ел кала (фанер төбәнәге һәм махсус сортимент әзерләү өчен билгеләнгән агачлардан гайре), шулай ук сайланма һәм тоташ кисү уздырылган башка диләнкеләрдәге яңа киселгән агачлардан рөхсәт ителә.

Үсеп утыручы агачлардан туз әзерләү язгы-җәйге һәм көзге чорда төп кабыкка зыян китерелмичә башкарыла. Шул ук вакытта әзерләү өчен кулланыла торган кәүсәнең өлеше агачның гомуми биеклегенең яртысыннан артмаска тиеш.

Корыган һәм ауган агачлардан туз әзерләү ел дәвамында башкарыла.

Агачларны туз әзерләү өчен кисү тыела.

Кабык һәм кайры әзерләү ел дәвамында агачларны һәм куакларны кисү белән берлектә башкарыла. Тал кайрысы язгы-җәйге чорда әзерләнә.

Тал кайрысы әзерләү өчен 5 һәм аннан да олырак яшьле тал куаклары, 15 һәм аннан да олырак яшьле тал агачлары яраклы.

Корыган ботакларны әзерләү Юан очының диаметры 4 см кадәр булган киселгән нәзек агач кәүсәләре, шулай ук агачларның киселгән ботак очлары, юан һәм нечкә ботаклары чыбык-чабык була. Чыбык-чабык ике категориягә бүленә: 2-4 м һәм 4 метрдан да артыграк.

Ботаказык әзерләү. Ботаклардан терлек азыгы дип 1,5 см кадәр калынлыктагы, кайбер яфраклы һәм ылыслы агачларның яшь ботакларыннан әзерләнгән һәм терлек азыгы буларак кулланыла торган урман материалына әйтәләр.

Ботаказык әзерләү өчен яфраклы (каен, усак, чаган, чикләвек, юкә, тирәк, корычагач һәм башкалар) һәм ылыслы (асылда чыршы) токым ботаклары кулланыла. Ботаклардан терлек азыгы әзерләү өчен нигездә җәй көне яфраклыларның яшь ботаклары кулланыла, ылыслылар – кыш көннәре.

Ботаклардан терлек азыгы әзерләү сайланма һәм тоташ урман кисүләр барышында гамәлгә ашырыла.

Ак чыршы, нарат, чыршы ботакларын әзерләү бары тик сайланма һәм тоташ урман кисүләре барышында диләнкедә киселгән агачлардан рөхсәт ителә.

Яңа ел бәйрәмнәре өчен чыршылар һәм (яисә) бүтән ылыслы агачлар әзерләү беренче чиратта махсус плантацияләрдә, чистартылырга тиешле урман кишәрлекләрендә (квартал араларында, минеральләштерелгән полосаларда, янгынга каршы чокырларда, янгынга каршы трассаларда һәм урман хуҗалыгы юлларында һәм яшь үсентеләрне саклау таләп ителми торган башка мәйданчыкларда) рөхсәт ителә.

Үзагач әзерләгән вакытта яңа ел бәйрәмнәре өчен чыршылар һәм (яисә) бүтән ылыслы агачларны әзерләү, шул исәптән киселгән агачларның очларыннан рөхсәт ителә.

Мүк, коелган яфраклар катламын, урмандагы аяк асты япмасын, камыш әзерләү төзелеш, шулай ук авыл хуҗалыгы терлекләре өчен азык һәм асларына салу материалы сыйфатында ярдәмче материал буларак һәм компост әзерләү өчен аларны куллану максатларында башкарыла. Аларны әзерләгәндә әйләнә-тирә мохиткә зыян китерелмәскә тиеш.

Мүкне әзерләү һәм җыеп алу вакытлары аренда килешүендә күрсәтелә.

Бензопычкы ярдәмендә мүк әзерләү бары тик Урманчылык хезмәткәрләре контролендә генә башкарыла.

Урмандагы аяк асты япмасын җыю бер үк мәйданда биш елга бер мәртәбә генә рөхсәт ителә. Урмандагы аяк асты япмасын җыю өлешчә, бөтен катламын алмыйча гына гамәлгә ашырылырга тиеш.

Урмандагы аяк асты япмасын җыю, бу елда коелачак яфраклар һәм ылыс, шулай ук япма табигый ашлама хасил итсен өчен, җәй азагында, әмма яфраклар коела башлаганчы ук башкарылырга тиеш.

Урманнардагы табигый һәм башка объектларны саклау функциясен башкаручы катламнарны җыеп алу тыела.

Урман кишәрлекләрендә агачларны әзерләү (казып алу) I яшь классындагы ылыслы утыртмаларда, I һәм II яшь классындагы яфраклы утыртмаларга карата гамәлгә ашырыла.

Урман кишәрлекләренең өстәмә урманчыгында куакларны әзерләү (казып алу) уртача куелыктагы яисә бөтенләй куе булган урманчыкта яки әзерләнә торган токым бик күп булган өлештә башкарыла. Әзерләнә торган төрнең калган куаклары саны бер гектарга кимендә 1000 данә булырга тиеш.

Чистартылырга тиешле урман кишәрлекләрендә (квартал араларында, минеральләштерелгән полосаларда, янгынга каршы чокырларда, янгынга каршы трассаларда һәм урман хуҗалыгы юлларында, печән чабу урыннарында, электр үткәргеч линияләрдә, су баскан зоналарда, автомобиль юлларына бүлеп бирелгән полосаларда, торбаүткәргечләрдә һәм яшь үсентеләрне саклау таләп ителми торган башка мәйданчыкларда), шулай ук сайланма яисә тоташ урман кискәндә диләнкеләрдә киселгән агачлардан яфраклы токымнардан (каен, усак, тал h.б.) мунча себеркесе, себерке һәм кисәкләргә турау өчен ботаклар һәм куаклыклар әзерләнә.

Агач яшеллеген әзерләү. Агач яшеллегенә яфраклы һәм ылыслы токымнарның яфраклары, бөреләре, ылыслары һәм нигезендә диаметры 8 мм кадәр булган яңа чыккан ботаклары керә.

Ылыслы-витаминлы он җитештерү өчен үзагач яшеллеген әзерләү бары тик сайланма һәм тоташ урман кисүләр барышында диләнкедә киселгән агачлардан рөхсәт ителә.

Ак чыршы маен җитештерү өчен агач яшеллеген (пихта ботакларын) әзерләү өлгергән пихта үсентеләрендә язгы-җәйге чорда диаметры кимендә 18 см булган үсеп утыручы агачлардан тере ябалдашының бары тик 30%ы озынлыгында гына үткен корал белән кисеп алу юлы белән кулдан әзерләү рөхсәт ителә. Бу чакта ботаклар кыеклап яисә тип-тигез итеп, тирәсен мунчалалатмыйча гына киселергә, ботакларның агачта калдырылган өлешенең озынлыгы кимендә 30 см ким булмаска тиеш.

Ак чыршы ботакларын бер үк урман утыртмалары буенча әзерләү 4-5 елдан соң гына рөхсәт ителә.

Гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен агач булмаган урман ресурсларын әзерләү һәм җыю тәртибе.

Нарат, чыршы һәм пихта ботакларын әзерләү, бары тик урман үсентеләрен кисү белән шөгыльләнүче затлар (урманнардан файдаланучылар) белән килештереп кенә, урман үсентеләрен кисү урыннарында киселгән агачлардан гына рөхсәт ителә.

Тал кайрысы киселгән агачлардан, бары тик урман үсентеләрен кисү белән шөгыльләнүче затлар белән килештереп кенә, язгы-җәйге чорда әзерләнә. Үсеп утырган агачлардан кайры каезлау тыела.

Корыган һәм дымлы каеннардан туз әзерләү ел дәвамында башкарыла. Үсеп утырган каеннардан каен тузы әзерләү бары тик агымдагы елда киселергә тиешле агачлардан бары тик урман үсентеләрен кисү белән шөгыльләнүче затлар белән килештереп кенә башкарыла.

Мунча себеркесе, себерке һәм кисәкләргә турау өчен, шулай ук терлек азыгына ботаклар һәм куаклыклар әзерләү чистартылырга тиешле урман кишәрлекләрендә (квартал араларында, минеральләштерелгән полосаларда, янгынга каршы чокырларда, янгынга каршы трассаларда һәм яшь үсентеләрне саклау таләп ителми торган башка мәйданчыкларда), шулай ук янгынга каршы, урман хуҗалыгы һәм урман әзерләү билгеләнгән ведомство юлларының бүлеп бирелгән полосасында, урман үсентеләрен кисү белән шөгыльләнүче затлар белән килештереп, урман хуҗалыгы чараларын гамәлгә ашырганда киселгән агачлардан башкарыла.

Яңа ел бәйрәмнәре өчен чыршылар һәм (яисә) бүтән ылыслы агачлар әзерләү чистартылырга тиешле урман кишәрлекләрендә (квартал араларында, минеральләштерелгән полосаларда, янгынга каршы чокырларда, янгынга каршы трассаларда һәм урман хуҗалыгы юлларында һәм яшь үсентеләрне саклау таләп ителми торган башка мәйданчыкларда) рөхсәт ителә. Әзерләү урыннары вәкаләтле орган белән язма рәвештә килештерелә.

Эшләнә торган диләнкеләрдә урман утыртмаларын кисүче затлар белән килештереп, үзагач әзерләгән вакытта, шул исәптән киселгән агачларның очларыннан яңа ел бәйрәмнәре өчен чыршылар һәм (яисә) бүтән ылыслы агачларны әзерләү рөхсәт ителә.

Мүк, урмандагы аяк асты япмасын җыю, бу елда коелачак яфраклар һәм ылыс шулай ук япма хасил итсен өчен, җәй азагында, әмма яфраклар коела башлаганчы ук, бер үк мәйданда җыйганда вәкаләтле орган белән килештерү буенча биш елга бер мәртәбә рөхсәт ителә. Урмандагы аяк асты япмасын җыю өлешчә, бөтен катламын алмыйча гына гамәлгә ашырылырга тиеш.

Урмандагы аяк асты япмасын җыю, бу елда коелачак яфраклар һәм ылыс, шулай ук япма табигый ашлама хасил итсен өчен, җәй азагында, әмма яфраклар коела башлаганчы ук башкарылырга тиеш.

Үз ихтыяҗларың өчен агач булмаган урман ресурсларының аерым төрләрен әзерләгәндә һәм җыйганда урман кишәрлекләрен файдалануга карата “Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында” 22.05.2008 ел, № 22-ТРЗ ТР Законы белән билгеләнгән таләпләр:

Туз әзерләү кисү өчен бүлеп бирелгән үсеп утыручы агачлардан кисәргә 12 ел кала (фанер төбәнәге һәм махсус сортимент әзерләү өчен билгеләнгән агачлардан гайре), шулай ук сайланма һәм тоташ кисү уздырылган башка диләнкеләрдәге яңа киселгән агачлардан рөхсәт ителә.

Үсеп утыручы агачлардан туз әзерләү язгы-җәйге һәм көзге чорда төп кабыкка зыян китерелмичә башкарыла. Шул ук вакытта әзерләү өчен кулланыла торган кәүсәнең өлеше агачның гомуми биеклегенең яртысыннан артмаска тиеш.

Корыган һәм ауган агачлардан туз әзерләү ел дәвамында башкарыла.

Агачларны туз әзерләү өчен кисү тыела.

Кабык һәм кайры әзерләү ел дәвамында агачларны һәм куакларны кисү белән берлектә башкарыла.

Чыбык-чабык әзерләү агач материалы әзерләү һәм урманнарны карау кагыйдәләре нигезендә башкарыла.

Ел дәвамында ботаклардан терлек азыгы әзерләү өчен агач-куак токымнары кулланыла.

Ботаклардан терлек азыгы әзерләү сайланма һәм тоташ урман кисүләр барышында гамәлгә ашырыла.

Ак чыршы, нарат, чыршы ботакларын әзерләү бары тик сайланма һәм тоташ урман кисүләре барышында диләнкедә киселгән агачлардан рөхсәт ителә.

## 2.4. Урманнардан азык-төлек урман ресурслары әзерләү һәм дару үләннәре җыеп алу өчен файдалану нормативлары, параметрлары һәм вакытлары

Азык-төлек урман ресурсларын әзерләү һәм дару үләннәрен җыеп алу өчен урманнардан файдалану Россия Федерациясе Урман кодексының 34, 35 статьялары, 05.12.2011 ел, №511 Рослесхоз боерыгы белән расланган Азык-төлек урман ресурсларын әзерләү һәм дару үләннәрен җыеп алу кагыйдәләре, "Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында" 22.05.2008 ел, №22-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы белән регламентлана.

Азык-төлек урман ресурсларына кыргый үсүче җимешләр, җиләкләр, чикләвекләр, гөмбәләр, орлыклар, каен суты һәм башка урман ресурслары керә.

Азык-төлек урман ресурсларын әзерләү һәм җыеп алу гражданнар, юридик затлар тарафыннан эшмәкәрлек максатларында, һәм шулай ук гражданнар тарафыннан - шәхси кирәк-яраклары өчен башкарыла.

Эшкуарлык эшчәнлеге максатларында азык-төлек урман ресурсларын әзерләү һәм җыеп алу урман кишәрлеге арендасы килешүе нигезендә башкарыла.

Урман кишәрлеге арендасы килешүе 10 елдан 49 елга кадәр вакытка төзелә.

Үз ихтыяҗлары өчен азык-төлек урман ресурсларын әзерләү һәм дару үләннәре җыю ирекле һәм бушлай башкарыла.

Аларның чикләрендә урманнардан азык-төлек урман ресурсларын әзерләү һәм җыеп алу рөхсәт ителгән кварталлар исемлеге 1.2 таблицада күрсәтелгән.

Россия Федерациясе Кызыл китабына, Татарстан Республикасы Кызыл китабына кертелгән, “Наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр турында” 08.01.1998 №3-ФЗ Федераль закон нигезендә наркотик чаралар дип танылган кыргый үсүче үләннәрне һәм гөмбәләрне әзерләү һәм җыю тыела.

Урман кишәрлекләрен азык-төлек урман ресурсларын һәм дару үләннәрен әзерләү һәм җыеп алу буенча арендалаучы гражданнар һәм юридик затлар түбәндәгеләргә хокуклы:

– урманнардан аренда килешүе шартлары нигезендә файдаланырга;

– урман инфраструктурасын булдырырга (урман юллары, урман саклыкханәләре һәм башкалар);

– бирелгән урман кишәрлекләрендә киптергечләр, гөмбә кайнаткычлар, саклыкханәләр һәм башка вакытлы төзелмәләр урнаштырырга;

– аларны гамәлгә ашыру Россия Федерациясенең урман законнары таләпләренә каршы килмәгән башка хокукларга ия булырга.

Урман кишәрлекләрен азык-төлек урман ресурсларын һәм дару үләннәрен әзерләү һәм җыеп алу буенча арендалаучы гражданнар һәм юридик затлар түбәндәгеләргә хокуклы:

– урманнарны үзләштерү проектын төзергә;

– урманнардан урманнарны үзләштерү проекты һәм әлеге урман хуҗалыгы регламенты нигезендә файдаланырга;

– урман кишәрлеге арендасы килешүе шартларын үтәргә;

– гражданнарның сәламәтлегенә, әйләнә-тирә мохиткә зарар китерүгә юл куймаска;

– урманнардан туфрак эрозиясен булдырмый торган, урманнарның торышына һәм аларны торгызуга, һәм шулай ук су объектларына һәм башка табигый объектларга тискәре йогынтыны булдырмый торган яисә чикли торган ысуллар ярдәмендә файдаланырга;

– урманнарда янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен, урманнарда санитар иминлек кагыйдәләрен, һәм шулай ук урманнарны карап тоту кагыйдәләрен үтәргә;

– урманнарда санитар иминлек булдыру максатларында санитар-савыктыру чараларын башкарырга (һәлак булган һәм зарарланган урман утыртмаларын кисәргә, урманнарны чүп-чардан, пычраклардан һәм башка тискәре йогынтылардан чистартырга);

– ел саен тапшырыла торган урман декларациясен, һәм шулай ук урманнардан файдалану буенча хисап, урманнарны билгеләнгән тәртиптә саклау һәм яклау буенча хисап тапшырырга;

– Россия Федерациясе законнары белән каралган башка йөкләмәләрне үтәргә.

### 2.4.1. Урманнардан азык-төлек урман ресурсларын һәм дару үләннәрен аларның төрләре буенча әзерләү һәм җыеп алу өчен файдалануның нормативлары (ел саен мөмкин булган күләмнәре) һәм параметрлары

Азык-төлек урман ресурсларын әзерләү һәм дару үләннәрен җыю буенча урманнардан рөхсәтле файдалану буенча ел саен мөмкин булган күләмнәр 2.4.1 таблицада китерелгән.

2.4.1 таблица

**Азык-төлек урман ресурсларын әзерләгәндә һәм дару үләннәрен җыеп алганда урманнардан файдалану параметрлары**

| № п/п | Азык-төлек урман ресурслары, дару үләннәре төре | Үлчәү берәмлеге | Ел саен мөмкин булган әзерлек күләме |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| Азык-төлек ресурслары | | | |
| 1. | Җиләкләр: нарат җиләге | т | - |
| | мүк җиләге | т | - |

| № п/п | Азык-төлек урман ресурслары, дару үләннәре төре | Үлчәү берәмлеге | Ел саен мөмкин булган әзерлек күләме |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| | күк җиләк | т | - |
| | кура җиләге | т | 1,5 |
| | җир җиләге | т | 0,5 |
| | кара җиләк | т | - |
| | кызыл бөрлегән | т | - |
| | миләш, шомырт | т | 3 |
| | Җәмгысе | т | 5 |
| 2. | Гөмбәләр: ак | т | 1 |
| | майлы | т | 10 |
| | ал гөмбә | т | 10 |
| | кызыл гөмбә | т | 5 |
| | каен гөмбәсе | т | 5 |
| | гөреждә | т | 2 |
| | этәч гөмбәсе | т | - |
| | баллы гөмбә | т | 10 |
| | Җәмгысе | т | 42 |
| 3. | Агач сутлары: каен | т | 250 |
| Дару чималы | | | |
| 4. | Сары мәтрүшкә, ике өйле кычыткан, ландыш, аю табаны, дару ромашкасы, акбаш, эт тигәнәге, канлы үлән, песи үләне, сәдәп гөле, лапчатка, үги ана яфрагы, кыр наратбашы һ.б. | т | 1,0 (коры килеш) |
| 5. | Ку гөмбәсе | т | 0,5 |

Җиләкләрнең, гөмбәләрнең һәм дару чималларының 60% уңышы җирле халык тарафыннан үзләштерелә.

## 2.4.2. Әзерләү һәм җыеп алу вакытлары

Кыргый җимешләрне һәм җиләкләрне әзерләү катгый рәвештә билгеләнгән вакытларда башкарыла. Кыргый үсүче җимешләрне һәм җиләкләрне әзерләү вакытлары уңышның массакүләм өлгерү вакыты җитүгә бәйле.

Җимеш бирүче ботакларны һәм агачларны җимеш әзерләү өчен кисү тыела.

Чикләвекләр әзерләү. Чикләвекләрне әзерләү вакытлары аренда килешүендә күрсәтелә. Урман кишәрлекләре чикләвек әзерләү өчен арендага бирелгән затлар чикләвек бирүче утыртмаларның саклыгын тәэмин итә.

Чикләвекләрне әзерләгәндә агачларны һәм куакларны кисү, һәм шулай ук агачларны һәм куакларны зарарлый торган ысулларны куллану тыела.

Гөмбәләрне әзерләү аларның ресурсларын саклауны тәэмин итүче ысуллар белән башкарылырга тиеш.

Гөмбәләрне гөмбәлеге белән өзеп алу, гөмбәләрне җыеп алганда мүкне һәм урман түшәмәсен әйләндерү, һәм шулай ук картайган гөмбәләрне юк итү тыела.

Гөмбәләрнең иң киң таралган төрләре, җыеп алу вакыты һәм урыннары 2.4.2.1 таблицада күрсәтелгән.

2.4.2.1 таблица

**Гөмбәләрнең иң киң таралган төрләре, җыеп алу вакыты һәм урыннары**

| Гөмбәләрнең атамалары | Җыеп алу вакыты | Җыеп алу урыны |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| Кәҗә гөмбәләре | Апрель–май | Нарат урманнарында урман киселгән, янгын булган, комлы туфраклы урыннарда |
| Кәҗә гөмбәләре | Апрель–май | Нарат һәм карагай урманнарында, куаклыкларда |
| Ак гөмбә | Июнь–сентябрь | Нарат, чыршы, каен һәм имән урманнарында |
| Сары гөмбә | Август–сентябрь | Сирәк шытып чыккан нарат һәм чыршы урманнарында |
| Ал гөмбә | Июнь–октябрь | Барлык урманнарда да, әмма иң күп очракта карагай урманнарында |
| Каен гөмбәсе | Июнь–октябрь | Каен булган бөтен җирдә үсә |
| Кызыл гөмбә | Июль–сентябрь | Яшь усаклыкларда һәм усак катнашмалы катнаш урманнарда |
| Майлы гөмбә | Июнь–октябрь | Наратлыкларда һәм вак яшь наратлыкларда (культураларда) |
| Моховик | Июнь–сентябрь | Нарат урманнарында нечкә торфлы-комлы туфракларда |
| Баллы гөмбә | Август–октябрь | Нарат һәм карагай токымлы, бигрәк тә зирек агачлары төпләрендә |
| Әтәч гөмбәсе | Июнь–сентябрь | Каен, ылыслы һәм катнаш урманнардагы дымлы урыннар |
| Валуй | Июль–октябрь | Барлык урманнарда да |
| Гөреждә | Июль–октябрь | Яфраклы һәм юкә һәм чикләвек куаклары булган катнаш урманнарда |
| Дуңгыз гөмбә | Июнь-октябрь | Ылыслы һәм яфраклы урманнарда кырпуларда, юл буйларында, паркларда |
| Йөнтәс гөмбә | Июль–октябрь | Катнаш һәм каен урманнарында |
| Ачы гөмбә | Май–октябрь | Нарат урманнарында дымлы урыннарда |
| Шампиньон | Июль–сентябрь | Яшелчә, җиләк-җимеш бакчаларында, паркларда, болыннарда, көтүлекләрдә, чүплекләрдә |

Дару үләннәрен әзерләү үсемлекләрнең һәм чимал запасының үз вакытында торгызылуын тәэмин итәрлек күләмнәрдә рөхсәт ителә.

Бер үк аланда (урман җирендә) дару үләннәре чималын кабат җыю бары тик конкрет үсемлек төренең чимал запасы тулысынча торгызылганнан соң гына рөхсәт ителә.

Дару үләннәренең кайсы да булса төре өчен кабат әзерләү вакытлары турында белешмә булмаганда түбәндәгеләргә таянып эш итәргә мөмкин:

– берьеллык үләннәрнең чәчәк өлешен, җир өстендәге органнарын ("үләнен") бер үк аланда әзерләү 2 елга бер башкарыла;

– күпьеллык үләннәрнең җир өсте органнарын ("үләнен") – 4-6 елга бер тапкыр;

– дару үләннәренең күпчелек төрләренең җир өсте органнарын – 15-20 елга бер тапкырдан да ешрак түгел.

Төп дару үләннәре, аларны әзерләү урыннары һәм вакытлары 2.4.2.2 таблицада күрсәтелгән.

2.4.2.2 таблица

**Төп дару үләннәре**

| Үләннәрнең исеме | Әзерләнә торган өлешләре | Әзерләү вакыты, ай | Әзерләү урыны |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| Сазанак | Өске яшь ботаклары яфраклары һәм җимешләре белән бергә | Август-сентябрь | Нарат утыртмалары каплаган дымлы һәм юеш урыннарда |
| Еламсар каен | Бөреләре | Март-апрель | утыртма буенча |
| Ком меңьяфрагы | Чәчәкләре | Июль-август | Болын кырыйлары, калку урыннар, ярлар, коры мүклекләр һәм ак мүклекләр һәм коры наратлыклар |
| Җете кызыл дүләнә | Чәчәкләре һәм җимешләре | Май, август-сентябрь | утыртма буенча |
| Гади нарат җиләге | Яфраклары | Апрель–май | Нарат җиләге наратлыклары |
| Дару үләне булган песи үләне | Тамырлары | Апрель, сентябрь-октябрь | Нарат җиләге аланнары |
| Өчьяфрак | Яфраклары | Май-август | Урман авызлары, болыннар, печәнлекләр, түбән урыннар, дымлы урыннар |
| Елан үләне | Тамыры | Май-сентябрь | Урман авызлары, болыннар, печәнлекләр, түбән урыннар, дымлы урыннар |
| Борычлы тау үләне | Җир өстендәге өлеше | Июль-сентябрь | Юеш һәм дымлы каен утыртмалары, түбәнлектәге сазлык, сазланган печәнлекләре |

| Үләннәрнең исеме | Әзерләнә торган өлешләре | Әзерләү вакыты, ай | Әзерләү урыны |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| Язгы утчәчәк | Җир өстендәге өлеше | Май-сентябрь | Дымлы сирәкләнгән утыртмалар, үзәннәрдәге болыннар |
| Биек сары чәчәк | Тамырлары | Май, сентябрь | Дымлы урман авызлары, үзәннәр, аланнар |
| Дарулык кандала | Чәчәк ату чорында өске өлеше | Июнь-июль | Коры болыннар, көтүлекләр, ярлар |
| Гади имән | Кайры | Апрель-июль | утыртма буенча |
| Дарулык сыбызгы үлән | Чәчәк атмаучы нөсхәләренең тамырлары | Апрель, сентябрь-октябрь | Үзәннәр, елга буйларындагы утыртмалар |
| Гади мәтрүшкә | Үләне | Июль-август | Ачыклыклар, печәнлекләр, яфраклы урманнар |
| Эт шомырты | Җимешләре | Август-сентябрь | Ачыклыклар, печәнлекләр, яфраклы урманнар |
| Тишек яфраклы сары мәтрүшкә | Үләне | Июль-август | Ачыклыклар, печәнлекләр Урман ачыклыклары һәм болыннар |
| Ак алтынбаш | Үләне | Июль-август | Ачыклыклар, печәнлекләр Урман ачыклыклары һәм болыннар |
| Гади балан | Кайрысы, җимешләре | Август-сентябрь | Үзәнлекләр, урман авызлары |
| Икеөйле кычыткан | Яфраклары | Май-сентябрь | Үзәнлекләр, бушлыклар, дымлы һәм юеш урыннарда сирәкләнгән урманнар |
| Дарулык кан үләне | Тамырлары | Август-сентябрь | Үзәннәрдәге сирәкләнгән урыннар, болыннар |
| Зирексыман эт шомырты | Кайры | Март-май | Елга буйларындагы һәм ярлардагы яфраклы урманнар |
| Сары эт шомырты | Тамыры | Май-октябрь | Сулыклар |
| Май ландышы | Чәчәк ату чорында үләне | Май-июнь | Яфраклы һәм катнаш урманнар |
| Калган | Тамыры | Апрель, сентябрь-октябрь | Яфраклы урманнар, ачыклыклар |
| Вак яфраклы юкә | Чәчәкләре | Июнь-июль | утыртма буенча |
| Үги ана яфрагы | Яфраклары | Май-июль | Сазланган печәнлекләр |
| Гади кура | Җимешләре | Июль-август | Киселгән урыннар, сирәкләнгән утыртмалар |
| Гади артыш | Күркә-җиләкләре | Сентябрь-октябрь | Ылыслы утыртмалары куаклыкларында |
| Дару тузганагы | Тамырлары | Май-октябрь | Печәнлекләр, көтүлекләр, ташландык урыннар, ачыклыклар |
| Соры зирек | Җимешләре | Август-октябрь | Елга буйларындагы утыртмалар |
| Гади гөлбадран | Чәчәкләре | Июль-сентябрь | Сирәкләнгән үләнсыман наратлыклар, ачыклыклар, болыннар |
| Зур көтүче яфрагы | Яфраклары | Июль-сентябрь | Юл буйлары, аланнар, болыннар |

| Үләннәрнең исеме | Әзерләнә торган өлешләре | Әзерләү вакыты, ай | Әзерләү урыны |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| Ачы әрем | Чәчк атучы өске өлешләре, яфраклары | Июнь-август | Тик яткан урыннар, юллар, ташландык урыннар |
| Сукыр кычыткан | Үләне | Июнь-август | Юл, яр буйларында, ташландык урыннарда |
| Гади миләш | Җимешләре | Сентябрь-октябрь | Яфраклы һәм катнаш урманнар |
| Кара карлыган | Җимешләре, яфраклары | Май-август | Елга үзәннәре |
| Гади нарат | Бөреләре, ылыслары | Май-октябрь | Ылыслы диләнкеләр |
| Коры үлән | Үләне | Июнь-август | Аланнар, ачыклыклар, сазлы болыннар |
| Гади әнис | Җимешләре | Июль-август | Болыннар, елга буйлары |
| Гади турак уты | Яфраклары | Май-сентябрь | Коры наратлыклар |
| Гади меңьяфрак | Җир өстендәге өлеше (үләне) | Май-август | Киселгән урыннар, аланнар, ачыклыклар, печәнлекләр |
| Өч чәчәкле миләүшә | Җир өстендәге өлеше (үләне) | Май-август | Урман авызлары, аланнар, урман юллары |
| Кыр наратбашы | Үләне | Май-сентябрь | Үзәнлекләр, урман авызлары |
| Чага (каен гөмбәсе) | Өстенә үскән өлешләре | Гыйнвар-декабрь | Каен утыртмалары |
| Лобель аксыргагы | Тамырлары | Май-сентябрь | Үзәнлекләр, түбәнлектәге көтүлекләр һәм печәнлекләр |
| Өч өлешле эт тигәнәге | Үләне | Май-сентябрь | Елгаларның дымлы ярлары, печәнлекләр |
| Гади шомырт | Җимешләре | Июль-сентябрь | Елга үзәннәре |
| Зур канлы үлән | Үләне | Май-август | Диләнкеләр, чүп үләне үскән урыннар |
| Коңгырт гөлҗимеш | Җимешләре | Август-сентябрь | Сирәкләнгән урманнар, киселгән урыннар |

### 2.4.3. Агач сутлары әзерләү

Каен суты әзерләү өлгергән урман кишәрлекләрендә кисәренә 5 елдан да ким булмаган вакыт кала рөхсәт ителә.

Каен сутын әзерләү кисү өчен әзерләнгән агач үсентеләренә кисеп җибәрү юлы белән гамәлгә ашырыла.

Кисеп җибәрү өчен тулылыгы 0,4 һәм бер гектарга кимендә 200 данә агачы булган, I-III бонитет класслы урманның сәламәт өлеше сайлап алына. Кисеп җибәргәндә күкрәк биеклегендә килеш агачның диаметры 20 см һәм аннан да күбрәк булырга тиеш.

Каналлар бораулауны агач тамыры башланган җиреннән 20-35 см биеклектә башкаралар. Агачта бер һәм аннан да күбрәк кисеп җибәрү ясалганда, сут бер

кабул итү савытына агып төшәрлек итеп, алар кәүсәнең бер ягында 8-15 см аралыкта булырга тиеш.

Агач диаметрына карап, бораулана торган каналлар саны нормативлары 2.4.3 таблицада китерелә.

2.4.3 таблица

**Агачларның кәүсә диаметрына карап бораулана торган каналлар саны нормативлары**

| Күкрәк биеклегендә агачның диаметры, см | Кирт салгандагы каналлар саны | Искәрмә |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 20-22 | 1 | Түбәндәге йөкләнеш нормасы булганда 16 см диаметрлы агачларны кисеп җибәрү кисәргә бер ел кала рөхсәт ителә:<br>16-20 см – 1 канал<br>21-24 см – 2 канал<br>25 см һәм аннан артык – 3 канал |
| 23-27 | 2 | |
| 28-32 | 3 | |
| 33 һәм аннан артык | 3 | |

Кисеп җибәрү сезоны тәмамланганнан соң авыруларны булдырмый калу максатларында, тишекләр сагыз пастасы белән сылап куелырга яисә агач бөке белән ябылырга һәм вар, бакча замазкасы яисә известьлы балчык белән сылап куелырга тиеш.

Калган елларда каналлар беренче елгы кисеп җибәрү каналлары дәрәҗәсендә 10 см интервал белән агач кәүсәсе әйләнәсенең теге яисә бу ягына таба бораулана.

Әзерләү үзагачның техник сыйфатларын саклап калырлык итеп гамәлгә ашырылырга тиеш.

## 2.4.4. Абага-кара абага әзерләү

Абаганың яшь ботакларын әзерләү аларның үсентеләренә зыян китермәслек алымнар белән гамәлгә ашырылырга тиеш. Абаганы тамыры белән йолкып алу, яфракларына һәм тамыр үзәгенә зыян китерү тыела.

Кара абага абагасының очында өчтән артмаган, "өчәрләнгән" ачылмаган яфрагы булган китерелмәгән яшь ботагы ашарга яраклы дип санала.

Җыярга яраклы яшь ботакларының оптималь биеклеге – әзерләү районына һәм үсү шартларына карап, 20-25 см алып 30-40 см кадәр. Үрентеләрне нигез төбендә ваклыйлар.

Урман абагасы чималын әзерләү бер үк кишәрлектә 3-4 ел буена алып барыла. Аннары үсентеләр торгызылсын өчен тәнәфес ясарга кирәк: чималны бер мәртәбә җыйганда (сезонга) – 2-3 ел, ике мәртәбә – 3-4 ел.

### 2.4.5. Азык-төлек урман ресурсларын әзерләгәндә һәм дару үләннәрен җыеп алганда урманнардан файдалану вакытлары

Дәүләт яисә муниципаль милектәге урман кишәрлеген арендалау шартнамәсе урманнардан азык-төлек урман ресурсларын әзерләү һәм дару үләннәре җыю өчен файдалану максатларында Россия Федерациясе Урман кодексының 72 статьясындагы 3 өлеше нигезендә ун елдан алып кырык тугыз елга кадәр төзелә.

## 2.5. Урманнардан аучылык хуҗалыгы өлкәсендә эшчәнлек төрләрен башкару өчен файдалану нормативлары, параметрлары һәм вакытлары

### 2.5.1. Биотехник чаралар үткәрүнең исемлеге һәм нормалары

Биотехник чараларның еллык күләмнәре 2.5.1.1 нче таблицада китерелә.

2.5.1.1 таблица

Аучылык хуҗалыгын алып барганда урманнардан файдалану параметрлары

| № п/п | Чараларның төрләре | Үлчәү берәмлеге | Ел саен мөмкин булган күләм |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Ашату мәйданнарын кору | данә | 10,0 |
| 2. | Пошилар өчен катырлар кору | данә | 4,0 |
| 3. | Куяннар өчен катырлар кору | данә | 35,0 |
| 4. | Усакны, талны каеп чыгу | кбм | 15,0 |
| 5. | Кабаннар өчен ашату урыннары эшләү | данә | 15,0 |
| 6. | Тоз ялау савытын урнаштыру | т | 0,2 |
| 7. | Бөртек калдыкларын салу | т | 4,7 |
| 8. | Бәрәңге салу | т | 1,4 |
| 9. | Кабан дуңгызы өчен ашату кырлары булдыру | га | 0,4 |
| 10. | Ясалма оялыклар булдыру | данә | 80,0 |

Урманчы 2.5.1.1 таблицада күрсәтелгән чараларны үтәү өчен башкаручылар билгели.

Урман хуҗалыгы һәм урманнардан файдалану чараларын проектлаганда саклау максатлары өчен өстәмә рәвештә түбәндәгеләр карала:

– махсус яклана торган кишәрлекләрне аеру өчен урман тавыгы гөлдерәү урыннарын, сулыкларны, кондызлар күп яши торган урыннарны карталаштыру;

– көртлек һәм урман тавыгы гөлдерәү урыннарында урман культуралары җитештерүдән баш тарту;

– җәнлекләр оя кора торган урыннарда һәм җәйге чорда яшь кыргый хайваннар туплану урыннарында эшләрне чикләү;

– агулы химикатлар һәм минераль ашламалар куллануны чикләү;

– кисүләрдән соң усак һәм башка токымнар шытып чыккан урыннарда 5-10 ел урман культуралары җитештерүдән баш тарту.

### 2.5.2. Аучылык инфраструктурасын урнаштыру буенча рөхсәт ителгән объектлар исемлеге

Аучылык хуҗалыгы өлкәсендә эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыру өчен урманнардан файдаланучы затлар түбәндәгеләргә хокуклы:

1) аучылык хуҗалыгы өлкәсендә эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыру өчен бирелгән урман кишәрлегендә (алга таба – урман кишәрлеге) аучылык инфраструктурасы объектлары булдыру чараларын күрергә, шул исәптән:

а) законнардагы таләпләр нигезендә аучылык базасы, аучы йорты, егерьлар кордоннары һәм башка туктап тору пунктлары булдырырга;

б) көймәләр пристаньнары корырга;

в) кыргый хайваннар өчен питомниклар, кинологик корылмалар һәм аучы токымнары этләре өчен питомниклар, ату вышкалары, тирлар, терлек азыгы саклау урыннары, өстәмә ашату корылмалары, печән чапкан урыннар, урман юллары, башка вакытлы корылмалар, төзелмәләр һәм аучылык хуҗалыгы өлкәсендә эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыру өчен төзекләндерү объектлары булдырырга;

г) законнардагы таләпләр нигезендә урман юллары һәм аучылык хуҗалыгы өлкәсендә эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыру өчен кирәкле башка линияле объектлар булдырырга, аларны ремонтларга һәм реконструкцияләргә, транспорт чаралары туктап тору урыннарын билгеләргә һәм корырга;

2) агач-ботаклардан терлек азыгы (кайры, нәзек ботаклар, яшь ботаклар, кыйммәте аз булган агач һәм куак токымнары яфраклары) һәм аучылык ресурсларына кертелгән җәнлекләргә һәм кошларга ашату өчен печән әзерләргә;

3) гамәлгә ашыруы урман законнарына, аучылык һәм аучылык ресурсларын саклау өлкәсендәге законнарга һәм (яисә) урман кишәрлеген арендалау шартнамәсе шартларына һәм аучылык хуҗалыгы килешүләренә каршы килмәсә, бүтән хокуклардан файдаланырга.

Кыргый хайваннар өчен питомниклар, кинологик корылмалар һәм аучы токым этләре өчен питомниклар, ату вышкалары, тирлар, терлек азыгы саклау урыннары кору – урман аланнарында, урман авызларында, янгыннан соң калган урман утыртылмаган урыннарда, буш урыннарда һәм агачлар һәм куаклар үсми торган урыннарда, ә өстәмә ашату урыннары асылда, түмәрләрне, җил аударган агачларны һәм урман туфрагын кулланып, гамәлгә ашырылырга мөмкин.

Вакытлы корылмалар урман кишәрлеген файдалану вакытыннан артмаган срокка урман үсентеләре булмаган яисә агачларның һәм куакларның кыйммәте аз булган токымнары үсә торган урыннарда корылырга мөмкин һәм, объектның төрен һәм аның хуҗасының атамасын күрсәтеп, аншлаглар белән билгеләнергә тиеш.

## 2.6. Урманнардан авыл хуҗалыгы алып бару өчен рөхсәтле файдалану нормативлары, параметрлары һәм вакытлары

Авыл хуҗалыгы алып бару өчен урманнардан файдалану алар урнашкан җирләрнең билгеләнешенә бәйле рәвештә, урман фонды җирләрендә ул урман хуҗалыгы мәнфәгатьләре туры килгәндә генә рөхсәт ителә һәм РФ УК 38 статьясы белән регламентлана, шул ук вакытта, авыл хуҗалыгы җитештерүе дип авыл хуҗалыгы продукциясен, чималын һәм азык-төлек үстерү генә түгел, аны җитештерү, эшкәртү буенча икътисади эшчәнлек төрләре җыелмасы да санала. (“Авыл хуҗалыгын үстерү турында” 29.12.2006 ел, № 264-ФЗ ФЗ, 4 ст.).

Авыл хуҗалыгы җитештерүенә гадәттә авыл хуҗалыгы чималын беренчел эшкәртү генә кертелә. Сәнәгать эшкәртүе авыл хуҗалыгы җитештерүе дип саналмый.

Шул максатта РФ УК 38 статьясындагы 2 өлеше белән авыл хуҗалыгы алып бару өчен билгеләнгән урман кишәрлекләрендә бары тик вакытлы корылмалар (умарталыклар, киртәләр, эвеслекләр һ.б.ш.) төзү генә рөхсәт ителә.

Әлеге норма авыл хуҗалыгын алып бару өчен урманнардан файдалану кысаларында авыл хуҗалыгы продукциясен сәнәгать эшкәртүен гамәлгә ашырырга мөмкинлек бирми, еш кына хәтта беренчел эшкәртергә дә.

Капиталь төзелеш объектларын төзергә кирәк булганда авыл хуҗалыгы товар җитештерүчесенә урманнардан авыл хуҗалыгы максатлары өчен файдалану гына түгел, урман ресурсларын эшкәртү өчен файдалану да таләп ителә (РФ УК 46 ст.).

Авыл хуҗалыгын алып бару өчен урманнардан файдаланганда алынган продукция бер үк вакытта урман ресурсы булып та саналырга мөмкин.

Авыл хуҗалыгы алып бару өчен урманнардан файдалану урманчылык территориясендә түбәндәгеләр тарафыннан гамәлгә ашырыла:

– гражданнар, шул исәптән әйдәүче крестьян (фермер) хуҗалыклары, бакчачылык, яшелчәчелек, терлекчелек белән шөгыльләнүче шәхси ярдәмче хуҗалыклар;

– хуҗалык итүче ширкәтләр һәм җәмгыятьләр, җитештерү кооперативлары, дәүләт һәм муниципаль унитар предприятиеләр, бүтән коммерция оешмалары;

– коммерцияле булмаган оешмалар, шул исәптән кулланучылар кооперативлары, дини оешмалар.

Гражданнар, юридик затлар авыл хуҗалыгын алып бару өчен урманнардан файдалануны урман кишәрлекләрен арендалау шартнамәләре нигезендә гамәлгә ашыра. Авыл хуҗалыгын алып бару өчен урманнардан файдалану кагыйдәләре “Авыл хуҗалыгын алып бару өчен урманнардан файдалану кагыйдәләрен раслау турында” 05.12.2011 ел, № 509 Рослесхоз боерыгы белән билгеләнә.

Әлеге Кагыйдәләрдә авыл хуҗалыгын алып бару өчен урманнардан файдалануның теләсә кайсы төренә кагыла торган гомуми нигезләмәләр һәм урманнарда алып барыла торган авыл хуҗалыгы эшчәнлегенең аерым төрләрен билгеләүче махсус таләпләр бар.

Авыл хуҗалыгын алып бару урман парклары зоналарында, тыюлык урман кишәрлекләрендә тыела.

Печән чабу һәм умартачылык белән шөгыльләнүдән гайре, су саклау зоналарында, яшел зоналарда, махсус саклanучы урман кишәрлекләрендә авыл хуҗалыгын алып бару тыела.

### 2.6.1. Авыл хуҗалыгын алып бару өчен урманнардан файдалану параметрлары

2.6.1 таблица

**Авыл хуҗалыгын алып бару өчен урманнардан рөхсәтле файдалану параметрлары**

| № п/п | Файдалану төрләре | Үлчәү берәмлеге | Ел саен мөмкин булган күләм |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Сөрүлекләр | га | 10 |
| 2. | Печән чабу | га | 45 |
| 3. | Көтү көтү | | |
| | а) урманда | мең га/баш | - |
| | б) утлавыкларда | га/ баш | 44 / 180 |
| 4. | Умартачылык | | |
| | а) бал бирүчеләр: | | |
| | - юкә | га | 13000 |
| | - үләннәр | га | 631 |
| | б) бал продуктлылыгы, шул исәптән: | | |
| | - юкә | кг/га | 500 |
| | - үләннәр | кг/га | 100 |
| | в) умарта оялары күләмен тәэмин итү мөмкинлеге | күләме | 908 |

### 2.6.2. Авыл хуҗалыгы, печән чабу, авыл хуҗалыгы терлеген көтү, умартачылык мөмкин булган авыл хуҗалыгы җирләренең мәйданнары турында белешмәләр

Печән чабу

Печәнлекләрне классификацияләгәндә түбәндәгеләр билгеләнә: печәнлекләрнең тибы (су баса торган, коры җирдәге, сазланган), табигыймы ул яисә яхшыртылганмы, агач-куаклар басып китү дәрәҗәсе, печән әзерләүне кыенлаштыра торган факторлар, үләннең төп төрләре, аның каплап кителеш дәрәҗәсе, куелыгы, уңышы, сыйфаты. Печәнлекләр мәйданының 20% агач-куаклар басып алган булса, ул агач-куак басып киткән дип санала, 20% артыгын түмгәкләр каплаган булса – түмгәкле дип, яхшыртылган печәнлекләр дип – табигый һәм чәчелгән үләннәр каплап алган булса, анда механика кертеп була.

Печән уңышын бәяләү: 10 ц/га һәм аннан да күбрәк – яхшы, 6-9 ц/га – уртача, 1-5 ц/га – начар.

Печән чабу җирләрен бәяләү

Печәнлекләр өчен түбәндәгеләр кулланыла:

– урман утыртылмаган диләнкеләр, ачыклыклар һәм урман җире капламаган һәм урман культуралары утыртып, урманнарны торгызу мөмкин булмаган җирләр;

– яхшыртуга мохтаҗ, печән чабу өчен яраклы җирләр;

– реконструкция өчен билгеләнмәгән кыйммәте аз булган урман утыртмалары кишәрлекләре.

2.6.2.1 таблица

**Печән чабу җирләренә сыйфатлама**

| Печән чабу тибы | Урнашкан урыны | Үлән капламы | Печән чабу тибының сыйфаты |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| Вакытлыча дымы артып киткән коры җирләр | Сизелер-сизелмәс субүлү урыннары | Карчыга үләне, тубылгы, гравилат, тузгак кылган, башаклы үлән, түмәрлек, эт үләне, бөтнек | Уртача |
| Коры үзәнлекле, үзәнле - ерганаклы | Кече елга үзәннәре, үлән баскан тар яр сөзәкләре һәм төбе тигез булмаган уйсулыклар | Тимофеевка, солыча, кылчыклы үлән, төлке койрыгы, бөтнек | Яхшы |
| Түбән уртача-артык дымланган | Киң үзән булдыручы түбәнлекләр | Бөртеклеләр, башаклы үлән, кузаклылар | Уртача |
| Сазланган иңкүлекләр | Грунт сулары якын булган сазланган түбәнлекләр | Дым яратучы бөртеклеләр, эре башаклы үлән | Начар |

Урманнарны авыл хуҗалыгы терлекләрен көтү өчен файдалану

Терлек көтү җирләрен исәпкә алу

Терлекләрне көтү, махсус сакланылучы табигать территорияләрендә, су саклау зоналарында, яшел зоналарда урнашкан урманнарда, эрозиягә каршы урманнарда һәм МСК тыш, барлык урманнарда да рөхсәт ителә.

Терлек көтү түбәндәге урыннарда рөхсәт ителми:

– очларына терлек буе җитмәслек булганчы (1.5-2.0 м) урман культуралары кишәрлекләрендә;

– урман орлыкларын үстерү, чыршы, тал, тирәк һәм чикләвек плантацияләрендә;

– табигый торгызуга ярдәм итү чаралары уздырыла торган кишәрлекләрдә;

– очларына терлек җитмәслек булганчы (1.5-2.0м.). Яшь урман утыртмаларында;

– ылыслы һәм каты яфраклы токымнарны табигый торгызу өчен билгеләнгән, урман утыртмалары белән капланмаган җирләрдә;

– су һәм җир эрозиясе белән зарарлаган җирләрдә.

Авыл хуҗалыгы терлекләренең хуҗалары түбәндәгеләрне тиешле:

– урман культураларын, питомникларны, үзе шытып чыккан яшь урман үсентеләрен һәм башка кыйммәтле урман кишәрлекләрен зарарламас өчен киртәләп алырга;

– авыл хуҗалыгы терлекләрен көтүче тарафыннан көттерергә (коймалы көтүлекләрдән һәм бәйләп куюдан гайре).

Кәҗә көтү авыл хуҗалыгы терлекләре хуҗалары киртәләгән урман кишәрлекләрендә һәм бәйләгән килеш кенә рөхсәт ителә.

Көтүлекләрнең категорияләре һәм аларның азык продуктлылыгы

Көтүлекләрне төрләргә бүлгәндә проект капланышын, үләннең төп төрләрен, аның куелыгын, асылда нинди үләннәрдән торуын, аларның сыйфатын региональ шкалалар кулланып күрсәтәләр. Алар булмаганда түбәндәгеләрне кулланырга мөмкин:

– яхшы җирләр – яхшыртылган һәм су баса торган, кузаклы-бөртеклеләр өстенлек итә торган (60% һәм аннан да күбрәк) кишәрлекләр; үләннең проект капламы – 60% һәм аннан да күбрәк);

– начар җирләр – табигый һәм каты үләннәр басып алган (60% аннан да күбрәк) (эре башаклы үлән, камышлык, ситник); башка үләннәрнең проект капламы 50% кадәр.

2.6.2.2 таблица

**1 баш терлеккә якынча сезонлы көтү нормалары, га**

| | |
|---|---|
| 0.0,5 – 0,6.6 тулылыктагы каен өстенлек итә торган яфраклы урманнар | 2 |
| 0.0,5 тулылыктагы саф каенлыклар | 1,5 |
| Көтүлек өчен яраклы башка урман үсентеләре (1 башмөгезле эре терлеккә яисә 7 сарыкка) | 4 – 5 |
| Куаклардан һәм шытып чыккан урман үсентеләре булмаган киселгән урыннарда | 0,75 |

Умартачылык

Бал бирүче бал кортлары өчен азык сыйфатында агачлары, куаклары яисә үләнле-куаклы ярусы составында бал бирә торган үләннәре булган урман кишәрлекләре кулланыла.

Умарта оялары һәм умарталыклар урнаштыру өчен беренче чиратта урман авызлары, ачыклыклар һәм урман үсентеләре капламаган башка җирләр бирелә.

1000 артык төре булган күпсанлы чәчәк үсемлекләреннән бал кортлары чәчәк нектары һәм серкәсе җыя. Шуларның берсе – беренче дәрәҗәдә бал бирүчеләр, башкалары – икенче дәрәҗәдә бал бирүчеләр. Алга таба аеруча киң таралган бал бирүче үсемлекләр тасвирламасы китерелә (2.6.2.3 таблица).

2.6.2.3 таблица

**Бал бирүче үсемлекләрнең бал продуктлылыгы**

| Бал бирүчеләр | Чәчәк атуның уртача вакытлары | | Бал продуктлылыгы, кг/га |
|---|---|---|---|
| | башы (дата) | продуктлылыгы (көн) | |
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| Үги ана яфрагы | 12.04 | 30-60 | П* |
| Чикләвек куагы | 20.04 | 6-9 | П* |
| Йолдыз чәчәк | 20.04 | 30 | П* |
| Кызыл тал | 22,04 | 5-30 | 150 |
| Баллыкый (даруханә) | 23.04 | 30 | П* |
| Кәҗә талы | 28.04 | 10 | 150 |
| Бүре җиләге | 30.04 | 15 | П* |
| Үрмәләк үлән | апрель | 90 | П* |
| Үткен яфраклы чаган | 08,05 | 7-10 | 200 |
| Мурт тал | 10.05 | 5-10 | 150 |
| Ак тал | 11.05 | 15-20 | 150 |
| Карлыган | 20.05 | 10-20 | 50-140 |
| Шомырт | 21.05 | 12 | П* |
| Сукыр кычыткан | 24,05 | 45 | 100 |
| Чия | 23.05 | 10-12 | 30-40 |
| Сары акация | 25.05 | 10-14 | 350 |
| Алмагач | 26,05 | 10-12 | 20-30 |
| Дүләнә | май | 15 | П* |
| Нарат җиләге | май | 30 | П* |

| Бал бирүчеләр | Чәчәк атуның уртача вакытлары | | Бал продуктлылыгы, кг/га |
|---|---|---|---|
| | башы (дата) | продуктлылыгы (көн) | |
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| Татар өрәңгесе | май | 7-10 | 100 |
| Миләш | май | 10 | 30-40 |
| Күгән | май | 15 | 25 |
| Зелпе | май | 20 | П* |
| Гади чамбыр | май-июнь | 34 | 140 |
| Кара җиләк | май-июнь | 30 | 30 |
| Кыр шалфейе | май-июнь | 30-60 | 110 |
| Мурт эт шомырты | 06,06 | 14 | 35 |
| Балан | 11.06 | 30-45 | П* |
| Урман курасы | 15.06 | 25-40 | 60-100 |
| Кырлыган | 22,06 | 45-60 | 350-400 |
| Киңяфраклы юкә | 23.07 | 14 | 500-600 |
| Ак ике еллык кандала үләне | 25.06 | 30 | 200-300 |
| Җир җиләге | июнь | 20 | 10 |
| Тычкан борчагы | июнь-июль | 30-40 | 180-370 |
| Дару шалфейе | июнь-июль | 47 | 117-133 |
| Сары кандала үләне | июнь-июль | 30-40 | 150-200 |

Искәрмә. П* - табышны тотып торучы тип билгеләнгән.

2.6.2.4 таблица

**Юкә чәчәк атканда җыеп алырга мөмкин булган бал, кг/га**
**( гомуми бал продуктлылыгыннан 30%)**

| Яше, ел | I – II бонитет | | III бонитет | | IV – V бонитет | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | тулылыгы | | | | | |
| | 0,3 – 0,5 | 0,6 – 1,0 | 0,3 – 0,5 | 0,6 – 1,0 | 0,3 – 0,5 | 0,6 – 1,0 |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| 20 | 29 | 32 | 22 | 25 | 11 | 14 |
| 30 | 115 | 137 | 86 | 104 | 65 | 76 |
| 40 | 155 | 187 | 133 | 162 | 104 | 126 |
| 50 | 190 | 223 | 169 | 198 | 137 | 162 |
| 60 | 216 | 248 | 198 | 227 | 166 | 191 |
| 70 | 227 | 270 | 205 | 245 | 184 | 216 |

| Яше, ел | I – II бонитет | | III бонитет | | IV – V бонитет | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | тулылыгы | | | | | |
| | 0,3 – 0,5 | 0,6 – 1,0 | 0,3 – 0,5 | 0,6 – 1,0 | 0,3 – 0,5 | 0,6 – 1,0 |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| 80 | 227 | 270 | 216 | 259 | 194 | 230 |
| 90 | 205 | 248 | 209 | 252 | 187 | 223 |
| 100 | 198 | 230 | 198 | 230 | 173 | 198 |
| 110 | 176 | 209 | 173 | 205 | 137 | 166 |
| 120 | 162 | 190 | 155 | 184 | 115 | 137 |
| 130 | 140 | 165 | 133 | 155 | 97 | 115 |
| 140 | 126 | 148 | 112 | 133 | 83 | 97 |
| 150 | 108 | 130 | 94 | 115 | 68 | 83 |

Башка токым утыртмаларындагы юкәлекләрнең һәм юкәнең бал продуктлылыгы 2.6.2.5 таблицада китерелә.

2.6.2.5 таблица

**Нормаль юкәлекләрнең продуктлылыгы (Мурахтанов буенча)**

| Яше | Утыртмаларның тулылыгы | | |
|---|---|---|---|
| | 1,0 – 0,8 | 0,7 – 0,6 | 0,5 – 0,3 |
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 20 | 6.45 | 6.24 | 5.04 |
| 30 | 28.12 | 27.73 | 22.87 |
| 40 | 43.35 | 42.49 | 35.32 |
| 50 | 53.09 | 52.04 | 42.98 |
| 60 | 61.52 | 60.25 | 49.93 |
| 70 | 66.44 | 65.14 | 54.03 |
| 80 | 59.04 | 67.25 | 56.05 |
| 90 | 67.29 | 65.96 | 54.50 |
| 100 | 62.11 | 60.65 | 50.57 |
| 110 | 55.49 | 54.24 | 45.13 |
| 120 | 48.72 | 47.71 | 39.57 |
| 130 | 41.30 | 40.43 | 33.67 |
| 140 | 35.18 | 34.47 | 28.63 |
| 150 | 30.08 | 29.34 | 24.46 |

Төрле утыртмалар составындагы юкәнең бал продуктлылыгын хисаплау буенча түбәндәге формула тәкъдим ителә:

$$M = N \times 0.1K \times C \times S,$$ биредә

M – кишәрлектә юкәнең бал продуктлылыгы;
N – 1 гектарга карата бал продуктлылыгы (табл.);
K – утыртма составындагы юкә коэффициенты;
C – юкәнең чәчәк ату озынлыгы, көннәр (14 көнгә тигез кабул ителә);
S – бүлемтек мәйданы.

Гомуми мөмкин булган нектар запасын билгеләгәндә бал кортлары нектарның 30% гына җыйганнарын исәпкә алырга кирәк.

Тагын шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, районнардагы умарталыкларда нектар пробаларын алудан һәм үсемлекләрнең һәм умартачылык җирләренең бал продуктлылыгын билгеләүдән гыйбарәт булган бал продуктлылыгын исәпләүләр – бик күп хезмәт таләп итә һәм бары тик фәнни хезмәткәрләр яисә шушы максатлар өчен әзерләнгән эзләнү экспедицияләре белгечләре тарафыннан гына башкарылырга тиеш.

Авыл хуҗалыгы культураларын үстерү

Авыл хуҗалыгы культураларын үстерү һәм башка төрле авыл хуҗалыгы эшчәнлеге алып бару өчен урманныкы булмаган җирләр, шулай ук урман утыртылмаган диләнкеләр, ачыклыклар һәм урмансыз һәм аларда урманнарны торгызганчы билгеләнгән җирләр кулланыла.

Авыл хуҗалыгы культураларын үстерү һәм башка төрле авыл хуҗалыгы эшчәнлеге алып бару өчен кулланыла торган урман кишәрлекләрендә химик һәм биологик препаратлар “Пестицидлар һәм агрохимикатлар белән сак эш итү турында” 19.07.1997 ел, №109-ФЗ Федераль закон нигезендә кулланыла.

Әлеге өлештә авыл хуҗалыгын алып бару өчен урманнардан файдалануның инде булган хокукый җайга салынышына авыл хуҗалыгы эшчәнлеге белән шөгыльләнүче затларга түбәндәге бурычлар йөкләнү турындагы нормалар өстәлә:

– гражданнарның сәламәтлегенә, әйләнә-тирә мохиткә зарар китерүгә юл куймаска;

– урманнардан файдаланганда туфрак эрозиясен булдырмаска, урманнарның торышына һәм аларны торгызуга, һәм шулай ук су объектларына һәм башка табигый объектларга тискәре йогынтыны булдырмаска яисә чикләргә;

## 2.7. Урманнардан фәнни-тикшеренү һәм мәгариф эшчәнлеге башкару өчен файдалану нормативлары, параметрлары һәм вакытлары

Россия Федерациясе урман законнары нигезендә фәнни-тикшеренү һәм мәгариф эшчәнлеген башкару өчен урман кишәрлекләре дәүләт учреждениеләренә, муниципаль учреждениеләргә – даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга, башка фәнни оешмаларга, белем бирү оешмаларына арендага бирелә.

Фәнни-тикшеренү һәм мәгариф эшчәнлеген башкару өчен урманнардан файдалануга урман кишәрлекләрендә урманнарны, табигатьнең бүтән компонентларын өйрәнү, алардан файдалану, аларны саклау, яклау торгызу өлкәсендә уку-гамәли базасы объектлары (урман табигатен өйрәнү, урманнарны исәпкә алу алымнарына, урман үсентеләрен кисүгә, урманнарны торгызуга өйрәтү һәм башка чаралар өчен полигоннар, тәҗрибә мәйданчыклары), укучыларда махсус белемнәр һәм күнекмәләр булдыру өчен урман инфраструктурасының кирәкле объектларын булдыру һәм алардан файдалану керә.

Фәнни-тикшеренү һәм мәгариф эшчәнлеген башкару өчен урманнардан файдалану әлеге Урман хуҗалыгы регламенты һәм урманнарны үзләштерү проекты нигезендә гамәлгә ашырыла.

Урманнарны фәнни-тикшеренү һәм мәгариф эшчәнлеге өчен файдаланганда түбәндәгеләр рөхсәт ителә:

махсус тамгалар, мәгълүмат тамгалары һәм белем бирү эшчәнлеге һәм фәнни-тикшеренү эшләре башкарыла торган территорияне чикли торган бүтән тамгалар урнаштырырга;

фәнни-тикшеренү максатларында урман утыртмаларын кисәргә;

урман инфраструктурасын булдырырга;

фәнни-тикшеренү эшләнмәләрен һәм тәҗрибә-конструкторлык эшләре нәтиҗәләрен тәҗрибә-җитештерү һәм гамәлгә кертү максатларында, урманнарны саклау, яклау, торгызу һәм алардан файдалану буенча эксперимент эшчәнлеген гамәлгә ашырырга;

уку-гамәли база объектларын булдырырга һәм алардан файдаланырга;

урманнарны үзләштерү проекты белән каралган бүтән төр эшләр.

Урманнарны фәнни-тикшеренү һәм мәгариф эшчәнлеге өчен файдаланганда түбәндәге очраклар булмаска тиеш:

бирелгән урман кишәрлегеннән читтә урман утыртмаларын, үсемлекләр капламын һәм туфрак зарарлау;

бирелгән урман кишәрлеген һәм аның чикләрендәге территорияләрне төзелеш һәм көнкүреш калдыклары, агач калдыклары, бүтән калдыклар белән чүпләү;

бирелгән урман кишәрлеге мәйданын һәм аның чикләрендәге территорияләрне химик һәм радиоактив матдәләр белән пычрату;

транспорт чараларының һәм бүтән механизмнарның бирелгән урман кишәрлеге читендәге юллардан гайре ирекле маршрут буенча узулары.

Фәнни-тикшеренү һәм мәгариф эшчәнлеген башкару өчен урманнардан файдаланучы затлар түбәндәгеләрне тиешле:

бирелгән урман кишәрлеген, аның янәшәсендәге урман аланнарын, ясалма һәм табигый су агып чыгу урыннарын төзелеш, урман кисү, көнкүреш һәм бүтән калдыклардан, агулы матдәләрдән даими рәвештә чистартып торырга;

эшчәнлек барышында бозылган юлларны, киптерү канауларын, дренаж системаларын, шлюзларны, күперләрне, башка гидротехника корылмаларын, квартал баганаларын, квартал юлларын торгызырга;

әлеге затлар гаебе белән барлыкка килгән һәлакәт очракларын, урман янгыннарын булдырмый калу, шулай ук башка шундый хәлләрне бетерү буенча кирәкле чаралар күрергә.

Фәнни-тикшеренү һәм мәгариф эшчәнлеген башкару өчен урманнардан рөхсәтле файдалану вакытлары әлеге Урман хуҗалыгы регламентының гамәлдә булу вакыты белән чикләнә.

## 2.8. Урманнардан рекреация эшчәнлеге башкару өчен файдалану нормативлары, параметрлары һәм вакытлары

### 2.8.1. Рекреация эшчәнлеге башкару өчен урманнардан файдалану нормативлары

Рекреация эшчәнлеген РФ УК белән кешеләрнең ялын, туризмны, физкультура-савыктыру һәм спорт эшчәнлеген оештыруга кагылышлы эшчәнлек буларак карала.

Урманнардан мондый файдалану (РФ УК 41 ст.) урман кишәрлекләре бирүне таләп итә, әмма урман ресурсларын җыймауны күз алдында тота торган эшчәнлек төренә кертелә, бирелгән урман кишәрлекләрендә кирәкле урман инфраструктурасы, шул исәптән вакытлы корылмалар булдырыла, территория төзекләндерелә (РФ УК 41, 13 ст.).

Рекреация эшчәнлеген оештыру үзенчәлекләре 21.02.2012 ел, №62 Рослесхоз боерыгы белән расланган Рекреация эшчәнлеген башкару өчен урманнардан файдалану кагыйдәләрендә бәян ителә.

Урманчылык урманнары ландшафтлар төркемнәре һәм типлары буенча түбәндәгечә бүленә, күрсәткечләр 2.8.1.1 таблицада китерелә.

2.8.1.1 таблица

**Ландшафт төркемнәре һәм типлары**

| Төркемнәр | Типлар | Урман ябалдашының гомуми йомыклыгы |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| Йомык | Горизонталь йомык агачлар | 1,0-0,6 |
| | 1,5 метрдан артыграк биеклектә булган шытымнар һәм урманчык ярусын исәпкә алып, вертикаль йомылган агачлар | 1,0-0,6 |
| Ярымачык | Агачлар арасы тигез булган сирәкләнгән, 1,5 метрдан артыграк биеклектә булган сирәк шытымнарлы һәм урманчыклы яисә аларсыз урман | 0,5-0,3 |
| | Агачлар арасы тигез булган сирәкләнгән, 1,5 метрдан артыграк биеклектә булган сирәк шытымнарлы һәм урманчыклы яисә аларсыз урман | 0,5-0,3 (төркемнәрдә – 0,7-0,6) |
| | 1,5 метрдан артыграк биеклектә булган яшь агачлар | 0,5-0,4 |
| Ачык | Сирәклекләр, биеклегенә бәйсез рәвештә куаклар сирәк кенә шытып чыга башлаган берән-сәрән агачлары булган кишәрлекләр | 0,2-0,1 |
| | Урман торгызылу яисә 1,5 метрга кадәрге биеклектәге куаклары булган кишәрлекләр (куелыгы нинди булуга карамастан) | |
| | Агач-куаклары булмаган кишәрлекләр | |

Урманда рекреация эшчәнлеген башкару түбәндәгеләрнең санлы күрсәткечләре ярдәмендә бәяләнә:

– рекреация ягыннан файдалану ешлыгына;

– рекреация басымына, мөмкин булган рекреация басымына;

– объектның рекреация сыешлыгына.

Рекреация басымы билгеле бер вакыт эчендә (сәгать, көн, ай, сезон, ел) урманнарның бер берәмлек мәйданында (1 гектарда) ял итүче кешеләр саны белән билгеләнә.

Аерым урман кишәрлекләренә рекреация басымы бик зур була, бигрәк тә автомобиль юллары, бакчачылык ширкәтләре, ял йортлары һәм башка савыктыру учреждениеләре буендагы нарат-каен урманнарына. Рекреация басымының һәм тулаем шәһәр урманнарындагы һәм алар янәшәсендәге территорияләрдәге антропоген йогынтының төп төрләре түбәндәгеләр:

– шәһәр халкының кышын һәм җәен урманнарда йөрүләре;

– спорт белән шөгыльләнүләр;

– урманнарда пикниклар;

– кыргый үсемлекләр (гөмбәләр һәм җиләкләр) әзерләү;

– кояшта кызынулар һәм су коенулар;

– турист походлары;

– пионер лагерьларында һәм ял йортларында сезонлы оештырылган ял;

– бакчачылык һәм яшелчәчелек белән шөгыльләнү;

– сәнәгать һәм көнкүреш калдыклары чүплекләре;

– шәхси транспортның оештырылмаган туктап торулары.

Мөмкин булган рекреация басымы – шактый вакыт дәвамында мондый йогынты нәтиҗәсендә урман биогеоценозларының үзлегеннән торгызылу үзенчәлекләреннән артып китмәгән басым. Ул гадәттә бик аз бозылуларга китерә һәм биогеоценозларының аерым элементларына сизелер-сизелмәс үзгәрешләр кертә, аның структур һәм функциональ тотрыклылыгын үзгәртми. Антропоген йогынты нәтиҗәләрен бетерү өчен максатлы урманчылык катышуы таләп ителми.

Урман үсентеләренә иң зур рекреацион басым елның җылы вакытына туры килә, гәрчә кайбер спорт төрләре кышын да гамәлгә ашырыла.

Түбәндә урман кишәрлекләрен, урман утыртмаларына мөмкин булган рекреация басымын бәяләү шкалалары һәм рекреация эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен арендага бирелгән урман кишәрлекләрен әзерләгәндә файдаланырга кирәк булган территорияне төзекләндерүнең якынча нормалары китерелә.

2.8.1.2 таблица

**Урман тирәлегенең рекреация деградациясен бәяләү шкаласы**

| Кишәрлекнең сыйфатламасы | Рекреация дегарадациясе стадияләре |
|---|---|
| 1 | 2 |
| Урман тирәлеге бозылу күренешләре юк, агачлар һәм куаклар үсеше нормаль, | 1 |

| Кишәрлекнең сыйфатламасы | Рекреация дегарадациясе стадияләре |
| --- | --- |
| 1 | 2 |
| аларда механик бозылулар юк; шытып чыкканнары һәм куаклары (төрле яшьтәге) яшәрлек. Әлеге урман төренә хас мүк һәм үлән капламы; аяк асты урман япмасы (сыгылмалы) бозылмаган. Рекреацияне җайга салу таләп ителми. | |
| Урман тирәлеге сизелер-сизелмәс үзгәргән һәм агачлар һәм куаклар үсеше начарайган, аларда берән-сәрән механик бозылулар бар; шытып чыкканнары һәм куаклары (төрле яшьтәге) яшәрлек, уртача куелыкта, 20%ка кадәр зарарланган һәм кипкән нөсхәләр бар. Мүк белән проект капланышы – 20%ка кадәр, үлән капламы – 50% кадәр (шулардан 1/10 – болын үсемлекләре); аяк асты урман япмасы бераз бозылган,туфрак һәм аяк асты урман япмасы тыгызланган; агачларның аерым тамырлары шәрәләнгән, туфракның 5%ка кадәр мәйданы минераль өлешенә кадәр тапталган. Рекреация эшчәнлеген җайга салу таләп ителә. | 2 |
| Урман тирәлеге шактый үзгәргән һәм агачлар һәм куакларүсеше зәгыйфьләнгән, кәүсәләр 10% кадәр механикзарарланган; шытып чыкканнары һәм куаклары (бер үкяшьтәге) зәгыйфьләнгән, уртача куелыкта яисә сирәк, 21-50% зарарланган һәм зәгыйфьләнгән нөсхәләр. Агач кәүсәләре тирәсендәге мүкләр, аларның проект капламы 70-60% (шулардан 2/10 болын үсемлекләре, чүп үләннәр калкый). Аяк асты урман япмасы тыгызланган, агачларның күп кенә тамырлары шәрәләнгән, туфракның 6-40% мәйданы минераль өлешенә кадәр тапталган. Рекреация эшчәнлеген актив җайга салу таләп ителә. | 3 |
| Агач-болын тибындагы урман тирәлеге бик нык үзгәргән, агачлар шактый зәгыйфьләнгән, кәүсәләр 11-20% кадәр механик зарарланган; шытып чыкканнары һәм урманчык (төрле яшьтәге) яшәрлек түгел (башлыча яшелләндерелгән кишәрлекләрдә), сирәк яисә бөтенләй юк, 50% артык зарарланган һәм зәгыйфьләнгән нөсхәләр. Мүкләр бөтенләй юк, проект үлән капламы 59-40% (шул исәптән 1/2 кадәр болын үсемлекләре һәм чүп үләннәр). Агачларның күп тамырлары шәрәләнгән, ачык урыннарда аяк асты урман япмасы бөтенләй юк, туфракның 41-60% мәйданы минераль өлешенә кадәр тапталган. Рекреация эшчәнлеген катгый рәвештә тыярга кирәк. | 4 |
| Урман тирәлеге деградацияләнгән; агачлар бик сирәкләнгән, болын тибында, агачлар бик зәгыйфьләнгән яисә кибеп баралар, 20% артыгы механик зарарланган; шытып чыкканнары һәм урманчык, мүкләр, аяк асты урман япмасы юк, проект үлән капламы 10% кадәр (шул исәптән 3/4 кадәр болын үсемлекләре һәм чүп үләннәр), күп агачларның тамырлары шәрәләнгән һәм зарарланган. Туфракның 60% мәйданы минераль өлешенә кадәр тапталган. Рекреация рөхсәт ителми. | 5 |

2.8.1.3 таблица

## Кишәрлеккә санитар-гиниена бәяләмәсе шкаласы

| Кишәрлекнең (бүлемтекнең) сыйфатламасы | Санитар-гигиена бәясенең классы (балл) |
| --- | --- |
| 1 | 2 |

| | |
|---|---|
| Кишәрлек яхшы санитар хәлдә, һава чиста, яхшы аэрация,техноген шау-шулар, кан эчкеч бөҗәкләр, үтеп чыкмаслык куелыклар юк. Хуш исләр, урман авазлары, матур төсләр бар. | 1 |
| Кишәрлек шактый яхшы санитар хәлдә, бераз гыначүпләнгән, берән-сәрән кипкән агачлар бар, һава бераз пычрак, техноген шау-шулар вакыт-вакыт була яисә бөтенләй юк. | 2 |
| Кишәрлек начар санитар хәлдә, черегән үзагач белән чүпләнгән. Чүпләрне ташлау урыннары, карьерлар һәм аермалар бар, һава бик нык пычранган (шул исәптән начар исләр килә). Җилле, бик күләгә урын, техноген шау-шулар югары дәрәҗәдә, кан эчкеч бөҗәкләр бик күп, артык дымлы, үтеп чыкмаслык куелыклар бар. | 3 |

Искәрмә. Бәя кишәрлекне даими санитар тикшереп тору нәтиҗәсендә бирелә.

2.8.1.4 таблица

**Үсентеләрнең биологик тотрыклылыгын бәяләү шкаласы**

| Тотрыклылык класслары | Агымдагы һәлак булу күләме һәм сыйфатламасы (кибеп баручы агачлар һәм яңа гына кипкәннәр) | Кибүнең гомуми күләме (2 һәм 3 төркем хәлендәге агачлар + чүпләнү) | Корткычлар һәм авырулар булу | Урман тирәлеге торышы |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 1 - тотрыклы | 2% кадәр (1,3 м биеклектә диаметры уртачадан кимрәк булган агачлар хисабына) | 5% кадәр | Юк яисә берән-сәрән | Җимерелмәгән |
| 2 - тотрыклылыгы җимерелгән. | 2 аннан да күбрәк мәртәбә табигый һәлак булудан артык булган (1,3 м биеклектә диаметры уртачага якын булган агачлар хисабына) | 6% - 40% | Киң таралган яисә саны күп булырга мөмкин | Кагыйдә буларак, бозылган, тулылыгы тигез түгел яисә түбән |
| Тотрыклылык класслары | Агымдагы һәлак булу күләме һәм сыйфатламасы (кибеп баручы агачлар һәм яңа гына кипкәннәр) | Кибүнең гомуми күләме (2 һәм 3 төркем хәлендәге агачлар + чүпләнү) | Корткычлар һәм авырулар булу | Урман тирәлеге торышы |

Искәрмәләр:

Биологик тотрыклылыгы 2 нче класслы булган агачларга сайлап алып кисү уздыралар, 3 нчесендә – тоташ (башка хуҗалык күрсәтмәләре булмаганда).

2 нче һәм 3 нче класслы биологик тотрыклы урман үсентеләренең суммар мәйданы санитар хәле канәгатьләнерлек булмаган урман үсентеләре мәйданнарын тәшкил итә.

Үтеп керүчәнлек;

1 – яхшы;
2 – уртача;
3 – начар.
Күрүчәнлек:
1 – яхшы;
2 – уртача;
3 – начар.

2.8.1.5 таблица

**Кишәрлеккә эстетик бәяләмә шкаласы**

| Класс | утыртма буенча | Ачык урыннар |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1 | Озын һәм киң ябалдашлы, сәламәт һәм матур куаклары һәм уртача куелыкта шытымнары булган I-II бонитет класслы ылыслы һәм яфраклы утыртмалар. Яхшы үтеп керүчәнлекләе, чүпләнмәгән кишәрлек | 1,0 га кадәр мәйданы (ачыклыклар, аланнар), яхшы дренажланган әйбәт һәм коры туфрак; катлаулы, борылмалы чикләре булган 1 алып 3га кадәр мәйданлы, яхшы билгеләнгән рельефлы, декоратив урман авызлары булган кишәрлекләр, берән-сәрән декоратив агачлары яисә формалашкан агач-куак төркемнәре; декортаив үсемлекләр белән әйләндереп алынган, ярлары күренеп торган зур булмаган матур сулыклары бар |
| 2 | Ябалдашларның уртача киңлеге һәм зурлыгында, куе яки җәберләнгән яшь үсентеләр һәм куаклыклар булганда составтан 5 берәмлек зирек һәм усак катнашмалы III бонитет классы утыртмалары. Кишәрлек өлешчә чүпләнгән (5 м3/га кадәр) | Чикләре конфигурациясе гади булган зур күләмле ачык пространстволар; аз декоративлы үсемлекләр белән әйләндереп алынган су пространстволары; агач үсми торган, куак басып алган кишәрлекләр |
| 3 | Зирек һәм усак, шулай ук IV-V бонитет класслы ылыслылар өстенлек иткән үсентеләр. Агачларның ябалдашлары начар үсеш алган. Чүпләнгәнлек һәм коры-сары 5 м3/га һәм аннан да югары | Урман утыртылмаган киселгән урыннар, сөрүлекләр, электрүткәргеч линияләр, хуҗалыклар, сазлыклар һәм башка ачык мәйданнар, декоративлыгы түбән булган сулыклар |

Искәрмәләр:

Ачык ландшафтларны эстетик бәяләү түбәндәге күрсәткечләрне исәпкә алып уздырыла:

– урындагы торышы, туфрактагы дымлылык, үтеп йөрүчәнлек;

– кишәрлекнең зурлыгы һәм конфигурациясе;

– урман авызларының һәм ачык киңлекләр янәшәсендәге урыннарның гүзәллеге;

– агачларның һәм куакларның берән-сәрән яисә зур булмаган төркемнәре булу һәм аларны урнаштыру характеры;

– үлән һәм мүк капламының сыйфаты;

– сулыкларның күләме һәм конфигурациясе, ярларының һәм әйләнә-тирәсендәге үсемлекләрнең характеры, ял итүчеләрнең суга керә алуы, сулыкның санитар хәле һәм аны ял итү һәм коену өчен куллану мөмкинлеге.

2.8.1.6 таблица

**Агачлар торышы категорияләре шкаласы**
**(һәр агач саен инвентарьлаштыру өчен)**

| Агачларның категорияләре | Төп билгеләре | Өстәмә билгеләре |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| ЫЛЫСЛЫ ТОКЫМНАР | | |
| 1 - зәгыйфьләнү билгеләреннән башка | Ылыслары яшел, ялтырап тора, ябалдашы куе, әлеге токым, шушы яшьтәгеләр, үсү шартлары һәм ел фасылы өчен агымдагы елда шытып чыкканнары өчен нормаль | |
| 2 - зәгыйфьләнгән | Ылыслары еш кына ачык яшел, ябалдашы бик челтәрле түгел, шытып чыкканнары нормаль белән чагыштырганда яртылаш кимегән | Кәүсәсендә һәм тамырларында, ботакларында урыны-урыны белән зараланулар булырга мөмкин |
| 3 - бик каты зәгыйфьләнгән | Ылыслары ачык яшел яки сорырак тонык, челтәрле ябалдашлы, нормаль белән чагыштырганда шытып чыкканнары яртылаш кимегән | Кәүсәсендә, тамырларында һәм ябалдашында, ботакларында зараланулар булырга мөмкин, кәүсәләрендә яисә ботакларында корткычлар оялау сыйфатлары булырга мөмкин |
| 4 - кибеп баручы | Ылыслары соры, сары яисә саргылт-яшел, ябалдашы шактый сирәкләнгән, агымдагы елда шытым юк диярлек яисә бөтенләй юк | Кәүсәсендә һәм башка өлешләрендә зарарланулар алдагы категория белән чагыштырганда бик күп, кәүсәләрендә корткычлар оялау сыйфатлары (сагыз бүрәнкәләре, коңгырт он, кайрысында, кайры астында һәм үзагачында бөҗәкләр) булырга мөмкин |
| 5 - агымдагы елның коры-сарылары (яңа) | Агымдагы ел ылыслары, сары яисә коңгырт, ябалдашы бик нык сирәкләнгән, вак ботаклары бар әле, кайрысы сакланган яисә өлешчә коелган | Алдагы категория сыйфатлары; сезон азагында агачның бер өлешендә бөҗәкләр очып чыга торган тишекләр пәйда булу мөмкин |
| 6 - иске коры-сары узган елларныкы (иске) | Ылыслары коелган яисә өлешчә сакланып калган, вак ботаклары, кагыйдә буларак, сынып беткән, кайрысы коелган | Кәүсәсендә һәм ботакларында бөҗәкләр очып чыга торган тишекләр пәйда булган, кайрысы астында – бик күп коңгырт он һәм гөмбәчек |
| ЯФРАКЛЫ ТОКЫМНАР | | |
| 1 - зәгыйфьләнү билгеләреннән башка | Ылыслары яшел, ялтырап тора, ябалдашы куе, әлеге токым, шушы яшьтәгеләр, үсү шартлары | |

| Агачларның категорияләре | Төп билгеләре | Өстәмә билгеләре |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | һәм ел фасылы өчен агымдагы елда шытып чыкканнары өчен нормаль | |
| 2 - зәгыйфьләнгән (коры ябалдашлы 1/4 кадәр) | Яфраклары яшел; ябалдашы аз челтәрле, үсентесе нормаль белән чагыштырганда зәгыйфьрәк булырга мөмкин, корыган ботаклар 1/4 кимрәк | Кәүсәсендә һәм тамырларында, ботакларында урыны-урыны белән зараланулар, механик зарарланулар, берән-сәрән сулы шытымнар булырга мөмкин |
| 3 - каты зәгыйфьләнгән (коры ябалдашлы 1/2 кадәр) | Яфраклары гадәттәгедән ваграк яисә ачыграк төстә, вакытыннан алда коела, ябалдашы сирәкләнгән, кипкән ботаклары 1/4дән ½ гә кадәр | Алдагы категория сыйфатлары күбрәк чагылыш тапкан; кәүсәләрендә яисә ботакларында корткычлар оялау сыйфатлары булырга мөмкин, суты агу һәм сулы шытымнар булырга мөмкин |
| 4 – кибеп баручы, ябалдашларының 1/2еннән артыграгы кипкән | Яфраклары гадәттәгедән ваграк, сарырак яисә ачыграк төстә, вакытыннан алда коела яки корый, ябалдашы сирәкләнгән, кипкән ботаклары 1/2дән 3/4 кә кадәр | Кәүсәләрендә һәм ботакларында корткычлар оялау сыйфатлары (керү тишекләре, кисекләр, суты агу һәм агач вагы, коңгырт он, кайрысында, кайры астында һәм үзагачында бөҗәкләр), бик күп сулы шытымнар, өлешчә кипкән һәм кибеп баручы ботаклар булырга мөмкин |
| 5 - агымдагы елның коры-сарылары (яңа) | Яфраклары кипкән, шиңгән яисә вакытыннан алда коелган, кипкән ботаклары 3/4 артыграк, вак ботаклары һәм кайрысы сакланган | Кәүсәсендә һәм тамырларында, ботакларында бөҗәкләр оялау һәм гөмбәчекләр белән зарарлану сыйфатлары булырга мөмкин |
| 6 - иске коры-сары узган елларныкы (иске) | Яфраклары һәм ботакларның бер өлеше коелган, кайрысы черегән яисә кәүсәсенең зур өлешеннән каерылган | Кәүсәсендә һәм ботакларында бөҗәкләр очып чыга торган тишекләр пәйда булган, кайрысында һәм кайрысы астында – гөмбәчек һәм гөмбәләрнең үзләре була |

Җил аударганны, буран аударганны, кар аударганны, алар барлыкка килү вакытын күрсәтеп, аерым исәпкә алалар.

Яңадан санап чыкканда төрле категориядәге агачларга кәүсә корткычлары оялау һәм, зарарлану ачык күренеп торса, авырулар белән зарарлану дәрәҗәсе күрсәтелә. Ылыс һәм яфрак кимерүчеләр чыганакларында ылыслары һәм яфраклары торгызылганнан соңгы чорда агачлар яңадан санала, аңарчы кирәк чакта ылысны яисә яфракны ашау дәрәҗәсе процентларда күрсәтелә (1 – зарарсыз, 2 – аз гына зарарланган – 25% ким, уртача – 25-50%, бик нык – 50-75%, тулысынча – 75% артык).

Ял итү өчен табигать ландшафтларын тәртипсез һәм системасыз файдалану төзекләндерү элементлары булмау туфрак өстендәге капламны бозуга, урман тирәлеген пычратуга һәм урман бергәлекләренең (урман фитоценозының) гомуми зәгыйфьләнүенә китерә. Территорияне тышкы төзекләндерү – кешенең табигатькә тискәре йогынтысын азайтырлык бердәнбер цивилизацияле алым.

Урман тирәлеге, алдан урман кишәрлекләре рекреация өчен әзерләнмәгән булса, 10 кеше/га басым булганда җимерелә башлый. Шуңа күрә функциональ

зоналар буенча урнаштырыла торган рекреация объектларының табигать тирәлегеН бозмыйча гына ял итү мөмкинлеге тудыра торган мәйданчыклары булырга тиеш. Рекреация басымына карап, урман кишәрлекләреннән ял итү өчен файдалану режимы түбәндәгечә булырга мөмкин:

– ирекле – басым 5 кеше/га (тыныч ял итүнең аз төзекләндерелгән зонасы);

– уртача җайга салынучы – басым 6-20 кеше/га (актив ял итүнең җитәрлек дәрәҗәдә рекреацион объектлар белән төзекләндерелгән зонасы);

– катгый җайга салынучы – басым 20 кеше/га артык (актив ял итүнең аерым урман кишәрлекләре, алар максималь рәвештә төзекләндерелгән булырга тиеш).

2.8.1.7 таблица

**Рекреация билгеләнешендәге урманнарда урманнардан файдалануның төп хуҗалык чаралары һәм төрләре**

| № п/п | Чараларның исеме | Функция зоналары | | |
|---|---|---|---|---|
| | | актив ялныкы | йөреп керә торган | фауна тынычлыгыныкы |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 1. Урман хуҗалыгы чаралары | | | | |
| 1. | Урманнарны карап тотканда түбәндәге максатларда кисү: | | | |
| | Ландшафтларны формалаштыру | + | + | - |
| | Аз кыйммәтле үсемлекләрне алып ташлау | + | + | + |
| | Табигый торгызылуга ярдәм итү | + | + | + |
| | Үрентене карап тоту | + | + | + |
| | Бар булган һәм булдырылган урман ландшафтларын карап тоту | + | + | + |
| | Утыртмаларны үзгәртеп кору һәм яңарту | + | + | - |
| 2. | Реконструкция кисүләре | + | + | - |
| 3. | Башка кисүләр түбәндәге максатларда: | | | |
| | Ачык ландшафтлар булдыру, ерактан күренешләрне чистарту | + | - | - |
| | Күренекле нокталарда рекреация карамагыннан кимчелекле үсемлекләрне алып ату | + | - | - |
| | Ял һәм тышкы төзекләндерү объектлары буенча төзелеш мәйданчыкларын чистарту | + | + | - |
| | Ачык ландшафтларны һәм күренекле урыннарны карап тоту | + | + | - |
| 4. | Агачларны һәм куакларны түбәндәге максатларда утырту: | | | |
| | Ландшафтларны формалаштыру | + | + | - |
| | Урманның санитар-гигиенасын һәм утыртмаларның тотрыклылыгын | + | + | - |

| № п/п | Чараларның исеме | Функция зоналары | | |
|---|---|---|---|---|
| | | актив ялныкы | йөреп керә торган | фауна тынычлыгыныкы |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| | арттыру | | | |
| | Урманны торгызулар | - | + | + |
| | Ремизалар булдыру | - | - | + |
| | Утыртмаларны реконструкцияләү | + | + | - |
| 5. | Болынлы газоннар булдыру | + | - | - |
| 6. | Ачык урыннардагы үлән катламнарын карап тоту | + | + | - |
| 7. | Табигатьне саклау чаралары | + | + | + |
| 8. | Санитар-саклык чаралары, ш.и. санкисүләр | + | + | + |
| 9. | Янгынга каршы чаралар | + | + | + |
| 10. | Урман бозуларны һәм ял итүчеләр тарафыннан урманга зыян салуларны кисәтү | + | + | + |
| II. Биотехник чаралар һәм фаунаны саклау | | | | |
| 1. | Хайваннар дөньясындагы шартларны яхшырту | - | - | + |
| 2. | Ашату мәйданнарын кору һәм җанварларны ашату | - | + | + |
| 3. | Кош ояларын кору һәм элеп чыгу | + | + | + |
| 4. | Урман хуҗалыгы эшләрен регтаментлау һәм чикләү | - | - | + |
| III. Территорияләрне тышкы төзекләндерү | | | | |
| 1. | Юл-сукмак челтәрләрен, автотукталышларны, ясалма корылмаларны булдыру | + | + | - |
| 2. | Рекреация маршрутларын булдыру | + | + | - |
| 3. | Күренекле урыннарны һәм карау мәйданнарын булдыру | + | + | - |
| 4. | Ял мәйданнарын булдыру һәм җиһазлау | + | + | - |
| 5. | Архитектураның вак формаларын һәм урман-парк җайланмаларын төзү һәм урнаштыру | + | + | - |
| 6. | Визуаль мәгълүмат | + | + | + |
| 7. | Ачык агитация | + | + | - |
| 8. | Төн кунулы җәйге ял буенча стационар урыннарны кору һәм җиһазлау | + | - | - |
| 9. | Тышкы төзекләндерү объектларын карап тоту, аларны төзекләндерү | + | + | + |
| IV. Урманнан файдалану | | | | |
| 1. | Өлгергән һәм картайган урман утыртмаларын кисү | - | - | - |
| 2. | Урман торгызу буенча кисүләр | - | - | - |
| 3. | Печән чабу | + | + | - |
| 4. | Көтү көтү | - | - | - |

| № п/п | Чараларның исеме | Функция зоналары | | |
|---|---|---|---|---|
| | | актив ялныкы | йөреп керә торган | фауна тынычлыгыныкы |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 5. | Җиләкләрне, гөмбәләрне, чикләвекләрне һәвәскәр җыю | + | + | - |
| 6. | Дару чималын һәвәскәр җыю | + | + | - |
| 7. | Умартачылык | - | - | - |

Искәрмәләр: "+" тамгасы – файдалану рөхсәт ителә;
"-" тамгасы – файдалану рөхсәт ителми;

### 2.8.2. Рекреация эшчәнлеге зонасын функция территорияләренә бүлгәләү

Функциональ бүлгәләнеше буенча рекреация зоналары түбәндәгеләргә бүленә:

1) интенсив кулланылышлы;
2) чамалап кулланылышлы;
3) оешкан төстә ял итү;
4) резерватлы;
5) тыюлык;
6) катгый режимлы;
7) хуҗалык итүле.

### 2.8.3. Урман кишәрлекләрендәге вакытлыча корылмалар исемлеге һәм аларны тышкы төзекләндерү нормативлары

2.8.3 таблица

**Рекреация билгеләнешендәге урманнарда территорияне тышкы төзекләндерү нормалары (гомуми мәйданның 100 гектарында)**

| № п/п | Тышкы төзекләндерү элементлары исеме | Яшел зона | | Алар чикләрендә туристлык маршрутлары (1 чм маршрутка), |
|---|---|---|---|---|
| | | актив ялныкы | йөреп керә торган | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 1. | Гравийлы килү юллары хәрәкәт итү өлеше 4,5 м (чм) киңлектә булган | 0,15 | 0,02 | - |
| 2. | Массивлар эчендәге гравийлы юллар тасма киңлеге 3 м (чм) булган | 1,8 | 0,5 | - |
| 3. | 15 машинага исәпләнгән автотукталышлар гравий һәм вак ташлы (данә) | 0,25 | 0,03 | - |
| 4. | Йөреп керү сукмаклары (чм) | - | 0,04 | - |
| 5. | 4 урынлы утыргычлар (данә) | 18 | 3 | 1 |
| 6. | 6 урынлы ашап алу өстәлләре (данә) | 7 | 0,6 | - |
| 7. | Яңгырдан ышыклану урыннары | 1,5 | 0,2 | 0,2 |

| № п/п | Тышкы төзекләндерү элементлары исеме | Яшел зона | | Алар чикләрендә туристлык маршрутлары (1 чм маршрутка), |
|---|---|---|---|---|
| | | актив ялныкы | йөреп керә торган | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| | (данә) | | | |
| 8. | Азык әзерләү учаклары (данә) | 3,5 | 0,5 | 0,6 |
| 9. | Чүп савытлары (данә) | 30 | - | - |
| 10. | Чүп җыйгычлар (данә) | 3,5 | - | - |
| 11. | Бәдрәфләр (данә) | 0,18 | - | - |
| 12. | Спорт һәм уен мәйданчыклары, м3. | 37 | - | 5 |
| 13. | Елгалардагы һәм сулыклардагы кызыну урыннары, м2 | 90 | 15 | - |
| 14. | Кызыну урыннарындагы кабиналар (данә) | 0,18 | 0,02 | - |
| 15. | Беседкалар (данә) | 0,17 | - | - |
| 16. | Күрсәткечләр (данә) | 1,5 | 0,2 | 0,4 |
| 17. | Күренекле нокталар (данә) | 0,7 | 0,1 | 0,3 |
| 18. | Коелар һәм чишмәләр (данә) | 0,02 | 0,01 | 0,1 |
| 19. | Туристларга палатка кору өчен мәйданнар, м2 | 50 | - | 20 |

### 2.8.4. Рекреация эшчәнлеге башкару өчен урманнардан файдалану параметрлары һәм вакытлары

Урманнарда рекреация эшчәнлеге урман законнарының хокукый норматив актлары нигезендә расланган Рекреация эшчәнлеген башкару буенча урманнардан файдалану кагыйдәләре белән регламентлана, аларда түбәндәгеләр каралган:

рекреация эшчәнлеген башкарганда аерып алынучы урман кишәрлекләренең зурлыгын билгеләгәндә, урман утыртмаларына зарар китермәү шартларын үтәп, урман экосистемаларына карата оптималь рекреация басымына таянырга кирәк;

ял, туризм, физкультура һәм спорт эшчәнлеген оештыру максатларында рекреация эшчәнлеген башкару буенча урманнардан файдаланучы затлар туристлык станцияләрен, туристлык сукмакларын һәм трассаларын оештыра, мәдәни-массакүләм чаралар үткәрә, җәяүләп, велосипедта һәм чаңгыда шуа, сынлы сәнгать белән шөгыльләнә, кызыксындыргыч һәм экологик экскурсияләр, аларның спецификасы ярышларны урманда үткәрүгә каршы килми торган аерым спорт төрләре буенча спорт ярышларын, физкультура-спорт фестивальләрен һәм тренировка җыелышларын, һәм шулай ук рекреация эшчәнлегенең башка төрләрен оештыра ала;

рекреация эшчәнлеген башкаруга бирелгән урман кишәрлекләрендә табигый ландшафтлар, хайваннар дөньясы объектлары, су объектлары сакланырга тиешле;

рекреация эшчәнлеген башкару буенча урманнар әйләнә-тирә мохиткә һәм кеше сәламәтлегенә зарар китерми торган ысуллар белән файдаланыла;

урманнарны рекреация эшчәнлеген башкару өчен файдалану гражданнарның урманнарда булу хокукын чикләргә тиеш түгел;

урманнарда рекреация эшчәнлеген башкарганда урман кишәрлекләрендә вакытлыча корылмалар (беседкалар, инвентарьларны саклау пунктлары һ.б) торгызу һәм урман кишәрлекләрен тышкы төзекләндерүләр (юл-сукмак челтәрләрен, мәгълүмати элмә такталарны һәм табигатьне саклау тематикасына бәйле аншлагларны, утыргычларны, яңгырдан әвеслекләрне, хәрәкәт итү юнәлеше күрсәткечләрен, чүп өчен әрҗәләр һәм тышкы төзекләндерүнең башка элементларын урнаштыру) рөхсәт ителә;

бирелгән урман кишәрлекләрен тышкы төзекләндерү максатларында урманнардан рекреация эшчәнлеген башкару буенча файдаланучы затлар урманнарны үзләштерү проекты нигезендә карап тота;

вакытлыча корылмаларны, физкультура-сәламәтләндерү, спорт һәм спорт-техник корылмаларны вакытлыча урнаштыру барыннан да элек агачлар һәм куаклар булмаган урыннарда, ә алар булмаганда - артык кыйммәтле булмаган урман утыртмалары булган урыннарда, урманнарны үзләштерү проектында билгеләнгән урыннарда рөхсәт ителә;

урманнарда рекреация эшчәнлеген башкару буенча объектларны төзү максатларында урман утыртмаларын урманнарны үзләштерү проекты нигезендә кисү рөхсәт ителә;

урманнарда рекреация эшчәнлеген башкарганда бирелгән урман кишәрлеге чикләрендә урман утыртмаларын, үсемлек капламын һәм туфракларны зарарлау, бирелгән урман кишәрлеген һәм янәшә урнашкан территорияләрне көнкүреш калдыклары, башка төр калдыклар белән чүпләү, транспорт чаралары һәм башка төр механизмнар белән ирекле, билгеләнмәгән маршрутлар белән керү рөхсәт ителми;

Халыкның массакүләм ялын кече архитектура формаларын урнаштыру һәм ял итү һәм тәмәке тарту урыннарын кору юлы белән уңайлы шартлар тудыру урман экосистемаларының экология шартларына тискәре рекреация йогынтысын киметергә мөмкинлек бирәчәк;

Халыкның культуралы ялы буенча шартлар тудыру һәм рекреация басымнарын җайга салу максатларында территорияләрне тышкы төзекләндерү буенча мөмкин булган чаралар тәкъдим ителә, алар урман кишәрлекләрен халыкның ялы өчен тагын да югарырак сыйфатлырак дәрәҗәдә куллану мөмкинлеген бирәчәк:

- урман плакатларын һәм панно элү;
- автотукталышлар төзү һәм җиһазлау;
- гап-гади җайланмалар ярдәмендә тәмәке тарту урыннарын кору;
- юл-сукмак челтәрләрен төзү;
- урман җиһазларын урнаштыру (ашау өстәлләре, утыргычлар, урындыклар);
- яңгырдан һәм начар һава шартларында ышыклану урыннарын булдыру;
- туристлар өчен палаткалар кору мәйданнарын җиһазлау;
- учаклар өчен урыннар билгеләү һәм җиһазлау;
- азык әзерләү өчен учаклар кору;
- учаклар өчен утын әзерләү;
- чүп өчен савытлар кую һәм чүпҗыйгычлар урнаштыру;

- кизләүләрдән эчәр су алу урыннарын кору;
- бәдрәфләр төзү;
- кошлар өчен ашату мәйданнарын һәм җимлекләр кору;
- тиеннәр, куяннар һәм тояклылар өчен катырлар кору;

Рекреация урманнарында туфрак-мелиоратив чаралар үткәрелергә мөмкин: ашлама кертергә, известьларга, мульчаларга, көпшәкләндерергә, киртәләргә;

Рекреация эшчәнлеген алып бару, урман сукмакларыннан һәм гидротехника корылмаларыннан гайре, капиталь төзелеш объектларын төземичә генә, урманчылык территориясендә рөхсәт ителә;

Урманнар кешеләрнең ялын, туризмны, физкультура-савыктыру һәм спорт эшчәнлеген оештыру максатларында рекреация эшчәнлеген алып бару өчен файдаланылырга мөмкин;

Рекреация эшчәнлеген алып бару өчен урман кишәрлекләре дәүләт учреждениеләренә, муниципаль учреждениеләргә – даими (озак вакытка) файдалануга, башка затларга – арендага бирелергә мөмкин;

Рекреация эшчәнлеген алып бару өчен урманнардан файдаланганда Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган Урманнарда санитар иминлек кагыйдәләре һәм Урманнарда янгын куркынычсызлыгы таләпләрен үтәүне тәэмин итү зарур;

Янгыннар сезонында урманнар территориясендә рекреация эшчәнлеген алып барганда массакүләм чаралар уздыру, җирле үзидарә органнары белән килештереп, файдаланыла торган урман кишәрлекләрендә учак ягу һәм чүп җыю урыннары булдыру шарты белән генә рөхсәт ителә.

Рекреация эшчәнлеген алып бару өчен урман кишәрлекләре даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга яисә арендага бирелгән затлар аны уңай дәүләт экспертизасы бәяләмәсе алган урманнарны үзләштерү проекты нигезендә гамәлгә ашыра.

## 2.9. Урманнардан урман плантацияләре булдыру һәм аларны эксплуатацияләү өчен рөхсәтле файдалану нормативлары, параметрлары һәм вакытлары

Урман плантацияләрен булдыру һәм аларны эксплуатацияләү билгеле бер максатчан токым урман үсентеләрен үстерүгә бәйле эшкуарлык эшчәнлегеннән гыйбарәт. Билгеле бер (максатчан) токым урман утыртмаларына, куелган сыйфатламалары булган үзагач алуны тәэмин итә торган ясалма чыгышлы урман утыртмалары кертелә. Урман плантацияләре урман фонды җирләрендә һәм башка категория җирләрендә (урман утыртмалары каплап алмаган җирләрдә һәм урманныкы булмаган җирләрдә) булдырылырга мөмкин. Урман плантацияләрендә урман утыртмаларын кисү һәм урман утыртмаларына кирт салу чикләүләрсез рөхсәт ителә (РФ УК 42 ст.).

Гражданнарга, юридик затларга урман плантацияләре булдыру һәм аларны эксплуатацияләү өчен урман кишәрлекләре – РФ УК нигезендә, җир кишәрлекләре – җир законнары нигезендә арендага бирелә.

Дәүләти яисә муниципаль милектәге урман кишәрлеген арендалау килешүе урманнардан азык-төлек урман ресурсларын әзерләү һәм дару үләннәре җыю өчен файдалану максатларында РФ УК 72 ст. 3 ө. нигезендә ун елдан алып кырык тугыз елга кадәр төзелә.

Плантация булдыру максатларында түбәндәгеләрне файдалану рөхсәт ителми: су саклау зоналарында урнашкан урманнарны; табигый һәм башка объектларны яклау функциясен үтәүче урманнарны; кыйммәтле урманнарны; махсус саклanучы урман кишәрлекләрендә урнашкан урманнарны.

## 2.10. Урманнардан җимешле, җиләкле, декоратив урман үсемлекләре һәм дару үләннәре үстерү өчен файдалану нормативлары, параметрлары һәм вакытлары

Урман җимешләрен, җиләкләр, декоратив үсемлекләр һәм дару үләннәре үстерү (РФ УК 39 ст.) җимешләр, декоратив үсемлекләр, дару үләннәре һәм башка шундый урман ресурслары алуга бәйле эшкуарлык эшчәнлегеннән гыйбарәт. Аларны үстерү өчен файдаланыла торган урман кишәрлекләрендә вакытлы корылмалар урнаштыру рөхсәт ителә.

Җимешле, җиләкле, декоратив урман үсемлекләрен, дару үләннәрен үстерү өчен, беренче чиратта, урман фонды җирләре составындагы урмансыз җирләр, һәм шулай ук урман булмаган диләнкеләр, аланнарны һәм аларга урман культураларын утыртканчы урманның табигый торгызылуы мөмкин булмаган башка урман утыртмалары белән капланмаган җирләр; рекультивацияләнергә тиешле (эшләнелгән торфлыклар һ.б.) җирләр файдаланыла.

Җимешле, җиләкле, декоратив урман үсемлекләрен, дару үләннәрен үстерү өчен реконструкцияләүгә билгеләнмәгән азкыйммәтле утыртма кишәрлекләре файдаланырга мөмкин;

Россия Федерациясенең Кызыл китабына, Татарстан Республикасы Кызыл китабына кертелгән үсемлек төрләре очрый торган урман кишәрлекләрен җимешле, җиләкле, декоратив урман үсемлекләрен, дару үләннәрен үстерү өчен куллану РФ УК 59 статьясы нигезендә тыела.

Җимешле, җиләкле, декоратив урман үсемлекләрен һәм дару үләннәрен үстерү өчен саклык урманнарыннан һәм урманнардагы махсус саклanучы кишәрлекләрдән файдалану тыела.

Азык-төлек урман продукциясен плантациядә үстерү перспективалары.

Кыргый үсүче азык-төлек һәм дару үләннәре өлкәсендә шактый гына табигый запаслар булуга карамастан, соңгы 20-30 елда кайбер төр җиләкләрне, җимеш бирә торган үсемлекләрне һәм гөмбәләрне ясалма үстерү тенденциясе барлыкка килде. Моның сәбәбе – плантацияләрдә үстерелгән продукциянең үзкыйммәте халыктан җыелган шул ук төр кыргый үсүче үсемлекләрне сатып алу бәяләренә караганда кимрәк чыга.

Плантацияләрдә барлык төр эшләрне дә бергә туплап һәм механикалаштырып була, шул исәптән әзерләүне дә, бер берәмлек мәйданнан уңышны арттырып, һава шартларына бәйлелекне бетереп, селекция өчен шартлар тудырып, продукциянең сыйфатын арттырып була.

Аз гына чыгымнар белән табигый шартларда иң продуктив үсемлекләрне сайлап алырга һәм аларда җимеш бирү һәм эксплуатацияләү (ягъни культуралаштыру) өчен оптималь шартлар тудырырга мөмкин.

Культивацияләнергә мөмкин булган һәм культураны гамәлгә керткәндә үз сыйфатларын югалтмый торган үсемлек төрләре плантацияләрен булдыру максатка ярашлырак.

Өлкә шартлары түбәндәгеләр плантацияләрен булдыру өчен яраклы: кара миләш (арония), сырганак, гөлҗимеш, кара карлыган һәм башка азык-төлек үсемлекләре, дару үләннәре, гөмбәләрдән – шампиньон плантацияләре.

Хәзерге вакытта, сатып алу бәяләре бик югары булганда, акчаны плантацияләр булдыруга тотарга тәкъдим итәргә мөмкин.

Гөлҗимеш плантацияләре өчен иң яхшы туфрак – озак су баса торган елгаларның үзәннәрендәге органик матдәләргә бай кара туфрак һәм куе соры урман туфрагы. Плантацияләр булдыру өчен сөргәннән, органик 100 т/га, фосфорлы 160 кг/га, калийлы 80 кг/га ашламалар керткәннән соң 3х1,5м чокырларга һәм буразналарга гөлҗимеш утыртыла, уңыш бу вакытта 5,0 тонна/га җитә.

Урманчылыкларда ясалма алым белән гади вешенка гөмбәсе үстерергә мөмкин. Бер тонна гөмбә җитештерү өчен лабораторияләрдә үстерелә торган инокулянт йоктырырга һәм плантациягә 25-30см озынлыктагы һәм 22см диаметрлы 700 усак кисәге утыртырга кирәк, өч ел эчендә бер тонна гөмбә алырга мөмкин булачак.

## 2.11. Урманнардан урман үсентеләренең утырту материалын (үсентеләр, чәчкеннәр) үстерү өчен файдалану нормативлары, параметрлары һәм вакытлары

Урман үсемлекләренең утырту материалын (үсентеләр, чәчкеннәр) үстерү урманнарны торгызу һәм үрчетү максатында гамәлгә ашырыла торган эшкуарлык эшчәнлегеннән гыйбарәт.

Урман үсентеләренең утырту материалын (үсентеләр, чәчкеннәр) үстерү өчен урман кишәрлекләре дәүләт учреждениеләренә, муниципаль учреждениеләргә – даими (чикләнмәгән вакытка) файдалануга, башка затларга арендага бирелә.

Урман үсемлекләренең утырту материалын (үсентеләр, чәчкеннәр) үстерү өчен урманнардан файдалану урманчылыкның яисә урман паркының урман хуҗалыгы регламентлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Россия Федерациясе Урман кодексының 24 статьясындагы 2 өлеше нигезендә урманнардан файдаланучы гражданнарның, юридик затларның урман хуҗалыгы регламентын һәм урманнарны үзләштерү проектын үтәмәүләре урман кишәрлеген арендалау килешүен вакытыннан алда туктату, шулай ук урман кишәрлегеннән даими (чикләнмәгән вакытка) файдалану хокукын мәҗбүри туктату өчен нигез була.

Урманнардан файдаланучы гражданнар, юридик затлар Россия Федерациясе Урман кодексының 25 статьясында каралган тәртиптә граждан законнары

нигезендә үзагачка һәм башка алынган урман ресурсларына милекчелек хокукына ирешәләр.

Урман үсентеләренең утырту материалын (үсентеләр, чәчкеннәр) үстерү өчен урманнардан файдалану Россия Федерациясе Урман кодексының 27 статьясы нигезендә чикләнергә мөмкин.

## Урман үсентеләренең утырту материалын (үсентеләр, чәчкеннәр) үстерү өчен урманнардан файдаланучы затларның хокуклары һәм бурычлары.

Урман үсентеләренең утырту материалын (үсентеләр, чәчкеннәр) үстерү өчен урманнардан файдаланучы затлар түбәндәгеләргә хокуклы:

- урманнардан аренда килешүе шартлары нигезендә файдаланырга;
- Россия Федерациясе Урман кодексының 13 статьясындагы 1 өлеше нигезендә урман инфраструктурасы (урман юллары, урман складлары һәм башкалар) булдырырга;
- бирелгән урман кишәрлекләрендә теплицалар, башка корылмалар һәм төзелмәләр урнаштырырга;
- аларны гамәлгә ашыру Россия Федерациясенең урман законнары таләпләренә каршы килмәгән башка хокукларга ия булырга.

Урман үсемлекләренең утырту материалын (үсентеләр, чәчкеннәр) үстерү өчен урманнардан файдаланучы затлар түбәндәгеләргә хокуклы:

- урманнарны үзләштерү проектын төзергә;
- урманнардан урманнарны үзләштерү проекты нигезендә файдаланырга;
- урман кишәрлеге арендасы килешүе шартларын үтәргә;
- урман үсемлекләренең утырту материалын (үсентеләр, чәчкеннәр) үстерү өчен туфрак эрозиясе булдырмаучы, урманнарның торышына һәм аларны торгызуга, шулай ук су объектларына һәм башка табигать объектларына тискәре йогынтыны булдырмаучы яисә чикләүче алымнар белән урманнардан файдаланырга;
- урманнарда янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен, урманнарда санитар иминлек кагыйдәләрен үтәргә;
- ел саен урман декларациясе тапшырырга;
- урманнардан файдалану турында хисап тапшырырга;
- урманнарны саклау һәм яклау турында хисап тапшырырга;
- дәүләт урман реестрына билгеләнгән тәртиптә документлаштырылган мәгълүмат тапшырырга;
- Россия Федерациясе законнары белән каралган башка йөкләмәләрне үтәргә.

## Урман үсентеләренең утырту материалын (үсентеләр, чәчкеннәр) үстерү өчен урманнардан файдалануга карата таләпләр

Урман үсемлекләренең утырту материалларын (үсентеләр, чәчкеннәр) үстерү өчен, иң беренче чиратта, урман фонды җирләре составындагы урман белән капланмаган җирләрне, һәм шулай ук урмансыз диләнкеләрне, аланнарны

һәм башка, урман үсемлекләре белән капланмаган, урманнар урнашкан бүтән категория җирләре файдаланыла.

Урман үсемлекләренең утырту материалларын (үсентеләр, чәчкеннәр) үстерү өчен урман үсемлекләренең яхшыртылган һәм сортлы орлыклары, яки, әгәр андый орлыклар булмаса, урман үсемлекләренең нормаль орлыклары кулланыла.

Урман үсемлекләренең утырту материалларын (үсентеләр, чәчкеннәр) үстерү өчен урман үсемлекләренең районнарга бүленмәгән орлыкларын, һәм шулай ук сыйфаты тикшерелмәгән урман үсемлекләре орлыкларын, чәчүлекләрен һәм башкаларын куллану тыела.

Россия Федерациясенең Кызыл китабына, Россия Федерациясе субъектларының кызыл китапларына кертелгән үсемлек төрләре очрый торган урман кишәрлекләрен урман утыртмаларының утырту материалларын (үсентеләрне, чәчкеннәрне) үстерү өчен файдалану Россия Федерациясе Урман кодексының 59 статьясы нигезендә тыела.

## 2.12. Урманнардан җир асты байлыкларын геологик өйрәнү, файдалы казылма ятмаларын эшләп чыгару буенча эшләр башкару өчен файдалану нормативлары, параметрлары һәм вакытлары

Урман кишәрлекләреннән җир асты байлыкларын геологик өйрәнү, файдалы казылма ятмаларын эшләп чыгару буенча эшләрне башкару өчен файдалану урманчылыкның урман хуҗалыгы регламенты (РФ УК 43 ст.) нигезендә гамәлгә ашырыла.

Җир асты байлыкларын геологик өйрәнү эшләрен башкару өчен, файдалы казылма ятмаларын эшләп чыгару өчен урманнардан файдаланганда урман фонды җирләрендә урман инфраструктурасы булдыруга бәйле объектлар төзү, реконструкцияләү һәм эксплуатацияләү Россия Федерациясе Урман кодексының 21 статьясы нигезендә рөхсәт ителә. Урман инфраструктурасы булдыруга бәйле булмаган объектлар төзү, реконструкцияләү һәм эксплуатацияләү урманнарны үзләштерү проекты нигезендә гамәлгә ашырыла. Урманнар урнашкан башка категория җирләрендә җир асты байлыкларын геологик өйрәнү эшләрен башкаруга, файдалы казылма ятмаларын эшләп чыгаруга бәйле объектлар төзү, реконструкцияләү һәм эксплуатацияләү башка федераль законнар белән билгеләнгән очракларда шушы җирләрнең максатчан билгеләнеше нигезендә рөхсәт ителә.

Барлык очракларда кебек үк урман инфраструктурасы булдыруга бәйсез объектлар төзү, реконструкцияләү һәм эксплуатацияләү җирләрдән файдалану эшләре тәмамланганнан соң рекультивацияләнергә тиеш (РФ УК 21 ст. 6 өлеш).

Урман үсентеләрен кисү урманнардан файдалануның әлеге төренең бер өлеше булган очракларда җир асты байлыкларын геологик өйрәнү эшләрен башкару өчен аренда килешүләре нигезендә урман кишәрлекләре бирелә (РФ УК 43 ст. 2 өлеш).

Мондый эшләрне башкару урман үсентеләрен кисүгә китерсә, капиталь төзелеш объектларын төзү өчен урманнар үз вәкаләтләре чикләрендә дәүләт

хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары рөхсәтләре буенча урман кишәрлекләре бирмичә генә файдаланыла (РФ УК 43 ст. 3 өлеш).

Җир асты байлыкларын геологик өйрәнү эшләрен башкару өчен, файдалы казылма ятмаларын эшләп чыгару өчен урманнардан файдалану өчен урман кишәрлеген арендалау килешүе, аукцион уздыру таләп ителмәсә, ун елдан алып кырык тугыз елга кадәр төзелә (РФ УК 72 ст. 3 өлеш һәм 74 ст. 3 өлеш).

Урман кишәрлеге арендасының күрсәтелгән вакытлары җир асты турындагы законнарның таләпләрен исәпкә алып билгеләнә.

21.02.1992 ел, №2395-1 РФ Законының 10 статьясында билгеләнгәнчә, җир асты кишәрлекләре файдалануга билгеле бер вакытка бирелә:

– геологик өйрәнү өчен – 5 елга кадәр вакытка;

– файдалы казылмалар чыгару өчен – файдалы казылма ятмаларын эшкәртү срогына, ул файдалы казылма ятмаларын эшкәртүнең җир асты байлыкларыннан нәтиҗәле файдалануны һәм аларны саклауны тәэмин итә торган техник-икътисади нигезләүдән чыгып исәпләнә;

– җир асты суларын табу өчен – 25 елга кадәр вакытка;

– җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын вакытыннан алда туктатканда җир асты байлыкларыннан кыска вакытта файдалану хокукы бирү нигезендә файдалы казылмалар чыгару өчен – бер елга кадәр вакытка.

Файдалы казылма ятмаларын эзләүләрне, бәяләүне һәм эшкәртүне тәмамлау яисә ликвидацион чаралар күрү кирәк булган очракта, әлеге җир асты байлыкларыннан файдаланучы тарафыннан лицензия шартларын бозулар булмаганда, җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану срогы җир асты байлыкларыннан файдаланучы инициативасы буенча туктатылырга мөмкин.

РФ УК 20 статьясындагы 2 өлешендә җир асты байлыкларын геологик өйрәнү эшләрен башкару өчен, файдалы казылма ятмаларын эшкәртү өчен урманнардан файдаланганда алынган урман материалына милекчелек хокукы урнаштырыла.

Җир асты байлыкларыннан файдаланучылар үзагач әзерләргә җыенган очракларда, аны 23.07.2009 ел, №604 Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерергә тиеш. Моның өчен урман кишәрлеге бер үк вакытта төрле максатларда файдалану өчен бирелергә мөмкин (РФ УК 24 ст. 2 өлеш).

Җир асты байлыкларын геологик өйрәнү эшләрен башкару өчен, файдалы казылма ятмаларын эшкәртү өчен урманнардан файдалану тәртибе Россия Федерациясе Урман хуҗалыгы министрлыгының 27.12.2010 ел, №515 боерыгы белән расланган.

Әлеге норматив хокукый актта урман кишәрлеге бирмичә генә эшләр алып баруга рөхсәт бирү процедурасы билгеләнә.

Урман фонды җирләрендә урман кишәрлеге тапшырылмыйча гына җир асты байлыкларын геологик өйрәнү эшләрен башкару өчен җир асты байлыкларыннан файдаланучы (алга таба – Гаризачы) дәүләт хакимияте органнарына һәм җирле үзидарә органнарына әлеге Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелүче язмача гаризаны тапшыра, анда түбәндәгеләр күрсәтелә:

1) Гаризачы турында белешмәләр:

тулы һәм кыскартылган исеме һәм оештыру-хокукый рәвеше, урнашкан җире, почта адресы, банк реквизитлары – юридик зат өчен;

фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда), яшәү урынының адресы, шәхесен раслаучы документ белешмәләре, - шәхси эшмәкәр булган граждан өчен;

2) планлаштырыла торган эшләрне башкару өчен кирәкле урман фонды җирләренең урнашкан урыны һәм мәйданы, урманнардан файдалануны нигезләү һәм җир асты байлыкларын геологик өйрәнү эшләрен башкару вакыты.

Гаризага Гаризачы исеменнән эш йөртүче затның вәкаләтләрен раслаучы документ кушып бирелә (кирәк булганда).

Дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек юлы белән түбәндәге документларны алалар:

юридик затка карата Бердәм дәүләт юридик затлар реестрыннан өземтә;

физик затка карата Бердәм дәүләт шәхси эшмәкәрләр реестрыннан өземтә;

салым органында исәпкә алынуы турында белешмәләр;

җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензиясе яисә дәүләт ихтыяҗлары өчен җир асты байлыкларын геологик өйрәнү эшләрен алып баруга дәүләт контракты булу турында белешмәләр.

Гариза 30 көн эчендә карала һәм әлеге эшләрне башкаруга рөхсәт бирү турында карар кабул ителә.

Җир асты байлыкларын геологик өйрәнү эшләрен башкару өчен, файдалы казылма ятмаларын эшләү буенча урманнардан файдалану тәртибе белән җир асты байлыкларын геологик өйрәнү, файдалы казылма ятмаларын эшләү буенча эшләр башкаруга бәйле объектлар урнаштыру максатларында, иң беренче чиратта, урманныкы булмаган җирләр, урман кишәрлегендә мондый җирләр булмаганда – башланып та дәвам ителмәгән урман кисүләр җирләре, янгыннан соң калган җирләр, бушлыклар, ачыклыклар, шулай ук тулылыгы һәм кыйммәте түбән булган урман үсентеләре үсә торган мәйданнарны файдалану карала. Әлеге максатлар өчен бүтән урман кишәрлекләреннән файдалану җир асты байлыкларын геологик өйрәнү, файдалы казылма ятмаларын эшкәртү эшләрен башкаруга бәйле объектлар урнаштыруның башка вариантлары булмаган очракта рөхсәт ителә.

Җир асты байлыкларын геологик өйрәнү, файдалы казылма ятмаларын эшләү буенча эшләр башкаруга бәйле объектлар урнаштыру бирелгән урман кишәрлеге һәм аның янәшәсендәге территориядә эрозия үсешен булдырмаска тиеш.

Тиешле объектларның сак һәм санитар-яклау зоналарында урман утыртмаларын кисү урман кишәрлеген биргән дәүләт хакимияте органнары яисә җирле үзидарә органнары белән килештереп гамәлгә ашырыла.

Урманнарны җир асты байлыкларын геологик өйрәнү, файдалы казылма ятмаларын эшләү буенча эшләр башкару максатларында файдаланганда түбәндәгеләр рөхсәт ителми: агачларны аудару һәм урман кишәрлекләрен бульдозер ярдәмендә агач үсемлекләреннән чистарту; чиктәш полосаларны һәм урман авызларын агач материалы калдыклары белән чүпләү; урман авызы агачларының кәүсәләрен һәм үрелеп үскән тамырларын зарарлау, яңа киселгән

агач материалын җәйге чорда махсус яклау чараларыннан башка саклау; урман утыртмаларын су бастыру һәм озак вакыт су астында тоту; урманнарны төзелеш, сәнәгать, агач материаллары, көнкүреш һәм бүтән калдыклар белән чүпләндерү; урманнарны химик һәм радиоактив матдәләр белән пычрату; транспорт чараларында һәм бүтән механизмнарда ирекле, билгеләнмәгән маршрутлар буенча узу.

Яшел зоналарда һәм урман-парк зоналарында, һәм шулай ук шәһәр урманнары территорияләрендә файдалы казылма ятмаларын эшләү тыела.

Урманнардан җир асты байлыкларын геологик өйрәнү, файдалы казылма ятмаларын эшләү буенча эшләр башкару максатларында файдаланучы затлар түбәндәгеләрне башкара:

– бирелгән урман кишәрлеген, аның янәшәсендәге урман аланнарын, ясалма һәм табигый су агып чыгу урыннарын төзелеш, урман кисү, көнкүреш һәм бүтән калдыклардан, агулы матдәләрдән даими рәвештә чистартып тора;

– җитештерү эшчәнлеге барышында бозылган юлларны, киптерү канауларын, дренаж системаларын, күперләрне, башка гидротехника корылмаларын, квартал баганаларын, квартал юлларын, аншлагларны, урманнар территориясен төзекләндерү элементларын торгыза;

– әлеге затлар гаебе белән барлыкка килгән һәлакәт очракларын, урман янгыннарын булдырмый калу, шулай ук башка шундый хәлләрне бетерү буенча кирәкле чаралар күрә.

– сейсмик разведка эшләрен планлаштыру һәм башкару максатларында, квартал юллары, урман юллары биләгән һәм урман утыртмалары белән капланмаган башка җирләрдән максималь рәвештә файдалана, шул исәптән хәрәкәт составын һәм йөкләрне шуларда урнаштыра.

## 2.13. Урманнардан сусаклагычлар һәм башка ясалма су объектлары, һәм шулай ук гидротехника корылмалары һәм махсуслаштырылган портлар төзү һәм эксплуатацияләү өчен файдалану нормативлары, параметрлары һәм вакытлары

Сусаклагычлар һәм башка ясалма су объектлары, шулай ук гидротехника корылмалары һәм махсуслаштырылган портлар төзү һәм эксплуатацияләү буенча урманнардан файдалану РФ УК 44 ст. нигезендә гамәлгә ашырыла.

Сусаклагычлар һәм башка ясалма су объектлары, шулай ук гидротехника корылмалары һәм махсуслаштырылган портлар төзү һәм эксплуатацияләү буенча урманнардан файдалану су законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.

РФ Су кодексының 1 статьясы су объекты дип табигый яисә ясалма сулыкны, су агып төшү урынын йә суларның даими яисә вакытлыча җыелып торулары су режимының характерлы рәвешләренә һәм сыйфатларына ия булган бүтән су объектын аңларга тәкъдим итә.

Россия Федерациясе Су кодексының 5 статьясы ясалма су объектлары дип, аерым алганда, сусаклагычларны, буаларны һәм каналларны игълан итә.

Урман хуҗалыгында сусаклагычлар һәм буалар асылда кече һәм уртача елгаларда, шулай ук инешләрнең урман үткәрүчәнлеген көчәйтү өчен, урман

әзерләүне һәм бүтән җитештерүне су белән тәэмин итү өчен инешләрдә корыла һәм файдаланыла.

Урман хуҗалыгында каналлар асылда киптерү, сугару һәм суландыру һ.б. максатларында корыла һәм файдаланыла. Аерым очракларда сал агызу каналлары булдырылырга һәм эксплуатацияләнергә мөмкин.

Мондый максатлар өчен гидротехника корылмалары корыла һәм файдаланыла, аларга “Гидротехника корылмаларының иминлеге турында” 21.07.1997 ел, №117-ФЗ Федераль законның 3 статьясы нигезендә плотиналар, гидроэлектростанцияләр биналары, су җыю, су җибәрү һәм су чыгару корылмалары, туннельләр, каналлар, насос станцияләре, суднолар йөрү шлюзлары, суднолар күтәргечләр; су басулардан саклагычлар һәм сусаклагычлар ярлары, елгалар ярлары һәм үзәннәре төпләре җимерелүдән яклау өчен билгеләнгән корылмалар; сәнәгать һәм авыл хуҗалыгы оешмаларының сыек калдыкларыннан саклану өчен корылган корылмалар (дамбалар); каналларда су ишмәсен өчен билгеләнгән җайланмалар, шулай ук су ресурсларын файдалану һәм суларның һәм сыек калдыкларның зарарлы йогынтысын булдырмый калу өчен билгеләнгән башка корылмалар кертелә.

РФ УК шулай ук махсуслаштырылган портлар төзү һәм эксплуатацияләү өчен урманнардан файдалануны күз алдында тота.

РФ Сәүдә өчен диңгездә йөзү кодексының 9 статьясыннан чыгып, анда махсуслаштырылган диңгез портларына билгеләмә бирелә, РФ УК 44 статьясында күрсәтелгән махсуслаштырылган портлар дигәндә махсус бирелгән территориядә һәм акваториядә урнашкан һәм урман ресурсларын һәм урман хуҗалыгы һәм урман сәнәгате өчен кирәкле бүтән йөкләрне ташучы судноларга хезмәт күрсәтү өчен билгеләнгән корылмаларны аңларга кирәк.

Сусаклагычлар, бүтән ясалма су объектлары, шулай ук гидротехника корылмалары, махсуслаштырылган портлар төзү һәм эксплуатацияләү өчен урманнардан файдалану РФ УК 21 ст. нигезендә гамәлгә ашырыла яисә әлеге файдалану төре урман инфраструктурасы булдыруга бәйле булмаган объектлар төзүгә, реконструкцияләүгә һәм эксплуатацияләүгә бәйле булмау мөмкинлеге күрсәтелә.

РФ УК 21 статьясы 1 һәм 2 өлешләрендә күрсәтелгәнчә, урман фонды җирләрендә, шулай ук урманнар урнашкан башка категория җирләрдә сусаклагычлардан һәм бүтән ясалма су объектларыннан, шулай ук гидротехника корылмаларыннан һәм махсуслаштырылган портлардан файдалану өчен урман инфраструктурасы булдыруга бәйле булмаган объектлар төзү, реконструкцияләү һәм эксплуатацияләү рөхсәт ителә.

Әлеге максатларда урманнардан файдаланганда агачларны, куакларны, лианаларны кисү, шул исәптән гражданнарның иминлеген тәэмин итү һәм тиешле объектларны эксплуатацияләү өчен кирәкле шартлар тудыру өчен билгеләнгән саклау һәм санитар-яклау зоналарында да, рөхсәт ителә (РФ УК 21 ст. 5 өлеше).

РФ УК 21 ст. 6 өлеше нигезендә урман инфраструктурасы булдыруга бәйле булмаган гидротехника корылмалары төзү, реконструкцияләү һәм эксплуатацияләү өчен файдаланыла торган җирләр рекультивацияләнергә тиеш.

РФ УК 21 ст. 4 өлешендә күрсәтелгәнчә, гидротехника корылмалары су законнары нигезендә консервацияләнергә яисә ликвидацияләнергә тиеш, аны РФ УК 44 ст. өлеше таләпләрен гамәлгә ашыручы норма буларак карарга мөмкин, аның буенча су законнары нигезендә су объектлары, гидротехника корылмалары һәм махсуслаштырылган портлар төзү һәм эксплуатацияләү өчен урман кишәрлекләре файдаланылырга мөмкин.

Әлеге урманнардан файдалану урман ресурсларын алмыйча гына, әмма урман кишәрлекләре бирмичә мөмкин булмаган урманнардан файдалану төренә кертелә (РФ УК 44 ст. 2 һәм 3 өлешләре).

Шуның белән бергә сусаклагычлар һәм бүтән ясалма су объектлары, шулай ук гидротехника корылмалары һәм махсуслаштырылган портлар төзү һәм эксплуатацияләү өчен урман кишәрлегеннән башка су объекты да таләп ителергә һәм файдалануга бирелергә мөмкин.

Россия Федерациясе Су кодексының 11 ст. нигезендә причалларны урнаштыру, шулай урман кишәрлекләре гидротехника корылмалары, шул исәптән мелиоратив системалар урнаштыру һәм төзү су объектларын файдалануга тапшыру турындагы карарлар нигезендә генә мөмкин.

Су объектларын файдалануга тапшыру турындагы карарны әзерләү һәм кабул итү кагыйдәләре 30.12.2006 ел, №844 РФ Хөкүмәте карары белән расланган.

Дәүләти һәм муниципаль милектәге урман кишәрлекләре сусаклагычлар һәм бүтән ясалма су объектлары, шулай ук гидротехника корылмалары һәм махсуслаштырылган портлар төзү һәм эксплуатацияләү өчен даими (чикләнмәгән вакытка) файдалануга, арендага яисә түләүсез сроклы файдалануга бирелергә мөмкин. Моннан тыш, мондый урман кишәрлекләренә сервитутлар йөкләнергә мөмкин.

РФ УК 72 ст. 3 өлеше һәм 74 ст. 3 өлеше игезендә әлеге урман кишәрлекләре мондый максатлар өчен, дәүләт хакимияте органнары яисә җирле үзидарә органнары карарлары нигезендә аукционнар уздырмыйча гына, бер елдан алып кырык тугыз елга кадәр арендага бирелергә мөмкин.

Урман фонды җирләрендә урнашкан әлеге урманнардан файдаланудан алынган агач материалына милекчелек хокукы Россия Федерациясенеке була (РФ УК 20 ст. 2 өлеше).

## 2.14. Урманнардан линияле объектлар төзү, реконструкцияләү һәм эксплуатацияләү өчен файдалану нормативлары, параметрлары һәм вакытлары

Электрүткәргеч линияләр, элемтә линияләре, бүлемтек юллары, торбаүткәргечләр һәм башка линияле объектлар (алга таба – линияле объектлар) төзү, реконструкцияләү һәм эксплуатацияләү өчен урманнардан файдалану РФ УК 45 ст. белән регламентлана. Дәүләти яисә муниципаль милектәге урман кишәрлекләре гражданнарга һәм юридик затларга РФ УК 9 ст. нигезендә бирелә.

Урман фондындагы юллар урман юлларына һәм гомуми файдаланудагы юлларга бүленә. Урман юллары урман инфраструктурасы объектларына кертелә

(кара: РФ УК 13 ст. һәм 1 бүлеге), ә гомуми файдаланудагы автомобиль юллары һәм тимер юллар – урман инфраструктурасы булдыруга бәйле булмаган объектларга кертелә (кара: РФ УК 21 статьясы).

Электрүткәргеч линияләр, элемтә линияләре, бүлемтек юллары, торбаүткәргечләр һәм башка линияле объектлар урман инфраструктурасы булдыруга бәйле булмаган объектларга кертелә.

Урман инфраструктурасы булдыруга бәйле булмаган линияле объектлар төзү, реконструкцияләү һәм эксплуатацияләү урман фонды җирләрендә генә түгел, федераль законнар белән билгеләнгән очракларда, шул җирләрнең максатчан билгеләнеше нигезендә урманнар урнашкан башка категория җирләрдә дә рөхсәт ителә (РФ УК 21 ст. 1 һәм 2 өлешләр).

Урман инфраструктурасы булдыруга бәйле булмаган линияле объектлар төзегәндә, реконструкцияләгәндә һәм эксплуатацияләгәндә агачларны, куакларны, лианаларны кисү, шул исәптән гражданнарның иминлеген тәэмин итү һәм тиешле объектларны эксплуатацияләү өчен кирәкле шартлар тудыру өчен билгеләнгән саклау һәм санитар-яклау зоналарында да, рөхсәт ителә (РФ УК 21 ст. 5 өлеше).

Әлеге объектларны төзү, реконструкцияләү һәм эксплуатацияләү өчен файдаланыла торган җирләр рекультивацияләнергә тиеш (РФ УК 21 ст. 6 өлеше).

Урман инфраструктурасы булдыруга бәйле булмаган линияле объектлар төзү, реконструкцияләү һәм эксплуатацияләү өчен урманнардан файдаланганда агач материалы яисә бүтән урман ресурслары әзерләү таләп ителсә, урманнардан файдалану РФ УК 25 ст. 2 өлеше нигезендә бер үк вакытта берничә максат өчен гамәлгә ашырыла.

Әгәр урман фонды җирләрендә үзагач әзерләү РФ УК 29 статьясындагы кагыйдәләр буенча рәсмиләштерелмәгән булса, алынган агач материалына милекчелек хокукы Россия Федерациясенеке була (РФ УК 20 ст. 2 өлеше).

Дәүләт яисә муниципаль милектәге урман кишәрлекләрен гражданнарга һәм юридик затларга электрүткәргеч линияләр, элемтә линияләре, бүлемтек юллары, торбаүткәргечләр һәм башка линияле объектлар төзү өчен биргәндә урман, шулай ук җир һәм граждан законнары кагыйдәләре кулланыла.

Урман законнары кагыйдәләре буенча урман кишәрлекләре арендага бирелә, ә җир һәм граждан законнары кагыйдәләре буенча урман кишәрлекләре даими (чикләнмәгән вакытка) файдалануга һәм түләүсез сроклы файдалануга бирелә. РФ ҖК һәм РФ ГК нигезендә бу урман кишәрлекләренә гавами һәм хосусый сервитутлар билгеләнергә мөмкин.

РФ УК каралганча, дәүләти яисә муниципаль милектәге әлеге урман кишәрлекләренә бу хокуклар гражданнарга һәм юридик затларга бары тик линияле объектлар төзү өчен генә бирелергә тиеш.

РФ УК электрүткәргеч линияләрне һәм бүтән линияле объектлар эксплуатацияләү өчен урман кишәрлекләрен бирү мөмкинлеген билгеләми, шул исәптән гражданнарның иминлеген тәэмин итү һәм тиешле объектларны эксплуатацияләү өчен кирәкле шартлар тудыру өчен билгеләнгән саклау һәм санитар-яклау зоналарын билгеләү максатларында да.

Тагын шунысын да аерым билгеләп үтәргә кирәк, әлеге саклау зоналарының хокукый режимы РФ УК белән генә түгел, РФ ҖК белән дә билгеләнә.

РФ ЖК саклау зоналары чикләрендә төрле милекчеләрнең, җирдән файдаланучыларның, җир биләүчеләрнең һәм арендаторларның җир кишәрлекләре урнашкан булырга мөмкин булуын рөхсәт итә (87 статьяның 3 пункты).

Җир законнарының бу таләпләре урманнарда урнашкан сак зоналарына да кагыла.

Мондый алым урманнардан файдалануның гамәленә дә туры килә. Мәсәлән, сак зоналары чикләрендә урман кишәрлекләре азык-төлек урман ресурслары җыю, дару үләннәре әзерләү, печән чабу, авыл хуҗалыгы терлекләре көтү һәм башкалар өчен арендага бирелергә мөмкин. Бу чакта урманнардан файдаланучы гражданнар һәм юридик затлар сак зоналарының хокукый режимын үтәргә тиеш.

Гомуми файдаланудагы автомобиль юллары һәм тимер юллар, шул исәптән аларның сак зоналары турындагы мәсьәлә РФ УК 105 ст. белән җентекләп регламентлана (бу юлларның яклау полосалары яклау урманнары дип санала).

Башка линияле объектлар өчен – төзелеш һәм реконструкцияләү өчен, кирәк чакта – эксплуатацияләү өчен дә коммуникацияләр трассалары бирелә.

Урман хуҗалыгында коммуникация трассалары дип урманда электртапшыру линияләрен, телефон линияләрен, торбаүткәргечләрне һ.б. салу өчен киселүче полосаларны атыйлар. Әлеге полосаларны агач үсемлекләреннән чистарталар һәм аларның иминлеген булдыручы торышта карап тоталар.

Линияле объектларга кагылышлы мәсьәләләрне җайга салуның хокукый нигезе РФ ЖК, шулай ук федераль законнардан һәм РФ Хөкүмәтенең икътисадның тиешле тармаклары эшчәнлеге үзенчәлекләрен билгеләүче карарларыннан гыйбарәт.

РФ ЖК 89 ст. белән каралганча, энергетика оешмалары һәм объектлары эшчәнлеген тәэмин итү максатларында электр челтәре хуҗалыгы объектлары һәм электр энергетикасы объектлары турындагы Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән бүтән объектлар урнаштыру өчен җир кишәрлекләре бирелергә мөмкин.

Электр челтәре хуҗалыгы объектларының һәм электр энергетикасы объектлары турындагы Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән бүтән объектларның имин һәм аварияләрсез эшчәнлеген тәэмин итү өчен, әлеге җирләр составына керә торган категорияләренә бәйсез рәвештә, җир кишәрлекләреннән мондый сак зоналары билгеләнә. Әлеге сак зоналарын билгеләү һәм тиешле җир кишәрлекләреннән файдалану тәртибе РФ Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә.

Үз чиратында, “Электр энергетикасы турында” 26.03.2003 ел, №35-ФЗ Федераль закон электрүткәргеч линияләрен электр челтәре хуҗалыгы объектларына кертә һәм теләсә кайсы зат бу линияләрне төзергә хокуклы дип күрсәтә (3, 10 ст.).

Үткәргечләре җир һәм сулар өстеннән эленгән һава электрүткәргеч линияләре һәм көч кабель кулланыла торган кабельле электрүткәргеч линияләре (җир астыннан һәм сулар астыннан) бүленеше кабул ителгән.

Электрүткәргеч линияләре төзү өчен кирәкле җир кишәрлекләре күләме Һава электрүткәргеч линияләре һәм электр челтәренә хезмәт күрсәтүче элемтә линияләре баганаларын урнаштыру өчен җир кишәрлекләре күләмнәрен билгеләү

кагыйдәләре (П.08.2003 ел, №486 РФ Хөкүмәтенең карары белән расланган) нигезендә исәпләп чыгарыла.

Шушы Кагыйдәләрнең 6 пункты белән аларны урман фонды җирләренә карата да һәм энергетика җирләренә кертелмәгән, урманнар урнашкан бүтән категория җирләргә карата да куллану рөхсәт ителә.

10 КВ кадәр көчәнешле һава электрүткәргеч линияләре баганалары урнаштыру өчен (электр челтәренә хезмәт күрсәтүче элемтә линияләре баганалары), контур мәйданы буларак, җир кишәрлегенең, шул исәптән урман кишәрлегенең дә минималь күләмен билгеләү рөхсәт ителә, ул җир өслеге дәрәҗәсендә багананың аркылы киселешенә тигез була.

10 КВ кадәр көчәнешле һава электрүткәргеч линияләре баганалары урнаштыру өчен урман кишәрлегенең минималь күләме түбәндәгеләр буларак билгеләнә:

– җир өслеге дәрәҗәсендә баганаың проекциясе контурыннан 1 метр торган контур мәйданы (тартып торучы җайланмалары булган баганалар өчен – тартып торучысын да кертеп) – тирәнлеге 0,8 метрдан артмаган ригельләре булган баганалар урнаштыру өчен билгеләнгән, авыл хуҗалыгы җир кишәрлекләре белән чиктәш җир кишәрлекләреннән гайре, барлык категория җир кишәрлекләре белән чиктәш җир кишәрлекләре өчен;

– җир өслеге дәрәҗәсендә баганаың проекциясе контурыннан 1,5 метр торган контур мәйданы (тартып торучы җайланмалары булган баганалар өчен – тартып торучысын да кертеп) – тирәнлеге 0,8 метрдан артмаган ригельләре булган баганалар урнаштыру өчен билгеләнгән, авыл хуҗалыгы җир кишәрлекләре белән чиктәш җир кишәрлекләре өчен.

330 КВ һәм аннан да күбрәк көчәнешле, конструкциясендә җиргә беркетелә торган таянычы (тартып торучы җайланмасы) кулланыла торган һава электрүткәргеч линияләре баганалары урнаштыру өчен җир кишәрлекләренең минималь күләмнәрен барлык категория җирләр (авыл хуҗалыгы җирләреннән гайре) өчен һәр таянычының (тартып торучы җайланмасының) тышкы контурыннан 1 метрда торган, авыл хуҗалыгы җирләре белән чиктәш җир кишәрлекләре өчен – 1,5 метрда торган контурлары мәйданы буларак билгеләү рөхсәт ителә.

Һава электрүткәргеч линияләре баганалары электр челтәренә хезмәт күрсәтүче элемтә линияләре баганаларын урнаштыру өчен җир кишәрлекләренең конкрет күләмнәре, баганаларны җиргә беркетү зарурлыгыннан, баганаларның күләменнән һәм типларыннан, грунтның күтәрү сәләтеннән һәм баганаың тотрыклылыгын һәм эксплуатацияләү иминлеген тәэмин итү максатында багана мәйданчыгын инженер яктан төзекләндерү зарурлыгыннан чыгып билгеләнә.

РФ ЖК 91 ст. нигезендә элемтә тәэмин итү өчен (космик элемтәдән гайре) тиешле инфраструктура объектларын урнаштыру максатларында җир кишәрлекләре бирелергә мөмкин, түбәндәгеләрне кертеп:

– кабельле, радиорелейлы һәм һава элемтә линияләрен, кабельле һәм һава элемтә һәм радиофикация линияләре трассаларындагы радиофикация һәм элемтә линияләренең тиешле саклау зоналарын;

– җир асты кабельле һәм һава элемтә һәм радиофикация линияләре һәм элемтә линияләренең тиешле саклау зоналарын.

"Элемтә турында" 07.07.2003 ел, №126-ФЗ Федераль закон элемтә линияләрен тапшыру линияләре, физик чылбырлар һәм линия-кабель элемтә корылмалары буларак билгели. Анда шулай ук күрсәтелгәнчә, элемтә оешмаларына җир кишәрлекләре бирү мәсьәләләре, алардан файдалану тәртибе (режимы), шул исәптән элемтә челтәрләренең һәм элемтә корылмаларының саклау зоналарын урнаштыру һәм элемтә челтәрләрен урнаштыру өчен бүлемтек юллары уздыру, шушы җир кишәрлекләрен тартып алу нигезләре, шартлары һәм тәртибе җир законнары белән билгеләнә. Мондый җир кишәрлекләренең, шул исәптән саклау зоналары урнаштыру һәм бүлемтек юллары уздыру өчен бирелгән җир кишәрлекләренең күләмнәре тиешле эшчәнлек төрен, шәһәр төзелеше һәм проект документациясен гамәлгә ашыру өчен җирләр бүлеп бирү нормалары нигезендә билгеләнә.

Җирләрдә, шул исәптән урманнар урнашкан җирләрдә элемтә максатларында файдалануга кагылышлы мәсьәләләр 09.06.1995 ел, №578 РФ Хөкүмәте карары белән расланган Россия Федерациясе Элемтә линияләрен һәм корылмаларын саклау кагыйдәләрендә билгеләнгән.

Кабельле һәм һава элемтә линияләре трассаларындагы урман массивларында һәм урман үсентеләрендә түбәндәгечә бүлемтек юллары уздырылырга тиеш:

– үсентеләр биеклеге 4 метрдан кимрәк булганда – һава элемтә линияләренең һәм радиофикация линияләренең кырый үткәргечләре арасыннан ким булмаган һәм плюс 4 м киңлектә (кырый үткәргечләрдән агач ботакларына кадәр һәрьяклап 2шәр метр);

– үсентеләр биеклеге 4 метр булганда – һава элемтә линияләренең һәм радиофикация линияләренең кырый үткәргечләре арасыннан ким булмаган һәм плюс 6 м киңлектә (кырый үткәргечләрдән агач ботакларына кадәр һәрьяклап 3шәр метр);

– трасса буйлап элемтә кабеле – кимендә 6 м киңлектә (элемтә кабеленнән һәрьяклап 3әр м).

Элемтә линияләре трассалары агач-куаклардан даими рәвештә чистартып торылырга, янгын куркынычы кагыйдәләренә туры килерлек дәрәҗәдә тотылырга, юллар арасының билгеләнгән киңлеге үтәлергә тиеш. Үткәргечләргә һәм элемтә линияләре баганаларына куркыныч тудыручы агачлар киселергә тиеш.

Урман массивлары һәм урман үсентеләре аша уза торган кабельле һәм һава элемтә линияләре юллары элемтә линияләре үз карамагында булган предприятиеләр тарафыннан янгын куркынычы кагыйдәләренә туры килерлек дәрәҗәдә тотылырга тиеш.

Гамәлдәге кабельле һәм һава элемтә линияләре трассалары яклаучы урманнар территорияләре аша узса, махсус сакланылучы кишәрлекләрнең (сирәк һәм бетеп баручы хайваннар төрләрен ашату урыннары, балыкларның кыйммәтле токымнарының уылдык чәчү урыннары һәм башкалар) эшчәнлек әһәмияте кимемәгәндә генә бүлемтек юллары булдыру рөхсәт ителә.

Паркларда, бакчаларда, тыюлыкларда, шәһәрләр һәм торак пунктлары тирәсендәге яшел зоналарда, кыйммәтле урман массивларында, кыр саклагыч урман үсентеләрендә, автомобиль юллары һәм тимер юллар буендагы яклаучы урман полосаларында, елгалар һәм каналлар буендагы, күлләр һәм башка сулыклар тирәсендәге тыюлык урман полосаларында бүлемтек юллары уздыру үсентеләр торышына мөмкин кадәр аз зыян китерерлек һәм аларның яклау вазифалары югалмаслык итеп башкарылырга тиеш. Бүлемтек юлларында куаклыклар һәм яшь агачлар киселмәскә (кабельле элемтә линияләренең бүлемтек юлларыннан гайре), йомшак туфракларда, текә урыннарда (15 градустан артык) һәм сулар белән юыла торган урыннарда түмәрләр казып алынмаска тиеш.

Элемтә линияләре үз карамагында булган оешмаларга урман массивлары аша узучы элемтә линияләрендә, шушы линияләр трассалары тирәсендәге урыннарда аварияләр булган очракларда, саклау зоналарындагы аерым агачларны кисү рөхсәт ителә, әмма соңыннан кисү калдыклары җыеп алынырга тиеш.

РФ ҖК 90 статьясы билгеләгәнчә, оешмалар эшчәнлеген тәэмин итү һәм торбаүткәргеч транспорт объектларын эксплуатацияләү максатларында, түбәндәгеләр өчен җир кишәрлекләре бирелергә мөмкин:

– нефть үткәргечләрне, газүткәргечләрне, бүтән торбаүткәргечләрне урнаштыру;

– җир кишәрлекләреннән файдалануның аерым шартлары белән сак зоналарын билгеләү.

Газ белән тәэмин итү системасы объектлары урнаштырылган саклау зоналары чикләре төзелеш нормалары һәм кагыйдәләре, магистраль торбаүткәргечләрне саклау кагыйдәләре, билгеләнгән тәртиптә расланган башка норматив документлар нигезендә билгеләнә. Күрсәтелгән җир кишәрлекләрендә аларны хуҗалык алып бару өчен файдаланганда газ белән тәэмин итү объектларына кадәр билгеләнгән минималь ара чикләрендә нинди дә булса биналар, корылмалар төзү рөхсәт ителми. Газ белән тәэмин итү системасы оешмасына – милекчесенә яисә ул вәкаләт тапшырган оешмага газ белән тәэмин итү системасы объектларына хезмәт күрсәтү, аларга ремонт ясау, аларда килеп чыккан авария һәм һәлакәт зыяннарын бетерү эшләрен башкарганда каршылык күрсәтү рөхсәт ителми.

Хәзерге вакытта торбаүткәргечнең һәр төре өчен бүлеп бирелгән полосалар киңлеге һәм саклау зоналары чикләре еш кына төзелеш нормалары (СниП) белән билгеләнә.

Урманнар урнашкан һәм торбаүткәргечләр төзелә, реконструкцияләнә һәм эксплуатацияләнә торган җирләрдән файдалануның үзенчәлекләре законнар белән каралган.

Мәсәлән, “Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турында” 31.03.1999 ел, № 69-ФЗ Федераль законның 28 статьясы нигезендә газ белән тәэмин итү системасының урманнарда урнашкан объектлары (аларга газүткәргечләр дә керә) үз карамагында булган оешмалар түбәндәгеләрне үтәргә тиеш:

– газ белән тәэмин итү системасының сак зоналарын янгын куркынычсызлыгы халәтендә тотарга;

– газ белән тәэмин итү системасының сак зоналарында һәм мондый зоналардан читтә Россия Федерациясе урман законнары белән билгеләнгән тәртиптә билгеләнгән эшләрне башкарырга, агачларны (куакларны) кисәргә.

Газ бүлү челтәрләрен саклау буенча 20.11.2000 ел, №878 РФ Хөкүмәтенең карары белән расланган кагыйдәләрендә, аерым алганда, торбаүткәргечләр төзү, реконструкцияләү һәм эксплуатацияләү өчен урманнардан файдалануның түбәндәге үзенчәлекләре билгеләнә.

Саклау зоналары урманнар аша уза торган поселокара газүткәргечләр трассалары буйларында, – 6 м киңлектәге, газүткәргечнең һәр ягыннан 3 м киңлектәге бүлемтек юллары уздырыла. Газүткәргечләрнең җир өстендәге кишәрлекләре өчен агачлар белән газүткәргеч арасы газүткәргечне эксплуатацияләү вакытында агач биеклегеннән ким булмаска тиеш.

Газ бүлү челтәрләренең саклау зоналары урманнар буенча узганда газ бүлү челтәрләренең эксплуатацион оешмалары үз исәбеннән түбәндәгеләрне башкарырга тиеш:

– газ бүлү челтәрләренең сак зоналарын (урман юлларын) янгын куркынычсызлыгы халәтендә тотарга;

– урман юллары чикләре буйлап киңлеге кимендә 1,4 м булган минеральләштерелгән полосалар булдырырга;

– һәр 5-7 км саен янгынга каршы техника узып йөрерлек юл булдырырга.

Мондый сак зоналарында һәм аларның чикләрендә эшләр башкару Россия Федерациясе урман законнары белән билгеләнгән тәртиптә башкарылырга тиеш.

Авария очракларында эксплуатацион оешмага, соңыннан акт рәсмиләштерү шарты белән, техника һәм материаллар китерү өчен иң кыска маршрут буенча газ бүлү челтәрләренә килергә рөхсәт ителә. Урманнар аша узучы газүткәргечләрдә мондый эшләрне башкарганда, киселгән урыннарны калдыклардан чистарту шарты белән, агачларны кисү рөхсәт ителә.

Урман фонды җирләрендә газ бүлү челтәрләренә ремонт ясау, аларга хезмәт күрсәтү яисә аварияләре зыяннарын бетерү эшләрен башкарганнан соң эксплуатацион оешма бу җирләрне башлангыч хәленә китерергә (рекультивацияләргә) һәм аларны җир кишәрлеге милекчесенә, хуҗасына, аннан файдаланучыга яисә ул вәкаләт биргән затка акт буенча тапшырырга тиеш.

Газүткәргечләр урманнарны кисеп үткәндә саклау зоналарында аларны эксплуатацияләү тәртибе газ бүлү челтәрләренең эксплуатацион оешмалары, шулай ук җир кишәрлекләренең милекчеләре, хуҗалары, алардан файдаланучылар белән килештерелергә тиеш.

Линияле объектлар төзү, реконструкцияләү, эксплуатацияләү өчен урманнардан файдалануның 10.06.2011 ел, №223 Рослесхоз боерыгы белән расланган кагыйдәләрендә бу бурыч тулысынча хәл ителмәгән.

Электрүткәргеч линияләр, элемтә линияләре, бүлемтек юллары, торбаүткәргечләр һәм башка линияле объектлар төзү, реконструкцияләү һәм эксплуатацияләү өчен урманнардан файдалану кагыйдәләре урманнардан файдалануның әлеге төре өчен РФ УК белән билгеләнгән хокукый җайга салуга түбәндәге нормаларны өсти.

Линияле объектлар төзү, реконструкцияләү һәм эксплуатацияләү максатларында иң беренче чиратта урманныкы булмаган җирләр файдаланыла, ә урман кишәрлегендә мондый җирләр булмаганда – башланып та дәвам ителмәгән урман кисүләр җирләре, янгыннан соң калган җирләр, бушлыклар, ачыклыклар, шулай ук тулылыгы һәм кыйммәте түбән булган урман үсентеләре үсә торган җирләр.

Әлеге максатлар өчен бүтән урман кишәрлекләреннән файдалану бары тик линияле объектлар урнаштыруның башка вариантлары булмаган очракта гына рөхсәт ителә

Автомобиль юллары һәм тимер юллар төзү, реконструкцияләү һәм эксплуатацияләү өчен урманнардан файдаланганда өске сулар һәм туфрак эченә сулар агып төшүне боза торган, юллар буендагы урман кишәрлекләрен су бастыра һәм сазландыра торган очраклар булмаска тиеш.

Линияле объектлар төзү, реконструкцияләү һәм эксплуатацияләү биләнгән һәм шуның тирәсендәге территориядә эрозия процесслары арттырмаска тиеш.

Гражданнарның иминлеген тәэмин итү һәм линияле объектларны эксплуатацияләү өчен кирәкле шартлар тудыру өчен билгеләнгән саклау һәм санитар-яклау зоналарында урман үсентеләрен кисү шушы зоналарның билгеләнгән режимы нигезендә урман кишәрлеген файдалануга тапшырган дәүләт хакимияте органнары яисә җирле үзидарә органнары белән килештереп гамәлгә ашырыла.

Электрүткәргечләр һәм элемтә линияләре трассаларын 4 метрдан биегрәк агачлардан һәм куаклардан аларны кисү, химик яисә катыш алымнар белән бетерү юлы белән даими рәвештә чистарту рөхсәт ителә.

Бүлемтек юлыннан читтә үсүче һәм электрүткәргечләрнең һәм элемтә линияләренең үткәргечләренә яисә баганаларына авырга мөмкин булган аерым агачлар яисә агачлар төркеме үз вакытында киселергә тиеш. Электрүткәргечләргә һәм элемтә линияләренә (саклау зоналарына) якын булган урман авызларында комачаулаучы агачлар кичекмәстән киселә.

Линияле объектлар төзү, реконструкцияләү һәм эксплуатацияләү урманнардан файдаланганда түбәндәге очраклар булмаска тиеш:

– бирелгән урман кишәрлегеннән читтә урман үсентеләрен, үсемлекләр капламын һәм туфрак зарарлау;

– бирелгән урман кишәрлеген һәм бирелгән урман кишәрлеге чикләрендәге янәшә урнашкан территорияләрне төзелеш һәм көнкүреш калдыклары, агач калдыклары, бүтән калдыклар белән чүпләү;

– бирелгән урман кишәрлеге мәйданын һәм аның чикләрендәге территорияләрне химик һәм радиоактив матдәләр белән пычрату;

– транспорт чараларының һәм бүтән механизмнарның бирелгән урман кишәрлеге читендәге юллардан гайре ирекле маршрут буенча узарга.

Линияле объектлар төзү, реконструкцияләү һәм эксплуатацияләү максатларында урманнардан файдаланучы затлар түбәндәгеләрне тәэмин итә:

– бирелгән урман кишәрлеген, аның янәшәсендәге урман аланнарын, ясалма һәм табигый су агып чыгу урыннарын төзелеш, урман кисү, көнкүреш һәм бүтән калдыклардан, агулы матдәләрдән даими рәвештә чистартып тора;

– эшчәнлек барышында бозылган юлларны, киптерү канауларын, дренаж системаларын, шлюзларны, күперләрне, башка гидротехника корылмаларын, квартал баганаларын, квартал юлларын торгыза;

– әлеге затлар гаебе белән барлыкка килгән һәлакәт очракларын, урман янгыннарын булдырмый калу, шулай ук башка шундый хәлләрне бетерү буенча кирәкле чаралар күрә.

Линияле объектлар төзү, реконструкцияләү һәм эксплуатацияләү өчен урманнардан файдаланганда бозылган яисә пычранган җирләр тиешле эшләр тәмамланганнан соң кимендә бер ел эчендә рекультивацияләнергә тиеш.

Электрүткәргечләр һәм элемтә линияләре трассаларының туфрак катламы эрозияне арттырырлык итеп бозылган барлык киңлеге буенча үләннәр чәчү һәм (яисә) куаклар утырту юлы белән рекультивация уздырылырга тиеш.

## 2.15. Урманнардан үзагач һәм башка урман ресурслары эшкәртү өчен файдалану нормативлары, параметрлары һәм вакытлары

Агач материалы һәм башка урман ресурслары әзерләү өчен урман кишәрлекләреннән файдалану РФ УК 46 ст. белән регламентлана, Татарстан Республикасының урман планы һәм урманчылыкның урман регламенты нигезендә гамәлгә ашырыла. Урман эшкәртү объектларын урнаштыруның бүтән вариантлары булмаганда бүтән урман кишәрлекләреннән файдалану рөхсәт ителә.

Агач материалы һәм бүтән урман ресурсларын эшкәртү өчен урман инфраструктурасына бәйле булмаган объектлар төзү, реконструкцияләү һәм эксплуатацияләү РФ УК 21 ст. нигезендә рөхсәт ителә. Урман инфраструктурасы булдыруга бәйле булмаган объектлар төзү, реконструкцияләү һәм эксплуатацияләү урманнарны үзләштерү проекты нигезендә гамәлгә ашырыла.

Үзагач һәм бүтән урман ресурсларын эшкәртү өчен арендага бирелгән урман кишәрлекләрендә урман эшкәртү инфраструктурасы булдырыла (әзерләнгән үзагачны эшкәртү объектлары, биоэнергетик объектлар һәм башкалар) (алга таба – урман эшкәртү инфраструктурасы объектлары)

Урман эшкәртү инфраструктурасы объектларын урнаштыру максатларында иң беренче чиратта урманныкы булмаган җирләр файдаланыла, ә урман кишәрлегендә мондый җирләр булмаганда – башланып та дәвам ителмәгән урман кисүләр җирләре, янгыннан соң калган җирләр, бушлыклар, ачыклыклар, шулай ук тулылыгы һәм кыйммәте түбән булган урман үсентеләре үсә торган җирләр.

Урман эшкәртү инфраструктурасы объектларын яклаучы урманнарда һәм махсус якланучы урманнарда урнаштыру рөхсәт ителми.

Үзагач һәм бүтән урман ресурсларын эшкәртү өчен урманнардан файдалану кагыйдәләре “Үзагач һәм бүтән урман ресурсларын эшкәртү өчен урманнардан файдалану кагыйдәләрен раслау турында” 12.12.2011 ел, №517 Рослесхоз боерыгында билгеләнә.

## 2.16. Урманнардан дини эшчәнлек башкару өчен файдалану нормативлары, параметрлары һәм вакытлары

Урманнар дини оешмалар тарафыннан РФ УК 47 ст. һәм 1997 елның 26 сентябрендәге “Вөждан иреге һәм дини берләшмәләр турында” №125-ФЗ Федераль закон нигезендә дини эшчәнлек башкару буенча файдаланылырга мөмкин.

Дини эшчәнлек алып бару өчен бирелгән урман кишәрлекләрендә дини һәм хәйрия билгеләнешендәге биналар, корылмалар, төзелмәләр төзү рөхсәт ителә (РФ УК 47 ст. 2 өлеше).

Урманнардан әлеге файдалану, урман ресурсларын алмыйча гына, урман кишәрлекләрен биреп гамәлгә ашырыла.

Урман ресурсларын әзерләү һәм җыю, авыл хуҗалыгы һәм башка шундый эшчәнлек алып бару дини оешмалар тарафыннан бирелгән урман кишәрлекләрендә РФ УК бүтән статьялары нигезендә башкарылырга мөмкин.

Дини эшчәнлек алып бару өчен урманнардан файдалану субъектлары һәм тиешле урман кишәрлегенә мөлкәти хокуклары булган тиешле субъектлар дини оешмалар дип игълан ителә.

26.09.1997 ел, № 125-ФЗ Федераль законның 8 статьясы нигезендә дини оешма дип Россия Федерациясе гражданнарының, Россия Федерациясе территориясендә даими һәм законлы нигезләрдә яшәүче бүтән затларның бергә гыйбадәт кылу һәм дин тарату максатларында төзелгән һәм юридик затлар буларак законда билгеләнгән тәртиптә теркәлгән ирекле берләшмәсе танылa.

Юридик зат статусына ия булмаган дини берләшмәләргә, шулай ук дини төркемнәргә һәм аларда катнашучыларга дини максатларда урманнарны файдалану өчен бирү каралмаган. Дини оешмалар 08.08.2001 елдан, № 129-ФЗ Федераль закон нигезендә дәүләт теркәве узарга тиеш (дини оешмаларның вөждан иреге һәм дин тоту турындагы законнар белән билгеләнгән дәүләт теркәвен узу тәртибен исәпкә алып).

РФ УК 47 ст. 3 өлеше билгеләгәнчә, дәүләт яисә муниципаль милектәге урман кишәрлекләре дини оешмаларга дини эшчәнлек башкару өчен түләүсез сроклы файдалануга бирелә.

## 2.17. Урманнарны саклау, яклау, яңадан үстерүгә карата таләпләр

### 2.17.1. Урманнардагы янгын куркынычсызлыгы чараларына, урманнарны радиоактив матдәләрдән һәм бүтән тискәре йогынтыдан саклауга карата таләпләр

Урманнарны янгыннардан саклау РФ УК 51-53 статьялары, “Янгын куркынычсызлыгы турында” 21.12.1994 ел, №69-ФЗ Федераль закон, 30.06.2007 ел, №417 Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган Россия Федерациясе урманнарында янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләре (алга таба – Урманнарда янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләре) нигезендә гамәлгә ашырыла.

Урманнарда янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләре урманнарны саклаганда, яклаганда һәм торгызганда, урманнарда бүтән эшчәнлек башкарганда урманнарда янгын куркынычсызлыгын тәэмин итүгә карата бердәм таләпләр урнаштыра һәм

дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, шулай ук юридик затлар һәм гражданнар өчен үтәлеше мәҗбүр була.

Урманнарда янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләре һәр урман районы өчен Россия Федерациясе Табигать ресурслары министрлыгы тарафыннан билгеләнә.

Урманнарда янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү максатларында түбәндәгеләр гамәлгә ашырыла:

а) урманнарны янгынга каршы төзекләндерү, шул исәптән янгынга каршы юлларны, урманнарны яклау һәм саклау буенча авиация эшләре башкару максатларында самолетлар һәм вертолетлар өчен очып төшү мәйданчыклары төзү, реконструкцияләү һәм тоту, бүлемтек юллары салу, янгынга каршы аермалар казу;

б) урман янгыннарын кисәтү һәм сүндерү системаларын, чараларын булдыру, шушы системаларны һәм чараларны тоту, шулай ук янгын куркынычсызлыгы югары булган чорда ягулык-майлау материаллары запасларын формалаштыру;

в) урманнарда янгын куркынычын мониторинглау;

г) урман янгыннарын сүндерү планнарын эшләү;

д) урман янгыннарын сүндерү;

е) урманнарда янгын куркынычсызлыгы буенча башка чаралар.

Урманнарда янгын куркынычсызлыгының санап үтелгән чаралары дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары тарафыннан аларның вәкаләтләре чикләрендә Россия Федерациясе Урман кодексының 81-84 статьялары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Урманнарны янгынга каршы төзекләндерү, шул исәптән янгынга каршы юллар, урманнарны яклау һәм саклау буенча авиация эшләре башкару максатларында самолетлар һәм вертолетлар өчен очып төшү мәйданчыклары төзү, реконструкцияләү һәм тоту, бүлемтек юллары салу, янгынга каршы аермалар казу, шулай ук янгыннарны булдырмый калу һәм сүндерү системаларын, чараларын тоту, шулай ук янгын куркынычсызлыгы югары булган чорда арендага бирелгән урман кишәрлекләрендә ягулык-майлау материаллары запасларын формалаштыру урманнарны үзләштерү проекты нигезендә шушы урман кишәрлекләренең арендаторлары тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Урманнарда янгын куркынычсызлыгының гомуми таләпләре.

Кар катламы эреп беткәннән алып тотрыклы яңгырлы көзге көннәр урнашканчы яисә кар катламы барлыкка килгәнче урманнарда түбәндәгеләр тыела:

а) ылыслы яшь урманнарда, янгыннан соң калган урыннарда, зарарланган урман кишәрлекләрендә, торфлыкларда, кисек калдыкларыннан һәм әзерләнгән агач материалыннан чистартылмаган урманнар кискән урыннарда (урман бүлемтекләрендә), кипкән үләннәр мәйданнарында, шулай ук агачлар ябалдашлары асларында учак ягарга. Ябалдашлары асларында учак ягарга. Башка урыннарда учак ягу кимендә 0,5 метр киңлектәге минеральләштерелгән полоса белән уратып алынган (ягъни туфракның минераль катламына кадәр чистартылган) мәйданчыкларда рөхсәт ителә. Кисек калдыкларын яндыру

тәмамланганнан яисә учакны башка максатта файдаланганнан соң учак урынын әйбәтләп туфрак белән күмәргә яисә учак тәмам сүнгәнче су сибәргә кирәк;

б) янып торган шырпы, тәмәке төпчекләре һәм тәмәке төрепкәсеннән көл, пыяла (пыяла шешәләр, банкалар һәм башкалар) ташларга;

в) ау вакытында ягулык яисә пыскып торучы материаллардан тыккычлар кулланырга;

г) бензин, керосин яисә башка ягулык матдәләре сеңгән материалларны (кәгазь, тукыма, пәҗи, мамык һәм башкалар) шуның өчен махсус каралмаган урыннарда калдырырга;

д) двигатель эшләп торганда эчке янулы двигательләр бакларына ягулык салырга, туклану системасы төзек булмаган двигательле машиналардан файдаланырга, шулай урман кишәрлекләре ягулык салына торган машиналар янәшәсендә тәмәке тартырга яисә ачык уттан файдаланырга.

Урманнарны көнкүреш, төзелеш һәм бүтән төрле калдыклар белән чүпләү тыела.

Торак пунктыннан чыгарылган чүпне яндыру урман янәшәсендә бары тик махсус билгеләнгән урыннарда гына түбәндәге шартлар булганда рөхсәт ителә:

а) чүп яндыру урыннары (котлованнар яисә мәйданчыклар) кимендә түбәндәге ераклыкта урнашырга тиеш:

– ылыслы урманнан яисә аерым үсеп утыручы ылыслы агачлардан һәм яшь агачлардан – 100 метр;

– яфраклы урманнан яисә аерым үсеп утыручы яфраклы агачлардан һәм яшь агачлардан – 50 метр;

б) чүп яндыру урыны тирәсендәге территория (котлованнар яисә мәйданчыклар) 25-30 метр радиуста корыган агачлардан, ауган агачлардан, кисек калдыкларыннан, башка ягулык материалларыннан чистартылган һәм һәрберсенең киңлеге кимендә 1,4 метр булган ике катлы минеральләштерелгән полосалар белән әйләндереп алынган булырга, ә коры туфраклардагы ылыслы урман янәшәсендә һәрберсенең киңлеге кимендә 2,6 метр, аралары 5 метр булган ике катлы минеральләштерелгән полосалар белән әйләндереп алынган булырга тиеш.

Урманнарда янгын куркынычы сезонында чүп яндыру бары тик яраклы һава торышы булганда һәм җаваплы затлар контролендә генә рөхсәт ителә.

Урманнарга, яклаучы һәм яшелләндерү урман үсентеләренә якын җир кишәрлекләрендә даими күзәтүдән башка үлән яндыру тыела.

Урманнардан файдаланучы юридик затларның һәм гражданнарның бурычлары түбәндәгеләр:

а) ягулык-майлау материалларын ябык савытта саклау, янгын куркынычы сезонында аларны саклау урыннарын үлән катламыннан, агач материалы чүбеннән, башка ягулык материалларыннан чистарту һәм аларны 1,4 метр булган минеральләштерелгән полоса белән әйләндереп алу;

б) шартлаткыч матдәләр ярдәмендә түмәрләрне казып чыгарганда шушы эшләрне башкару хакында тиешле дәүләт хакимияте органнарына һәм җирле үзидарә органнарына аларны башлаганчы кимендә 10 көн кала хәбәр итәргә;

урманда янгын куркынычы зур булганда әлеге матдәләр ярдәмендә түмәрләрне казып чыгаруны туктатырга тиеш;

в) Россия Федерациясе Табигать ресурслары министрлыгы тарафыннан расланган урманнардан файдалану урыннарында янгын сүндерү чараларын булдыру нормаларын үтәргә, янгын куркынычы югары булган чорда янгын сүндерү чараларын аларны кичекмәстән кулланырлык итеп әзер килеш тотарга;

г) үзләре гаебе белән чыккан урман янгыннарын сүндерергә;

д) урманнардан файдалану урыннарында чыккан урман янгыннарын сүндерү буенча кичекмәстән чаралар күрергә, шулай ук янгын турында тиешле дәүләт хакимияте органнарына яисә җирле үзидарә органнарына хәбәр итәргә;

е) хезмәткәрләрне (юридик затлар өчен), янгын техникасын, транспорт һәм башка чараларны Россия Федерациясе законнары нигезендә янгын сүндерүгә җибәрергә.

Янгын куркынычы югары булган чор башланганчы урманнардан файдаланучы юридик затлар үз хезмәткәрләренә, шулай ук алар уздыра торган массакүләм чараларда катнашучыларга янгын куркынычсызлыгы таләпләрен үтәү, шулай ук урман янгыннарын сүндерү алымнары турында инструктаж уздырырга тиеш.

Янгын куркынычы класслары буенча урманчылык мәйданын бүлү 2.17.1.1 таблицада китерелә.

2.17.1.1 таблица

**Янгын куркынычы класслары буенча урманчылык мәйданын бүлү**

мәйданы, га

| № п/п | Кишәрлек урманчылыгы | Янгын куркынычы классы | | | | | Җәмгысе | Уртача класс |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | I | II | III | IV | V | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
| 1. | Питрәч | 891 | 5697 | 6686 | | | 13274 | 2,4 |
| 2. | Янтык | 369 | 1924 | 5947 | | | 8240 | 2,7 |
| 3. | Лаеш | 757 | 3699 | 8061 | | | 12517 | 2,6 |
| Урманчылык буенча барлыгы: | | 2017 | 6320 | 25694 | | | 34031 | 2,5 |
| % | | 6 | 18 | 76 | | | 100 | |

2011 елның 5 июлендәге "Урманнарның табигый янгын куркынычы классификациясен һәм һава шартларына бәйле рәвештә урманнарда янгын куркынычы классификациясен раслау турында" №287 Рослесхоз боерыгы белән расланган урман янгыннары чыгу дәрәҗәсе бәяләнде.

Шкала, токым составы үзенчәлекләрен, туфрак дымлылыгын, урман үсентеләренең яшен һәм торышын исәпкә алып, туфрак-типологик принцип буенча төзелде.

2.17.1.2 таблица

## Урманнарның табигый янгын куркынычы классификациясе

| Урманнарның табигый янгын куркынычы классификациясе | Янып китүчән объект (кисүләрдән соң урманнарның, урман утыртмаларының һәм урмансыз киңлекләрнең характерлы типлары) | Янгыннарның иң күп мөмкин булган төрләре һәм алар чыгуның һәм таралуның мөмкин чоры |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| I (бик югары табигый янгын куркынычы) | Ылыслы яшь агачлар Тоташ кисү урыннары: мүкле, арчанлы, кылганлы һәм коры урыннар буенча кисүләр (бигрәк тә чүпләнгән).<br>Мүкле һәм арчанлы наратлыклар.<br>Зәгыйфьләнгән, корып баручы һәм бик зарарланган агачлыклар (корыган агачлар, җил-буран аударган урыннар, кисеп бетермәгән урыннар), аерым агачлар калдырып, тоташ кисү урыннары, югары һәм бик югары интенсивлыктагы сайлап алып кисүләр урыннары, чүпләнгән элек янган урыннар. | Янгын куркынычы югары булган чор дәвамында – аскы өлештә, агачлар булган җирләрдә өске өлештә булырга мөмкин.<br>Кылганлы һәм башка үләннәр үскән коры урыннардагы урман кисүләрдә янгын куркынычы – бигрәк тә яз көне, ә кайбер районнарда көз көне дә югары була. |
| II (табигый янгын куркынычы - югары) | Нарат җиләкле, нарат шытымнары яисә уртача куелыктагы артыш куаклыклары булган наратлыкларда.<br>Кедрлы-стланниклы яфраклылар. | Янгын куркынычы югары булган чор дәвамында аскы өлештә; өске өлештә – янгыннар максимумнары чорында (янгын чыгу саны яисә янгын элеп алган мәйдан әлеге район өчен күпьеллык күрсәткечләрдән артып китә торган чор дәвамында). |
| III (табигый янгын куркынычы - уртача) | Ачы җиләкле наратлыклар һәм кара җиләклекләр, нарат җиләкле яфраклылар, барлык типтагы кедрлыклар, сфагналы, нарат җиләкле чыршылыклар һәм ачы җиләклекләр. | Аскы һәм өске янгыннар җәйге максимум чорында булырга мөмкин, ә кедрлыкларда, моннан тыш, язгы һәм бигрәк тә көзге максимумнарда. |
| IV (табигый янгын куркынычы - аз) | Тубылгылы һәм озын мүкле тоташ кисү урыннар (бигрәк тә чүпләнгән).<br>Үләнле типтагы урманнарда наратлыклар, яфраклылар һәм яфраклы урман үсентеләре.<br>Катлаулы наратлыклар һәм чыршылыклар, юкәлекләр, чикләвеклекләр, имәнлекләр, чыршылыклар-кара җиләклекләр, сфагналы һәм озын мүкле чыршылыклар һәм елга буйларындагы һәм сфагналы кедрлыклар, каенлыклар-мүк җиләклекләр, ачы җиләклекләр, | Янгыннар чыгу (беренче чиратта аскы) үләнле типтагы урманнарда, тубылгылы һәм озын мүкле кисү урыннарында язгы һәм көзге масимумнар чорында; башка тип урманнарда һәм озын мүкле кисүләрдә җәйге максимум чорында мөмкин. |

| Урманнарның табигый янгын куркынычы классификациясе | Янып китүчән объект (кисүләрдән соң урманнарның, урман утыртмаларының һәм урмансыз киңлекләрнең характерлы типлары) | Янгыннарның иң күп мөмкин булган төрләре һәм алар чыгуның һәм таралуның мөмкин чоры |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | кара җиләклекләр һәм сфагналы, усаклыклар-ачы җиләклекләр һәм кара җиләклекләр, мари. | |
| V (табигый янгын куркынычы - юк) | Чыршылыклар, каенлыклар һәм усаклыклар, озын мүклекләр, сфагнумлы һәм елга буйларындагы чыршылыклар. Барлык типтагы зиреклекләр. | Янгын бары тик аеруча начар шартларда (дәвамлы корылык) гына чыгарга мөмкин. |

| | - эшлекле | мең. м3 | - | - | - | | - |

| № п/п | Күрсәткечләр | Үлч. берәм л. | Һәлак булган һәм зарарланган урман утыртмаларын кисү | | | Урманнарны чүплрәдән чистарту | Җәмгысе |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Барлыгы | шул исәптән | | | |
| | | | | тоташ | сайланма | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
| **Урманчылык буенча барлыгы** | | | | | | | |
| 1. | Урманчылык таләпләре буенча ачыкланган фонд | га<br>мең. м3 | 1526<br>300,7 | 185<br>20,9 | 1341<br>279,8 | | 1526<br>300,7 |
| 2. | Кисеп ташлау яки чистарту вакыты | ел | | | | | |
| 3. | Ел саен файдаланылучы күләм: | | | | | | |
| | - мәйданы | га | 267 | 32 | 235 | | 267 |
| | Сайлана торган запас: | | | | | | |
| | - тамыр | мең. м3 | 20,27 | 11,39 | 8,88 | | 21,47 |
| | - ликвидлы | мең. м3 | 12,59 | 7,01 | 5,58 | | 12,59 |
| | - эшлекле | мең. м3 | 1,93 | 0,66 | 1,27 | | 1,93 |

### 2.17.3. Урманнарны яңадан үстерүгә карата таләпләр

Урманнарны торгызу Россия Федерациясе Урман кодексының 61, 62 статьялары, Россия Федерациясе Табигый ресурслар министрлыгының 16.07.2007 ел, №183 боерыгы белән расланган Урманнарны торгызу кагыйдәләре (алга таба – Урманнарны торгызу кагыйдәләре) белән гамәлгә ашырыла.

Урманнарны торгызу урман кисүләр җирләрендә, янгыннан соң калган җирләрдә, бушлыкларда, урман үсентеләре белән капланмаган башка ачыклыкларда яисә урман торгызу өчен яраклы җирләрдә киселгән, корыган, зарарланган урманнарны торгызу максатларында гамәлгә ашырыла. Урманнарны торгызу урман үсентеләрен торгызуны, урманнарның биологик күптөрлелеген, аларның файдалы функцияләрен саклап калуны тәэмин итәргә тиеш.

Урман торгызулар түбәндәгеләр белән тәэмин ителә:

– агач материалы әзерләү өчен арендага бирелгән урман кишәрлекләрендә - шушы урман кишәрлекләренең арендаторлары тарафыннан;

– урман кишәрлекләрендә, агач материалы әзерләү өчен арендага бирелгән урман кишәрлекләреннән гайре, – Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан.

Урманнарны торгызу өчен билгеләнгән һәр урман кишәрлегендә урманнарны торгызу гамәлләре урманнарны торгызу проекты нигезендә гамәлгә ашырыла.

Урманнарны табигый торгызуга ярдәм итү максатларында түбәндәге чаралар күрелә:

– урман үсентеләре ябалдашлары астында шытып чыккан урман үсентеләренең яшәргә сәләтле, әлеге табигый-климат шартларында яңа урман үсентеләре булдырырга сәләтле төп урман агач токымнары (алга таба – төп урман

агач токымнары) буынын (яшь агачларны) саклап калу. Ике яшькә кадәрге агач үсентеләре (үзлегеннән үсеп чыккан) яшь агачларга кертелми;

– кыйммәтле урман токымлы урман утыртмаларын кискәндә яшәргә сәләтле, яхшы тамыр җибәргән, 2,5 метрдан артык биеклектәге төп урман агач токымнарын булдыруда катнашучы урман үсентеләрен (яшь агачларны) саклап калу;

– урман үсемлекләре белән капланмаган мәйданнарда кыйммәтле агач токымнарының урман үсентеләре шытымнарын карау;

– туфрак өслеген минеральләштерү;

– мәйданнарны киртәләү.

Кыйммәтле урман агач токымнарының урман утыртмалары шытымнарын саклау чаралары урман утыртмаларын кисү белән бер үк вакытта гамәлгә ашырыла. Мондый очракларда кисүләр башлыча кар өсли кыйммәтле урман агач токымнары шытымнары һәм яшь агачлары санын урман бүлемтеге биргәндә каралганнан күбрәк юк итүдән һәм зарарлаудан саклауны тәэмин итәрлек технологияләр кулланып гамәлгә ашырыла. Кисүләр уздырганнан соң шытымнарны һәм яшь агач токымнарын кисек калдыкларыннан, сынган һәм зарарланган урман утыртмаларыннан арындыру юлы белән аларны карау уздырыла.

Кисүләр уздырганда урман үсентеләрен яшәргә сәләтле нарат, чыршы, пихта, имән, бук, корычагач һәм үзләренә туры килә торган табигать-климат шартларындагы кыйммәтле агач токымнарының бүтән урман үсентеләре шытымнары һәм яшь агачлары сакланып калырга тиеш.

Мәйданнарны киртәләү юлы белән урманнарны табигый торгызуга ярдәм күрсәтү яңа чыккан урман үсентеләренә һәм шытымнарына кыргый яисә йорт хайваннары зарар китерү куркынычы булган очракларда планлаштырыла һәм гамәлгә ашырыла.

Туфракны минеральләштерү юлы белән урманнарны табигый торгызуга ярдәм күрсәтү урман үсентеләренең кыйммәтле агач токымнары орлыклары чыганаклары (якындагы урман үсентеләре, аерым орлык агачлары яисә аларның төркемнәре, чәчәклекләре, полосалары, тулылыгы 0,6 артык булмаган урман үсентеләре ябалдашлары астындагы кисәргә керешелә торганнары) булган мәйданнарда гамәлгә ашырыла.

Хуҗалык эшчәнлеге чикләнгән режимдагы урманнарда, шул исәптән милли парклардагы урманнарда, табигать тыюлыкларында урманнарны табигый торгызуга ярдәм итүнең башка чаралары, алар тиешле территорияләрне саклау режимын бозарлык булмаса гына, гамәлгә ашырылырга мөмкин.

Урманнарны табигый торгызуга ярдәм итү буенча уздырылган чаралар нәтиҗәләре Урманнарны торгызу кагыйдәләре белән билгеләнгән шытымнарның куелык нормативларына туры килгәндә генә нәтиҗәле дип таныла. Урманнарны табигый торгызуга ярдәм итү чараларының нәтиҗәлелеген исәпкә алу эшләр башкарылганнан соң ике ел узгач гамәлгә ашырыла.

Агач токымнары белән урманнарны табигый торгызу уңышлы уздырылган мәйданнар урман үсемлекләре каплаган җирләргә кертелә.

Шытымнар саны Урманнарны торгызу кагыйдәләре белән билгеләнгәннән кимрәк булганда, урманнарны ясалма яисә катнаш торгызуның өстәмә чаралары карала.

Кыйммәтле урман агач токымнарын табигый торгызуга бәйле рәвештә урманнарны торгызу алымнары 2.17.3.1 таблицада китерелә.

2.17.3.1 таблица

**Кыйммәтле урман агач токымнарының табигый торгызылуына карап, урманнарны торгызу алымнары**

| Урман торгызу ысуллары | Агач токымнары | Урманнар типлары төркеме, урман үсү шартлары типлары | Яшәргә яраклы үсенте һәм яшь агач күләме, 1 гектарга мең данә |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| Ылыслы-киң яфраклы урманнар зонасы | | | |
| Россия Федерациясе Европа өлеше ылыслы-киң яфраклы (катнаш) урманнар районы | | | |
| Шытымнарны саклау чаралары ярдәмендә урманнарны табигый торгызу | Нарат, чыршы, карагай | Коры | 3 артык |
| | | Яңа | 1,5 артык |
| | | Дымлы | 1 артык |
| | Имән һәм бүтән 0,5 метрдан биегрәк булган каты яфраклылар | Коры | 4 артык |
| | | Яңа | 3 артык |
| | | Дымлы | 2 артык |
| Туфракны минеральләштерү юлы белән урманнарны табигый торгызу яисә урманнарны катнаш торгызу | Нарат, чыршы, карагай | Коры | 1 - 3. |
| | | Яңа | 0,5 - 1,5. |
| | | Дымлы | 0,5 - 1. |
| | Имән һәм бүтән 0,5 метрдан биегрәк булган каты яфраклылар | Коры | 2 - 4. |
| | | Яңа | 1 - 3. |
| | | Дымлы | 1 - 2. |
| Ясалма урман торгызу | Нарат, чыршы, карагай | Коры | 1 кимрәк |
| | | Яңа | 0,5 кимрәк |
| | | Дымлы | 0,5 кимрәк |
| | Имән һәм бүтән 0,5 метрдан биегрәк булган каты яфраклылар | Коры | 2 кимрәк |
| | | Яңа | 1 кимрәк |
| | | Дымлы | 1 кимрәк |

Урманнарны ясалма торгызу хуҗалык өчен кыйммәтле урман агач токымнарын урманнарны табигый торгызуны тәэмин итү мөмкин булмаганда яисә урманнарны катнаш торгызу максатка ярашсыз булганда, шулай ук урман культуралары һәлак булган урман кишәрлекләрендә гамәлгә ашырыла.

Урман культураларын булдыру өчен урман кишәрлеген әзерләгәндә шуннан соңгы барлык технологик гамәлләрне сыйфатлы үтәү өчен, шулай ук янгын куркынычын киметү һәм урман культураларының санитар торышын яхшырту өчен шартлар тудыру чаралары гамәлгә ашырыла.

Урман кишәрлеген әзерләүгә түбәндәгеләр керә:

– урман кишәрлеген тикшерү;

– урманнарны торгызуны проектлау;

– урман кишәрлеген бүлеп чыгару;

– урман культураларының яисә туфрак эшкәртү полосаларының булачак рәтләре линияләрен маркалау һәм техника эшләү өчен куркыныч булган урыннарны билгеләү;

– мәйданны ауган агачлардан, ташлардан, кирәксез агач үсемлекләреннән, вак түмәрләрдән, корыган агач кәүсәләреннән тоташ яисә полосалап чистарту;

– түмәрләрне казып алу яисә аларның биеклеген техника йөрешенә комачауламаслык дәрәҗәдә киметү;

– урман кишәрлеге өслеген планлаштыру, мелиоратив эшләр алып бару, авышлыкларда террасалар кисү;

– зарарлы туфрак организмнары белән башлангыч көрәш.

Туфракны эшкәртү алымнары урманнарны ясалма торгызуны проектлаганда табигать-климат шартларына, туфрак типларына һәм бүтән факторларга бәйле рәвештә сайлап алына.

Туфракны эшкәртү барлык кишәрлекләрдә (тоташ эшкәртү) яисә аның бер өлешендә (өлешчә эшкәртү) механик, химик яисә термик алымнар белән гамәлгә ашырыла. Нигезе, техника кулланып, туфракны механик эшкәртү була.

Урман культуралары төп бер агач токымының урман үсентеләреннән (чиста токымнардан) яисә төп берничә агач токымыннан һәм юлдаш агач һәм куак токымнарыннан (катнаш культуралар) булдырылырга мөмкин.

Урман культуралары төп бер агач токымының урман үсентеләреннән (чиста токымнардан) яисә төп берничә агач токымыннан һәм юлдаш агач һәм куак токымнарыннан булдырылырга мөмкин.

Бар булган юлдаш агач токымы җирле урман агач токымнарыннан һәм куак токымнарыннан сайлап алганда аларның төп урман агач токымына йогынтысын исәпкә алырга кирәк.

Юлдаш агач һәм куак токымнары урман культураларына кертү башлыча аларның рәтләрен төп урман агач токымы рәтләре белән чиратлаштырып гамәлгә ашырыла.

Урман культураларын булдыруның төп ысулы утырту материалының төрле төрләре белән гамәлгә ашырыла торган утыртудан гыйбарәт. Су һәм җил эрозиясенә дучар булган туфракларда, артык дымлы туфракларда һәм утырту урыннарын чүп үләннәр бик тиз басып китә торган кишәрлекләрдә, шулай ук дымлылык булмаган районнарда гамәлгә ашырырга кирәк.

Зарарлы организмнар таралу чыганакларында утыртуның (чәчүнең) башлангыч куелыгы) һәм урман культуралары составы махсус тикшеренүләр нигезендә билгеләнә.

Урман культураларын утырту һәм чәчү туфракка ашламалар, үсемлекләрне яклау чаралары кертү, шулай ук туфракны яхшырта торган махсус үләннәр чәчү белән бергә алып барылырга мөмкин.

Күп очракларда урман культураларын утыртуның һәм чәчүнең иң яхшы срогы – яз башы, бөреләр уяна башлаганчы.

Туфрак өслегеген чүп үләннәр һәм агач-куак үсемлекләре сырып алмасын, туфракта дым җыелсын өчен урман культураларын агротехник карау уздырыла.

Агротехник карауга түбәндәгеләр кертелә:

– үсемлекләрне үлән һәм туфрак өемнәреннән, ком өеменнән, туфракны су юып алып китүдән һәм җил белән очыртудан, салкыннан кысылудан кул ярдәмендә төзәткәләү;

– культуралар рәтләрендә һәм рәт араларында үлән һәм агач үсемлекләрен юк итеп, туфракны көпшәкләндерү;

– үлән һәм кирәксез агач үсемлекләрен юк итү һәм чыгуларын булдырмый калу;

– урман культураларын өстәү, минераль ашламалар белән тукландыру һәм урман культураларына су сибү.

Урман зонасында агротехник карау башлыча төп урман агач токымының урман үсентеләрен чүп үләннәр һәм кирәксез тиз үсә торган урман агач токымнары йогынтысы аркасында начар үсүдән һәм һәлак булудан саклап калу максатларында уздырыла.

Агротехник карау алымнары, саны һәм озынлыгы табигать-климат шартларына, культивацияләнә торган урман агач токымның биологик үзенчәлекләренә, туфрак эшкәртү алымына, урман культураларын булдыру ысулына, кулланыла торган утырту материалы зурлыгына бәйле була.

Чүп үләннәрне һәм кирәксез агач үсемлекләренә каршы көрәш өчен химик чаралар куллану, Россия Федерациясе урман законнары нигезендә әйләнә-тирә мохитне саклауны исәпкә алып, бик сирәк очракларда гына рөхсәт ителә.

Үсеп китү мөмкинлеге 25-85% булган урман культуралары (үсемлекләрнең һәлак булган нөсхәләре урынына яңаларын утырту) өстәлергә тиеш. Тигез һәлак булмый торган урман культуралары кишәрлек мәйданы буйлап үсеп китүчәнлегенә карамастан өстәләләр.

Урманнарны катнаш торгызу төп урман агач токымы урман үсентеләрен табигый торгызуның урман кишәрлекләрендә утырту һәм чәчү юлы белән гамәлгә ашырыла.

Урман культураларын утырту һәм чәчү юлы белән кертелгән төп урман агач токымы урман үсентеләре саны урман үсентеләре шытымнарына тигез яисә аннан да күбрәк булган урман кишәрлекләре мәйданнары урманнарны катнаш торгызу биләгән урман үсентеләрен саны ким булган мәйданнарга кертелә.

Урманнарны катнаш торгызганда урман культураларының куелыгы (бер мәйдан берәмлегендә утырту яисә чәчү урыннарының саны) төп урман агач

токымы урман утыртмаларының бар булган шытымнары һәм яшь агачлар санына карап билгеләнә.

Урман утыртмаларының ябалдашлары астында урманнарны катнаш торгызу гадәттә санитар-гигиеник функцияләрен арттыру максатларында яшел зоналарда, эрозиягә каршы һәм башка яклаучы урманнарда уздырыла.

Урман үсентеләре ябалдашлары астында урманнарны катнаш торгызу урман культураларының башлангыч куелыгы тиешле табигать-климат шартларында урманнарны ясалма торгызу өчен билгеләнгән норманың кимендә 50% тәшкил итәргә тиеш.

Үсеп китүчәнлеге кимендә 25% булган урман культуралары һәлак булган дип санала.

Урман агач токымнарының утырту материалына һәм урманнарны ясалма һәм катнаш торгызганда булдырылган, мәйданнары урман үсемлекләре белән капланган җирләргә кертелә торган яшь агачлар сыйфатына карата таләпләр 2.17.3.2 таблицада китерелә.

2.17.3.2 таблица

**Урман агач токымнарының утырту материалына һәм урманнарны ясалма һәм катнаш торгызганда булдырылган, мәйданнары урман үсемлекләре белән капланган җирләргә кертелә торган яшь агачлар сыйфатына карата таләпләр**

| Агач токымнары | Утырту материалына таләпләр | | | Мәйданнары урман үсемлекләре белән капланган җирләргә кертелергә тиешле яшь агачлыкларга карата таләпләр | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | яше, кимендә, ел | тамыр башланган җирдә кәүсәсе диаметры, кимендә, мм | кәүсәсе биеклеге кимендә, см | урманнар типлары төркеме яисә урман үсентеләре шартлары типлары | яше, кимендә, ел | төп токымнар агачлары саны кимендә, 1 гектарга мең данә | төп токым-нар агачлары ның уртача биеклегекимендә, м |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
| Ылыслы-киң яфраклы урманнар зонасы | | | | | | | |
| Россия Федерациясе Европа өлеше ылыслы-киң яфраклы (катнаш) урманнар районы | | | | | | | |
| Карелия каеныһәм еламсар каен (сөялле) | 2 | 3,0 | 25 | Нарат җиләкле, кымызлыклы, кара җиләкле | 4 | 2,0 | 1,1 |
| Еламсар каен (сөялле) | 2 | 2,5 | 20 | Яңа һәм дымлы имән катыш урман | 5 | 2,0 | 1,5 |
| Ботаклы-чатаклы имән | 1 - 2. | 3,0 | 12 | Яңа һәм дымлы имән катыш урман | 8 | 1,7 | 0,9 |
| Европа | 2 - 3. | 2,0 | 12 | Катлаулы, | 7 | 2,0 | 1,0 |

| Агач токымнары | Утырту материалына таләпләр | | | Мәйданнары урман үсемлекләре белән капланган җирләргә кертелергә тиешле яшь агачлыкларга карата таләпләр | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | яше, кимендә, ел | тамыр башланган җирдә кәүсәсе диаметры, кимендә, мм | кәүсәсе биеклеге кимендә, см | урманнар типлары төркеме яисә урман үсентеләре шартлары типлары | яше, кимендә, ел | төп токымнар агачлары саны кимендә, 1 гектарга мең данә | төп токым-нар агачлары ның уртача биеклегекимендә, м |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
| чыршысы (гади) | | | | вак үләнле, кара җиләкле | | | |
| | | | | Озын мүкле, үләнле-сазлыклы | 7 | 2,0 | 0,7 |
| Сукачев һәм Себер карагайлары | 2 | 2,5 | 15 | Нарат җиләкле, кымызлыклы, кара җиләкле | 5 | 1,7 | 1,2 |
| Себер эрбет нараты | 3 - 4. | 3,0 | 12 | Шул ук | 9 | 1,6 | 0,8 |
| | | | | Катлаулы, катлаулы вак үләнле | 5 | 1,5 | 1,5 |
| | | | | Озын мүкле, үләнле | 9 | 1,6 | 0,7 |
| Гади нарат | 2 | 2,0 | 12 | Лишайниклы, арчанлы | 7 | 2,5 | 0,8 |
| | | | | Нарат җиләкле, кымызлыклы, кара җиләкле | 7 | 2,0 | 1,2 |
| | | | | Озын мүкле һәм сфагнумлы | 7 | 2,2 | 1,0 |
| Гади корычагач | 2 | 4,0 | 15 | Яңа һәм дымлы имән катнаш урманнар һәм имәнлекләр | 6 | 2,0 | 1,5 |

Урман үрчетү Россия Федерациясе Урман кодексының 63 статьясы, Россия Федерациясе Табигый ресурслар министрлыгының 08.06.2007 ел, №149 боерыгы белән расланган Урман үрчетү кагыйдәләре (алга таба – Урман үрчетү кагыйдәләре) нигезендә гамәлгә ашырыла.

Урман үрчетү урман фонды җирләрендә һәм элегрәк су, җил һәм башка туфрак эрозиясен булдырмау, саклык урманнарын булдыру максатында һәм урманнарның потенциалын арттыруга бәйле башка максатларда урманнар үскән башка төр категория җирләрендә гамәлгә ашырыла.

Урман үрчетүгә түбәндәгеләр карый:

– урман фонды җирләре составындагы урман булмаган җирләрне урманлаштыру (сазларны киптерү, авыл хуҗалыгы куллануыннан чыгарылган җирләрне, чокырларны рекультивацияләү һ.б.);

– авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдә, сәнәгать, транспорт җирләрендә, су фонды җирләрендә һәм башка категория җирләрендә саклык урман утыртмалары булдыру;

– сәнәгать эшчәнлеге аркасында бозылган җирләрне рекультивацияләгәндә урман утыртмаларын булдыру;

– санатор-курорт зоналарда һәм башка объектларда урман утыртмалары булдыру.

Урман үрчетү куелган максатлар, җир кишәрлекләре туфракларының урман үсү үзлекләренә, агач һәм куак токымнарының урман хуҗалыгы-биологик үзенчәлекләренә нигезләнеп гамәлгә ашырыла һәм түбәндәгеләрне тәэмин итәргә тиешле:

– җирләрне һәм объектларны начар факторлардан сакларга;

– территориянең урманлы өлешен арттырырга һәм әйләнә-тирә мохиттәге шартларны яхшыртырга.

Урман үрчетү ясалма урман утыртмаларын үсентеләрне, чәчкечләрне, ботакларны утырту яки орлыкларны чәчү ысуллары белән башкарыла.

Урман үрчетү максатларында булдырылучы урман утыртмаларының төп төрләре кырсаклагыч һәм агынтыкөйләүче урман полосалары булып тора.

Көтүлекләрдә микроклиматны яхшырту, көтүлекләрнең продуктлылыгын арттыру, хайваннарны начар климат шартларыннан саклау өчен урман-мелиоратив утыртмалар утыртыла.

Автомобиль һәм тимер юлларының читләрендә, һәм шулай ук аларның сак зоналарында урман утыртмалары юлларны кар һәм ком каплаудан саклау, якын-тирәдә урнашкан авыл хуҗалыгы биләмәләренә авыр металлар керүне булдырмый калу өчен утыртыла.

Рекультивацияләнергә тиешле җирләрдә урман үрчетү рекультивациянең техник этабын үткәргәннән соң әлеге җирләрнең биологик рекультивациясе (планлаштыру, уңдырышлы туфрак катламын салу, чокыр казылган җирләрне террасалау һ.б.) максатында урман утыртмалары утырту юлы белән гамәлгә ашырыла.

Су саклау зоналарында һәм су объектларының яр буе сак полосаларында урман үрчетү аларның ярлары ишелүдән, чүпләнүдән, ләм белән капланудан һәм су ресурсларының арыклануыннан саклау максатында яр ныгыткыч һәм башка урман утыртмаларын утырту юлы белән гамәлгә ашырыла.

Торак пунктлар урнашкан җирләрдә урман үрчетү әйләнә-тирә мохитне яхшырту максатларында рекреация басымнарына, сәнәгать ташландыклары йогынтысына һәм башка начар факторларга карата тотрыклы булган урман утыртмаларын утырту юлы белән башкарыла.

Урман үрчетү буенча башкарылучы эшләрнең методлары һәм технологияләре урман үрчетү проектлары белән билгеләнә. Урман үрчетү проекты булдырылган урман үрчетү объектларының торышына карата урман үрчетү буенча эшләрне тәмамланган дип табу өчен конкрет бәяләмә

критерийларын (урман-мелиоратив утыртмаларның яше, агачларның уртача озынлыгы, ябалдашларның йомыклык күрсәткечләре, мәйдан берәмлегендә яшәргә яраклы булган агачларның һәм куакларның саны һ.б.) үз эченә алырга тиеш.

Урман утыртмалары иң әһәмиятле (төп) агач яки куак токымнарыннан яисә берничә әһәмиятле һәм тыгыз бәйләнешле агач һәм куак токымнарыннан булдырыла ала.

Иң әһәмиятле агач токымы җирле урман булдыру токымнарыннан сайлап алына, ә уңай тәҗрибә булган очракта – интродукцияләнгәннәрдән. Ул урман үрчетү максатларына туры килергә һәм җир кишәрлегендәге урман үсү үзенчәлекләренә ярашырга тиеш.

Тыгыз бәйләнешле агач токымнарын һәм куакларны сайлап алу аларның төп токымга карата йогынтысыннан чыгып башкарыла.

Урман үрчетү буенча урман утыртмаларын булдыруның төп методы утырту булып санала, ул төрле утырту материалларны белән башкарыла ала. Утырту өчен чәчкечләр һәм үсентеләр, һәм шулай ук ботаклар кулланыла.

Утырту материалы утырту алдыннан аны кибүдән һәм зыянлы организмнар белән зарарланудан саклау, һәм шулай ук яшәргә яраклылыгын һәм үсеш тизлеген арттыру өчен төрле матдәләр белән эшкәртелергә мөмкин.

Утыртылучы урман утыртмаларының башлангыч куелыгы һәм утырту урыннарының урнашуы агачларның һәм куакларның үсү дәрәҗәсенә карап, начар факторларга карата тотрыклы булган, аеруча озын гомерле һәм урман үрчетү максатларына туры килүче урман утыртмаларының формалашуына ярдәм итәргә тиеш.

Утыртылучы урман утыртмаларының башлангыч куелыгы һәм утырту урыннарын сайлау төп агач токымының төренә, урман зонасына, урман үсү шартларының тибына, урман үрчетү методына һәм максатларына, файдаланылучы утырту материалының тибына карап билгеләнә.

Агач һәм куак токымнарын утырту туфракка ашлама, үсемлекләрне зыянлы организмнардан саклау чараларын кертеп, һәм шулай ук киләчәктә аларны ашлама буларак, печән әзерләү һәм башка максатларда куллану буенча үлән чәчү белән үрелдерелергә мөмкин.

Утыртылган урман үсемлекләрен карап тоту агротехник (агротехник карап тоту) һәм урманчылык (урманчылык карап тотуы) ысуллары белән башкарыла.

Агротехник карап тоту, кагыйдә буларак, агачларның һәм куакларның ябалдашлары йомылганчы башкарыла һәм түбәндәгечә тәэмин ителә:

– үсемлекләрне үлән һәм туфрак өемнәреннән, ком өеменнән, туфракны су юып алып китүдән һәм җил белән очыртудан, салкыннан кысылудан кул ярдәмендә төзәткәләү;

– үлән үсемлекләрен механик юл аша бетерү белән берлектә туфракны көпшәкләндерү;

– үләнле үсемлекләрне химик чаралар белән юк итү;

– өстәмәләр (үлгән, тамырланмаган үсемлекләр урынына агачлар һәм куаклар утырту), минераль, органик ашламалар белән тукландыру һәм су сибү (планлаштырыла һәм махсус чаралар кебек үткәрелә).

Агротехник карап тотуның максаты – үләнле һәм кирәкле булмаган агач үсемлекләрен бетерү.

Карап тотуның ысуллары, алымнарының күләме, аларның кабатланучанлык вакытлары һәм агротехник карап тотуларны үткәрүнең озынлыгы (утыртканнан соң узган еллар саны) урман үсү шартларының типларыннан, культивацияләнүче агач һәм куак токымнарының биологик үзенчәлекләреннән, туфракны эшкәртү ысулыннан, урман утыртмаларын утырту методыннан, кулланылучы утырту материалының зурлыгыннан һәм башка үзенчәлекләреннән чыгып билгеләнә.

Чүп үләннәренә һәм агач үсемлекләренә каршы көрәш буенча химик чараларны куллану Россия Федерациясенең пестицидлар һәм агрохимикатлар белән сак эш итү турындагы законнары нигезендә рөхсәт ителә.

Минераль һәм органик ашламалар, кагыйдә буларак, ярлы (комлы, су белән юылган, киптерелгән, рекультивацияләнгән һәм б.ш.), үлән үсемлекләренә үсеп китү мөмкинлеге булмаган туфракларга кертелә.

25% алып 85% кадәр яшәп китүче урман утыртмалары (утыртылган яки чәчелгән күләм процентларыннан тере үсемлекләре яки шытымнар күләме белән) өстәлергә тиешле. Тере үсемлекләр яки шытымнар кишәрлек мәйданы буйлап тигез урнашмаган урман утыртмалары теләсә нинди җайлашып китүләрдә дә өстәлә.

Өстәгән вакытта утырту материалының яше культивацияләнүче үсемлекләрнең яшенә яраклашырга тиеш.

Урман үрчетү максатларында утыртылган урман утыртмаларын урманчылык карап тотуы чүп булып саналган, зәгыйфьләнгән, һәлак булган агач үсемлекләрен һәм сәламәт агач һәм, калганнары яхшы үсеп китсен өчен, куакларның өлешен даими кисеп торудан, урман үрчетү максатларында файдалы функцияләрне башкаруын тәэмин итүче утыртмаларны формалаштырудан гыйбарәт.

Урманчылык карап тотуы культивацияләнүче агач һәм куакларның ябалдашлары йомылганчы башкарыла.

Агачларның һәм куакларның ябалдашлары йомылганнан соң аларны карап тоту Россия Федерациясе урман законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Әгәр дә утыртылган урман утыртмалары урман үрчетү проектында куелган критерийларга туры килә икән, ул чакта урман үрчетү объектларын булдыру буенча эшләр төгәлләнгән дип санала.

Урман торгызу һәм урман үрчетү буенча чаралар үткәрү таләп ителгән мәйданнарның зурлыклары 2.1.7.3.3 таблицада күрсәтелгән.

2.17.3.3 таблица

## Урман торгызу һәм урман үрчетү буенча чараларның нормативлары һәм параметрлары

мәйданы, га

| Күрсәткечләр | Урман үсемлекләре белән капланмаган урманнар | | | | Үзгәртеп кору фонды | Диләнкеләр, алдагы тоташ кисү чорыныкы* | Тоташ санитар кисүләр* | Барлыгы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | көек-ләр | кисеп ташлан-ган | агачсыз урыннар бушлыклар | җәмгысе | | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
| Урман торгызуга мохтаҗ җирләр - Барлыгы: | 7 | 125 | 59 | 191 | | 128 | 272 | 591 |
| Шул исәптән токымнар буенча: | | | | | | | | |
| - ылыслылар буенча | | | | | | - | 42 | 42 |
| - каты яфраклылар буенча | | | | | | 51 | 60 | 111 |
| - йомшак яфраклылар буенча | 7 | 125 | 59 | 191 | | 77 | 170 | 438 |
| Ясалма (урман культураларын булдыру) - барлыгы: | | | | | | 51 | 102 | 153 |
| Алардан токымнар буенча: | | | | | | | | |
| Ылыслы | - | - | - | - | | 51 | 42 | 93 |
| Каты яфраклы | | | | | | | 60 | 60 |
| Йомшак яфраклы | | | | | | | | |
| Табигый урман торгызу, барлыгы: | 7 | 125 | 59 | 191 | | 77 | 170 | 438 |
| Алардан токымнар буенча: | | | | | | | | |
| Ылыслы | - | - | - | - | | | | 83 |
| Каты яфраклы | | - | - | | | | | |
| Йомшак яфраклы | 7 | 125 | 59 | 191 | | 77 | 170 | 438 |

* 10 елга карата күрсәткеч хисабында тоташ кисүләрнең мәйданы 8,5кә тапкырлана, чөнки соңгы ел алдыннан килүче алда һәм соңгы елдагы диләнкеләрнең яртысы күрсәтелгән вакытка кисүдә тора һәм урман торгызу чараларына җәлеп итеп алмый. Калган 1,5 диләнкеләр киләсе елдагы чор хисабында исәпкә алынырга мөмкин.

Урман торгызу ысулын билгеләү өчен урман белән капланмаган җирләрдә һәм өлгергән һәм өлгереп килүче утыртмаларның ябалдашлары астында табигый яңартылуны (башлангыч яңартылу) тикшереп тору нәтиҗәләре нигез булды.

Урман культураларын булдыру технологиясе туфрак-типологик шартларга бәйле. Технологияләр нигезе сыйфатында Урманчылык һәм урман хуҗалыгын механикалаштыру буенча Бөтенроссия фәнни-тикшеренү институты тарафыннан эшләнгән урман торгызу буенча хисап-технологик карталар киңәш ителә.

Урман культураларын булдыруның иң ышанычлы ысулы утырту булып санала.

Урман торгызу эшләрендә эш урыннарын сайлап алу, урнаштыру һәм планлаштыру 2.17.3.4 таблицада китерелгән.

2.17.3.4 таблица

**Урман торгызу эшләрендә эш урыннарын сайлап алу, урнаштыру һәм планлаштыру**

| Күрсәткечләр | Нормативлар (оптималь күрсәткечләр) |
|---|---|
| 1 | 2 |
| 1. Эш урыннарын рациональ сайлап алу билгеләре<br>1.1. Яраклаша алырдай яшь агач булганга карап | |
| Торгызылган дип түбәндәге кишәрлекләрне санарга: | |
| Йомшак яфраклы хуҗалыкта | 1 гектарга кимендә 5 мең данә шытымнары яисә орлык нөсхәләре мәйдан буенча чагыштырмача тигез урнашканда |
| Каты яфраклы тәбәнәк кәүсәле хуҗалыкта | 1 гектарга каты яфраклылар токымнарының шытымнары белән 400-600 данә түмәр булганда (400 данәдән ким булса – торгызу канәгатьләнерлек түгел) |
| Вак шытым | 1,5 м биеклектәге нөсхәләре гомуми саныннан 2/3 артык булганда |
| Эре шытым | 1,5 м биеклектәге нөсхәләре гомуми саныннан 1/3 артык булганда |
| 1.2. Урман культуралары мәйданнары категориясе буенча: | |
| Тоташ сөрү рөхсәт ителә торган | Бушлыклар, ачыклыклар, аланнар һәм авыл хуҗалыгы әйләнешеннән төшеп калган мәйданнар, киселгән урыннар һәм черегән яисә казып алынмаган түмәрләре булган иске янгын урыннары |
| Туфракны полосалар һәм буразналар рәвешендә өлешчә эшкәртү рөхсәт ителә торган | Киселгән урыннар, төп һәм икенчел токымнар белән торгызылмаган янгын урыннар, 1 гектаргага артык дымлы 500 түмәргә кадәр, 600 түмәргә кадәр – яңа һәм коры туфракларда |
| Туфракны буразналар яисә мәйданчыклар рәвешендә эшкәртү рөхсәт ителә торган | Шул ук мәйданнар, әмма аларда тиешенчә 500дән артык һәм 600 түмәр |
| Туфракны өлешчә эшкәртүне таләп итә торган | Киселгән урыннар, төп токым белән канәгатьләнмәслек дәрәҗәдә торгызылган яисә йомшак яфраклылар белән (соры зирек, фаут усагы һәм башкалар) яисә сирәкләнгән үсентеләр |
| 1.3. Кишәрлек урнашу рельефы буенча: | |

| Күрсәткечләр | Нормативлар (оптималь күрсәткечләр) |
|---|---|
| 1 | 2 |
| Оптималь | Диңгез өслегеннән 500 метрга кадәр биеклектәге һәм 5 градуска кадәр тигезлек шартлары |
| Тракторлар кереп йөри ала торган (иминлек күзлегеннән) | 6-12 градус авышлыгы (гомуми билгеләнештәге тракторлар базасында агрегатлар белән эшкәртү: көпчәкле - 8 градустан да артмаган авышлыкларда, башмаклы - 12 градустан да артмаган) |
| 1.4. Гидрологик шартлар буенча (дым күп яратмый торган агач токымнары өчен) | |
| Оптималь | Туфрак-грунт сулары кимендә 30 см тирәнлектә яткан дренажланган туфраклар (мөмкин булса – туфракны эшкәртмичә, ә кирәк чакта – полосаларны фреза яисә сука белән йомшарту, буразналар яру) |
| Мөмкин булган | Дымы вакытлыча артып киткән туфраклар (түтәлләр һәм катламнар рәвешендә микрокалкулыклар әзерләгәннән соң) |
| | Дымы артып киткән туфраклар (дренаж каналлары ярып яисә киптергәннән соң туфракны катламнар белән әзерләү) |
| Мөмкин булмаган | Йомык котлованнар кишәрлекләре (киптерү юлы белән артык дымны чыгару кыенлашкан) |
| 1.5. Урман культуралары эшләре башкарылырга тиешле кисүләрне планлаштыруга таләпләр | |
| Кисү калдыклары | Яндырылырга яисә 3 м киңлектәге тыгыз параллель валларга куелырга тиеш. Кисек калдыклары гомуми мәйданның 20%тан артмаган өлешен биләргә тиеш (вариант: кисек калдыклары бик күп булмаганда, ягъни 1 гектарга 15 скл. куб. м булганда, кисү бүлемтекләре буйлап тигез урнаштырылырга мөмкин) |
| Агачсыман | Барлык агач материалы урман культуралары эшләре башланганчы тулысынча алып бетерелергә тиеш. |
| Агач материалының өске складлары һәм йөк төяү мәйданнары били торган мәйдан | 10 гектардан кимрәк булган диләнкеләрдә ул гомуми мәйданның 10%тан артмаган өлешен биләргә тиеш. Барлык кисү урыннарында ул урманнар торгызу эшләрен уздырырга яраклы хәлгә ктерелергә тиеш (агач материалын тулысынча җыеп алу, шул исәптән аска салынганнарын, кисек калдыкларын, бульдозер белән микрорельефны тигезләү һәм башкалар) |
| Урман бүлемтекләрен машина белән эшкәртү барышында минеральләштерелгән туфрак өслеге күләме: | |
| а) урман культуралары булдырылырга тиешле | Көлсу авыр балчык һәм суглин дымлы туфракларда (кара җиләкле, озын мүкле наратлыклар һәм чыршылыклар) – урман бүлемтекләре мәйданының 20%ы. Коры комлы туфракларда (лишайниклы наратлыклар) - урман бүлемтекләре мәйданының 15%тан артмаган өлеше. |
| б) табигый яңартылырга тиешле | Көлсу комлы яхшы дренажланган туфраклардагы тигезлек урманнарында (нарат җиләкле наратлыкларда) 15-20% өлешен минеральләштерү рөхсәт ителә (үзлегеннән орлыкларын чәчүне тәэмин итеп). Табигый яңартылуга ярдәм итү өчен бүлеп бирелгән кисү урыннарында туфракны минеральләштерү гомуми мәйданның кимендә 20-30%ында уздырылырга тиеш (шытымнарны саклап калу шарты белән). |
| Түмәрләрнең биеклеге | Диаметрының 1/3ыннан артмаган, диаметры 30 сантиметрдан нечкәрәк, 10 сантиметрдан артмаган |

| Күрсәткечләр | Нормативлар (оптималь күрсәткечләр) |
|---|---|
| 1 | 2 |
| 1 гектарга түмәрләр саны - 600 данәдән артык | Җир белән тигез өлештә алдан түмәрләрне казып чыгармыйча, чистартмыйча, кисеп алмыйча сукалар, фрезалар, урман утырту машиналары, культиваторлар белән эшләү рөхсәт ителми.<br>Эре утырту материалларын механикалаштырылган утырту алдыннан полосалап казып алу юлдаш һәм куак токымнары үсентеләре белән капланган кисүләр урыннарында аеруча нәтиҗәле була (полосаларның киңлеге 2 м.). |
| 1.6. Кишәрлекләрне урман культуралары фондына кертүнең рөхсәт ителмәгән үзенчәлекләре | |
| Урманчылык алып баруындагы | Хуҗалык өчен кыйммәтле токымнар белән табигый рәвештә канәгатьләнерлек яңара торган мәйданчыклар |
| Техник-икътисади | Су бастырылырга яисә корылмалар куелырга тиешле җирләр.<br>Хуҗалык йогынтысы өчен мөмкин булмаган, күләме һәм әһәмияте буенча зур булмаган, аерым урнашкан, ерак урнашкан, урман культуралары булдыру өчен икеләтелгән чыгымнар таләп итүче мәйданнар |
| туфракның тамырлар үтеп керерлек тыгыз катламы тирәнлеге буенча | Шуннан артык түгел:<br>катнаш урманнарда – чыршы өчен 50 см һәм нарат өчен 80 см; киң яфраклы урманнарда – чыршы өчен 60 см һәм нарат өчен 120 см киң яфраклы урманнарда – чыршы өчен 60 см һәм нарат өчен 120 см |
| 2. Кишәрлекләр конфигурациясе һәм күләме | Туры почмаклы яисә трапеция сыман, агрегатлар эшләү өчен уңайлы. Эре массивлар рәвешендә, мөмкин кадәр тигез яклы |
| 3. Кишәрлекне җирлектә беркетү | Урман культуралары эшләрен алып бару өчен бүлеп бирелгән барлык мәйданнар почмак үлчәү рәвешендә фотога төшерелгәннән соң, сызыклары кисешкәш җирләрдә (кишәрлек яклары) баганалар утырту юлы белән шушы урында беркетелә.<br>Баганалар озынлыгы 2 м, диаметры 12-16 см булырга һәм багананың өске очында төрге белән ике мәртәбә ышкып алып ясалган чокырда (яңагында) тиешле язу ясалырга тиеш. |
| | Барлык кишәрлекләр сызымда квартал челтәренә бәйләп, ачык визирлар яисә табигый чикләр белән чикләнгән булырга тиеш. Урман культуралары проектына кушып бирелүче сызымнарда шулай ук утырту материалын казып кую чокырларның кайда урнашуы, техника туктап тору урыннары, буразналар, борылып китүче полосалар юнәлеше һәм эшкәртелми торган мәйданнар (юллар һәм башкалар) ачык итеп билгеләнергә тиеш. Сызымнар 1:10000 масштабында төзелә, кишәрлек мәйданы 0,1 гектарга кадәр төгәллек белән исәпләнә. |
| | Фотога төшерү белән бергә (урман культураларын булдыру буенча билгеләнгән алымнарга бәйле рәвештә) мәйданны урында һәм сызымда үсү шартлары буенча бер үк төрле кишәрлекләргә, шулай ук блокларга (әгәр янгынга каршы чокырлар казу зарур булса) кишәрлекләргә алдан бүлгәләү гамәлгә ашырыла. |
| 4. Урманчылык территориясендә урман культураларын, предприятиеләр урнаштыру | Кишәрлекләр урман культуралары эшләрен төрләре һәм аларны башкару вакытлары буенча мөмкин кадәр бер урында, ахыр чиктә якындагы кварталларда (блокларда) тупланган булырга тиеш. Моның өчен мондый блоклар җыелмасын алдан әзерләп куялар, алар өчен (туфрак өлгерү срокларын исәпкә алып) эшләрне башкару |

| Күрсәткечләр | Нормативлар (оптималь күрсәткечләр) |
|---|---|
| 1 | 2 |
| | графикларын һәм техника (эш урыннары) хәрәкәте өчен барлык урманнар торгызу эшләре буенча уртак итеп тә, иң мөһимнәре өчен аерым да рациональ маршрутлар әзерлиләр (агачлар утырту, туфракны әзерләү, урман культураларын карау, питомник кору һәм утырту материалларын казып алу һәм башкалар). |
| 5. Техника өчен туктап тору урыннарын һәм тиешле эшләр башкару сезонына эшчеләрне яшәү өчен урнаштыру | Эшкәртелергә тиешле кишәрлекләр (блоклар, кварталлар) мөмкин кадәр территория үзәгендә иң ерак урнашканыннан 10 километрдан ла артык булмаган җирдә урнашырга тиеш. Эшләр күп булып та, эшчеләрне һәр көн саен эш урыннарына илтү мөмкин булмаганда яисә моны нинди дә булса сәбәпләр аркасында башкару мөмкин булмаганда, аларның техник туктап тора торган урыннар янәшәсендә күчмә йортларда, кыр лагерларында яисә торак пунктта вакытлыча яшәүләрен оештыралар. |
| 6. Кишәрлектә утырту материалы өчен казып кую чокырларын урнаштыру (чәчкеннәре алмаштырыла торган запасы булган тракторлар) | Чәчкеннәрне утырткванда аларны китерүнең максималь аралары 50 метрдан артмаска тиеш. Казып кую өчен калкулыктагы, су басмый торган, җил һәм кояш тими торган, туфрагы җиңел булган урыннар сайлап алына. |
| 7. Урман культуралары кишәрлекләрендә эш урыннарын урнаштыру: | |
| Туфрак кулдан эшкәртелеп | Бер-берсенә 3 м якын түгел |
| Киселгән агачларны һәм куакларны кулдан җыю | Куак кискечләр эшли торган урыннан 30 метрдан якын түгел |
| 2 куак кискечнең берьюлы эшләве | Бер-берсенә 60 м якын түгел |
| Ике һәм аннан да күбрәк агрегат бер үк вакытта туфрак эшкәрткәндә | Сөзәклек буенча - бер-береннән 60 метрдан да якын түгел (бер үк вертикаль буенча техника һәм кешеләр эшләү рөхсәт ителми). Горизонталь буенча - 30 метрдан якын түгел |
| Тамырлары казып алына торган теләсә нинди эшләр башкару барышында | Тамырказыгычтан 50 метрдан да якын түгел |
| Урманнарны механикалаштырылган утыртуда | Агрегат артыннан төзәтеп йөрүче эшчеләр аңардан 10 метрдан да якын түгел. Агрегат борылып киткәндә, башка җиргә күчкәндә, каршылыкларга тап булганда үсентеләр утыртучылар трактор туктаганнан соң тракторчы сигналы буенча эш урыннарыннан китәргә тиеш. Агрегат хәрәкәттә вакытта аларга аннан тушәргә, аңа утырырга яисә утырту материалын тутырырга рөхсәт ителми. Берничә агач утырту агрегаты бер үк кишәрлектә берьюлы эшләгәндә бер-берләреннән 20 метрдан да якын булмаска тиеш. |
| 8. Кишәрлекләрдә эшләү урыннарын (чокырлар, буразналар, полосалар) урнаштыру: | Мөмкин кадәр туры сызык буйлап бер-беренә параллель урнашакан кишәрлекнең озын ягы буенча |
| Чокыр-чакырлы рельефлы урында | Чокырлар авышлыкта аркылы урнашырга тиеш |
| Дымлы туфракларда (кара җиләкле урманнарда) һәм | Туфракны киптерү максатларында сулар агып төшү юнәлеше буенча (сөзәклек буенча), аларны табигый су агып төшү |

| Күрсәткечләр | Нормативлар (оптималь күрсәткечләр) |
|---|---|
| 1 | 2 |
| дымлы (озын мүкле) туфракларда | чокырларына яисә гамәлдәге мелиоратив челтәрләргә кушып, буразналар яралар |
| 9. Полосалар үзәкләре арасындагы ераклык (буразналар, культуралар рәтләре): | |
| Туфракны өлешчә эшкәрткәндә | Төп токымны утыртуның әлеге урман үсү районы өчен билгеләнгән санын тәэмин итәргә һәм кирәк булганда агрегаталар (катоклар һәм башкалар) өчен булачак культуралар рәтләре арасында (киңлеге кимендә 3 метрлык) узып йөрү урыннары салынырга тиеш. |
| Рәтләр арасындагы ераклык | Нарат культуралары өчен - 3-4 м, чыршы өчен - 4 м, карагай өчен - 5 метрга якын, кедр өчен - 6 метрга якын (тамырларын казып алганда нарат һәм чыршы өчен 5 метрга кадәр арттырылырга мөмкин) |
| 10. Культуралар рәтләрендә утырту материаллары арасындагы ераклык: | |
| Чәчкеннәр | 0,50-0,75 м кадәр |
| Эре утырту материалы (үсентеләр) | 0,75-1,50 м (күләменә һәм токымына карап) |
| 11. Урман культураларының 1 гектарына башлангыч куелык (урман утыртканда): | |
| Уңайлы үсү шартларындагы кисүләрдә | 4 мең данәдән азрак булмаган |
| Аеруча коры урыннарда | 7-8 мең данәгә кадәр |
| 12. 1 гектарга карата нарат культураларының куелыгы: | |
| Туфракны өлешчә әзерләгәндә | 8 мең данәгә кадәр |
| Тоташ булганда | 10-20 мең данәгә кадәр |
| Хрущевланган мәйданчыкларда һәм кайры асты кандаласы чыганакларында | 15-20 мең данә |
| Азкыйммәте утыртмаларны өлешчә реконструкцияләгәндә | Урман культураларының оптималь куелыгыннан кимендә 50% |
| 13. Урман культуралары өстәмәләре | Чәчкеннәр һәм утыртмалар шактый корыганда (10%тан артыграк) |
| 14. Урман культуралары исәптән төшереп калдырылырга тиеш | Үсеп китүләре 25% ким булганда (комнарны беркетә торган токымнардан тыш) |
| 15. Урманнарның табигый яңару чоры | 3-5 ел (һәрбер урман хуҗалыгы районы өчен аерым билгеләнә) |

Урманнарны карап тоту Россия Федерациясе Урман кодексының 64 статьясы, Россия Федерациясе Табигый ресурслар министрлыгы 16.07.2007 ел, №185 боерыгы белән расланган Урманнарны карап тоту кагыйдәләре (алга таба - Урманнарны карап тоту кагыйдәләре) белән гамәлгә ашырыла.

Урманнарны карап тоту Татарстан Республикасының урман планы, урманчылык буенча әлеге Регламент, һәм шулай ук урманнарны үзләштерү проекты нигезендә, агачларның һәм куакларның өлешләрен кисү, агроурманмелиоратив һәм башка төр чараларны үткәрү юыл белән урманнарның продуктивлылыгын арттыру һәм аларның файдалы функцияләрен саклау максатларында гамәлгә ашырыла.

Урманнарны карап тотуны түбәндәгеләр башкара:

– урманнардан урманнарны үзләштерү проекты нигезендә файдаланучы гражданнар һәм юридик затлар;

– Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы.

Урманнарны карап тотканда урманнарның токым составын һәм сыйфатын яхшыртуга, аларның төре начар йогынтыларга тотрыклылыгын һәм экологик әһәмиятен арттыруга юнәлдерелгән төрле яшьле урман утыртмаларын кисү (алга таба – урманнарны карап тоту кисүләре) башкарыла.

Эксплуатация урманнарында урманнарны карап тоту буенча чаралар, урманнарның файдалы функцияләрен саклап, тотрыклы, максималь рәвештә нәтиҗәле итеп югары сыйфатлы үзагач һәм башка урман ресурслары, аларны эшкәртү продуктларын алу максатларына ирешүгә юнәлдерелгән.

Саклык урманнарында урманнарны карап тоту чаралары әйләнә-тирәлекне булдыручы, су саклаучы, сак, санитар-гигиена, сәламәтләндерү һәм урманнарның башка файдалы функцияләрен саклау максатларына ирешүгә юнәлдерелгән.

Урманнарны карап тоту кисүләре урман утыртмаларының токым составын яхшырту; урман утыртмаларының сыйфатын һәм тотрыклылыгын арттыру, урманнарның саклаучы, су саклаучы, санитар-гигиена һәм башка файдалы үзлекләрен саклау һәм көчәйтү; үзагачны техник яктан өлгертү вакытларын киметү; үзагач ресурсларыннан рациональ файдалану максатларында башкарыла.

Урман утыртмаларының яшенә һәм карап тоту максатларына карап, урманнарны карап тоту кисүләренең түбәндәге төрләре башкарыла:

– яшь агачларның табигый һәм сыйфат составын һәм төп агач токымнары агачларының үсеш шартларын яхшыртуга юнәлдерелгән тонықландырулар;

– урман утыртмаларының куелыгын көйләүгә һәм төп агач токымы агачларының үсеш шартларын яхшыртуга, һәм шулай ук урман утыртмаларының токым һәм сыйфат составын формалаштыруны дәвам иттерүгә юнәлдерелгән тазартулар;

– агачларның кәүсәсе һәм ябалдашы дөрес формалашуга уңайлы шартлар тудыруга юнәлдерелгән сирәкләүләр;

– агачларның үрчемен арттыруга уңайлы шартлар тудыруга юнәлдерелгән аркылы кисүләр;

– утыртмаларда булган яшь өметле агачларның үсеше өчен уңайлы шартлар тудыруга юнәлдерелгән өлгереп килүче, өлгергән һәм картайган утыртмаларга карата үткәрелүче яңартулар;

– формалашкан урта һәм олы яшьтәге утыртмаларда аларның составын, структурасын, төзелешен көйләү һәм максатчан токым агачлары, буыннары, яруслары үсеше өчен уңайлы шартлар тудыру юлы белән яңадан формалаштырулар;

– урман-парк ландшафтларының формалашуына һәм аларның эстетик, сәламәтләндерү кыйммәтләрен һәм тотрыклылыгын арттыруга юнәлдерелгән ландшафт формалаштырулар;

Тонықландыру, тазарту, сирәкләү, аркылы кисү кисүләрен үткәрүнең яшь чорлары 2.17.3.5 таблицада күрсәтелгән.

2.17.3.5 таблица

**Төрле урманны карап тоту кисүләрен үткәрү буенча яшь чорлары**

| Урманны карап тоту буенча кисүләрнең төрләре | Урман утыртмаларының яше, ел | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | кисентенең яше зур булганда үсенте бирүче агач токымыннан барлыкка килгән орлыклы һәм беренче генерацияле ылыслыларның һәм каты яфраклыларның | | башка агач токымнарының кисентенең яше түбәндәгечә булганда | | |
| | 100 яшьтән артык | 100 яшьтән кимрәк | 60 яшьтән артык | 50 - 60 яшь | 50 яшьтән кимрәк |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| Тоныкландырулар | 10 кадәр | 10 кадәр | 10 кадәр | 10 кадәр | 5 кадәр |
| Тазартулар | 11-20 | 11-20 | 11-20 | 11-20 | 6-10 |
| Сирәгәйтүләр | 21-60 | 21-40 | 21-40 | 21-30 | 11-20 |
| Аркылы кисүләр | 60 артык | 40 артык | 40 артык | 30 артык | 20 артык |

Урманнарны карап тоту кисүләрен үткәрүнең дүрт чират төркеме аерылып чыгарыла:

– беренче төркемгә яшь агачларны карап тоту кисүләре һәм катнаш урман утыртмаларындагы сирәкләүләр керә;

– икенче төркемгә куеланган саф утыртмаларны сирәкләү, катнаш утыртмаларда беренче тапкыр аркылы кисүләр керә;

– өченче төркемгә катнаш урман утыртмаларындагы ахыргы аркылы кисүләр, яңарту кисүләре, яңадан формалаштырулар керә;

– дүртенче төркемгә саф (шул исәптән, гомуми агач запасында йомшак яфраклы токымнарның өлеше 30 процентка кадәр булган ылыслы) урман утыртмаларындагы аркылы кисүләр керә.

Урманнарны карап тоту кисүләрен үткәрү вакытлары:

– тоныкландыру һәм тазарту – агачлар яфраклы торышта булганда барлык вегетатив чор дәвамында;

– сирәкләүләр һәм аркылы кисүләр – ел дәвамында;

– аларны саклау максатында җиләкле урман утыртмаларын (мүк җиләге, кара җиләк һ.б.) карап тоту кисүләре – кар каплаган чорда.

Карап тоту кисүләре ылыслы һәм каты яфраклы орлык утыртмаларында өлгергән утыртмаларны кисү буенча билгеләнгән яшькә 20 ел кала, ә йомшак яфраклы һәм каты яфраклы яшь урман утыртмаларына карата 10 ел алдан тәмамлана.

Урманнар өчен агромелиоратив чаралар уздыру юлы белән урманнарны карау яклаучы урман үсентеләрен булдырудан һәм торгызудан, аларны реконструкцияләүдән, кисү юлы белән урманнарны формалаштырудан һәм санитар кисүдән, куакларны яңартудан, шытымнарны караудан, урманнарны табигый торгызудан, хәрәкәтчән комлыкларны ныгытудан, көтүлекләрне яхшыртудан, деградацияләнгән җирләрне урманландырудан, җир кишәрлекләренең туфрак эрозиясеннән зарар күргән җирләрне яклаудан, урманнарны янгыннардан һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә бүтән афәтләрдән саклаудан гыйбарәт.

Азкыйммәтле урман утыртмаларын реконструкцияләү бер яшь классы чорында урман утыртмаларын тулысынча яки өлешчә алмаштыру юлы белән тамырдан үзгәртүгә юнәлдерелгән (реконструкция кисүләре, урман культураларын булдыру, башка чаралар) чаралар комплексыннан гыйбарәт.

Икътисади, экологик максатларга туры килмәүче һәм үзенең агачлары составында кыйммәтле утыртмаларны карап тоту кисүләрен формалаштыру өчен кирәкле күләмдә (ш.и. табигый урман торгызуга ярдәм итәрлек) хуҗалык-кыйммәтле утыртма токымнары булмаган, урман кишәрлегенең әлеге урман үсү шартларына һәм максатчан билгеләнешенә ярашмаган утыртмалар азкыйммәтле булып тора.

Эксплуатация урманнарында реконструкция азҗитештерелешле һәм түбән сыйфатлы агачларны (түбән тукымалы, канәгатьләндерерлек булмаган составлы, түбән үләнле һ.б.ш.) хуҗалык-кыйммәтле токымнарга алмаштыру максаты белән гамәлгә ашырыла.

Саклык урманнарында реконструкция үзләренең әйләнә-тирәлекне булдыру, су саклау, санитар-гигиена, сәламәтләндерү һәм башка файдалы функцияләрен югалта баручы урман утыртмаларын саклык урманнарының максатчан билгеләнешен һәм алар тарафыннан башкарылучы файдалы функцияләрне саклауны тәэмин итүче урман утыртмаларына алмаштыру максатында гамәлгә ашырыла.

Урта яшьле, өлгереп килүче, өлгергән һәм картайган азкыйммәтле урман утыртмаларына карата реконструкция кисүләренең нормативлары (диләнкеләрнең киңлеге һәм мәйданы, диләнкеләрнең тоташу вакыты) йомшак яфраклы урман токымнарының төп кулланылучы урман утыртмаларын тоташ кисү буенча үзагач әзерләү нормативлары нигезендә билгеләнә.

